# Алиш варислары

***Татарстан Республикасы***
***Мәдәният министрлыгы һәм***
***Язучылар берлегенең***
***Абдулла Алиш исемендәге премиясе лауреатлары***
***әсәрләре***

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2010

# Татарстан Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге премиясе турында нигезләмә

Татарстан Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге премиясе балалар әдәбиятындагы күренекле хезмәтләре (проза, поэзия, драматургия, тәнкыйть һәм публицистика өлкәсендәге әсәрләргә), шулай ук балалар әдәбиятын пропагандалау һәм үстерүдәге эшчәнлекләре өчен аерым оешмаларга, шәхесләргә бирелә.

Язучылар берлеге әгъзаларының бүләккә лаек дип табылган әсәрләре, балалар әдәбияты остаханәсендә тикшерелеп, остаханә советы тарафыннан тәкъдим ителә, Язучылар берлеге идарәсе утырышында яшерен тавыш бирү юлы белән (катнашучыларның өчтән ике өлеше яклау шарты белән) раслана. Бүләк соңгы елларда басылып чыккан яңа һәм күренекле әсәрләргә, авторның балалар әдәбиятындагы иҗат эшчәнлеген бәяләп бирелә.

Бер яисә ике премия билгеләнә һәм идарә карары белән һәр елны, А.Алиш туган көнгә багышлап (15 сентябрь), яңа уку елы башланганда игълан ителә.

А.Алиш премиясе ияләренә «Татарстан Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге премиясе лауреаты» исеме бирелә, диплом, лауреат билгесе һәм таныклык тапшырыла.

«Абдулла Алиш премиясе лауреатлары» сериясе булдырылып, бүләк ияләренең иң яхшы әсәрләре китап итеп чыгарыла.

Нигезләмә кагыйдәләре Татарстан Язучылар берлеге идарәсе утырышында расланды.

***Балалар әдәбияты остаханәсе җитәкчесе Шәүкәт Галиев,***
***Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев.***
***Сентябрь, 1996***

*P.S. 2006 елдан Абдулла Алиш исемендәге премия, Татарстан Язучылар берлеге идарәсендә расланып, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан бирелә башлады.*

*1996*

# Шәүкәт Галиев



Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Галиулла улы Галиев (Һидиятуллин) 1928 елның 20 ноябрендә Татарстанның Апас районы Олы Бакырчы авылында туа. 1943 елда туган авылында җидееллык мәктәпне тәмамлагач, ул башта – колхозда, аннары – Кайбыч район үзәгендә хисапчы, 1949 елдан Кайбычта чыгучы «Колхоз бригадасы» исемле газетада җаваплы сәркатип булып эшли. 1953 елда Казанга килеп, алты ел «Чаян» журналында бүлек мөдире вазифасын башкара, бер үк вакытта кичке мәктәптә урта белем ала. 1959–1961 елларда Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршында оештырылган Югары әдәби курсларда укый. Аннары ун ел буе тик язучылык эше белән генә шөгыльләнә. 1971–1984 елларда Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясе мөдире булып эшли. Шуннан соң бүгенге көнгә хәтле профессионал язучылык хезмәтендә.

Шәүкәт Галиев – төрле жанрларда иҗат итүче әдип. Ул – өлкәннәр өчен шигырьләр, җырлар, бик күп юмористик һәм сатирик әсәрләр авторы.

1962 елдан бирле балаларга атап утыздан артык шигырь китабы чыгарган күренекле балалар шагыйре.

1972 елда «Шәвәли», «Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр», «Кызык», «Тәмле йорт», «Котбетдин мәргән» исемле шигырь китаплары өчен Шәүкәт Галиев Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә, 1982 елда «Заяц на зарядке» китабы өчен халыкара әдәби бүләккә – Г.-Х.Андерсен исемендәге Почетлы дипломга лаек була.

1995 елдан Ш.Галиев «Татарстанның халык шагыйре» дигән мактаулы исем йөртә.

1996 елда Татарстан Язучылар берлегендә А.Алиш исемендәге премия булдырылгач, беренче лауреат исеме Шәүкәт Галиевкә бирелә.

Шәүкәт Галиев – 1958 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

# КОТБЕТДИН МӘРГӘН

*(Мәзәкле маҗаралар)*

Ышанма күргән күзеңә,
Ышан минем сүземә.

*Мәкаль*

## БЕРЕНЧЕ КЫЙССА

Мәргән – туры бәргән...

### Котбетдин төлкегә ата һәм...

Иртән үк торып,
Тамакны кырып,
Мыекны борып,
Мылтыкны корып,
Котбетдин мәргән
Ауга киткән, ди.

Чыгып киткән, ди,
Этен ияртеп,
Чаңгысын киеп.
Көртлек йә куян,
Төлке йә бүре
Атармын диеп.

Кырларны гизгән,
Урман ураган.
Көн буе йөргән,
Юлы уңмаган...

Эте һәм үзе
Эңгер-меңгердә
Башларын иеп
Кайтканнар бергә.

Чү, нинди чыр-чу
Ишегалдында –
Ахры, берәр хәл
Булгандыр монда!

Казлар какылдый,
Үрдәк бакылдый,
Сарык өреккән,
Бозау курыккан.

Йөриләр бар да,
Йөриләр анда
Тирәли чабып.
Эт тә кушыла
Һау да һау барып!

Аучының хәле
Көлкесен көлке –
Ишегалдына
Кергән бит төлке!

«Сине эзләп, мин
Кырларда чаптым,

Сагалап күпме
Урманда яттым.
Бу йортны ничек
Эзләп син таптың,
Нәкъ кешесенә
Килдең дә каптың!»

Сөйләвен болай
Сөйләп тормады,
Тик күрү белән
Шулай уйлады.

Чаңгы таягын
Селтәп бер сукты,
Әмма... егылган –
Каз булып чыкты!

Төлке бик елгыр,
Төлке бик чая,
Сугам дигәндә,
Ялт – читкә тая.

Котбетдин мәргән
Мылтыгын ала!
Менә берзаман
Төтен тарала...
Төтен тарала,
Тукта, ни булган –
Төлке йөгерә,
Кәҗә егылган...

Тагын да ярсып
Чаба мал-туар.
Аучы, үчегеп,
Төлкене куа.
Патроннар алып,
Мылтыгын кора,
Төлкегә төбәп,
Көпшәсен бора.

Атылды тагын
Мылтык шарт! итеп,
Һәм ауды... бозау
Җиргә шап итеп.

Ишегалдында
Зәп-зәңгәр төтен,
Җәрәхәтләгән
Котбетдин этен...

Тавык-чебешне
Шактый ук кырган.
Ләкин ычкынган
Төлке, муркырган!

Гарьләнә мәргән,
Мәргән сукрана,
Күкрәк кага да
Болай аклана:
– Төлке дә төлке,
Хәйләкәр, имеш,
Эләгер миңа
Ул тере килеш!

### Төлке Котбетдингә ата һәм...

Котбетдин көчкә
Таңны аттыра,
Котбетдин төрле
Хәйләләр кора,
Ике көпшәле
Мылтыгын кора.

Яралы эте
Өендә кала.

Аучы берүзе
Эз буйлап бара.
Уңышлар телик
Бу юлы аңа!

Авылны чыгып
Менүгә үргә,
Берьюлы ике
Куянны күрә!

Күрсә дә атмый,
Юкса бит өркеп
Еракка качар
Һәм посар төлке.

Урман керүгә,
Очрый бүрегә.
Мылтык шартлатмый,
Һава яңгыратмый,
Үчле ядрәне
Төлкегә саклый.
Авылдан бирле
Эзен югалтмый.
Җитәр, кичә дә
Эшләнде хата.
Тукта!
Әнә ул –
Котбетдин ата!

Котбетдин ата –
Төлке егыла!
Бик җәһәт кенә
Килеп янына,
Мылтыгын куя,
Кулга бау ала...

Ни булганын да
Төшенми кала;
Төлке сикерә,
Котбетдин ава –
Шартлау тавышы
Колакны яра...

Мәргәннең хәле
Мөшкел һәм көлке:
Аның үзен бит
Яралый төлке! –

Яткан җиреннән
Ыргылган чакта,
Аягы тиеп,
Тартылган чакма...

Төлке әй качкан,
Төлке әй чапкан.
Аягы канап,
Котбетдин яткан
Ак карда чалкан.

Аксаклап кына,
Авылга кайткан.
Оялып, өйдән
Чыкмыйча яткан.

Авыл ду килгән,
Авыл гөр килгән,
Авызын ерып,
Авыл бер көлгән!

Авыл сөйләгән
Бары шул хакта:
– Хәзер төлкеләр
Мәргәнгә ата!
Хәзер мәргәннәр
Егылып ята!..

Эте дә аксак,
Үзе дә аксак,
Тик Котбетдиннең
Үзгәрми максат:
– Мин, барыбер мин
Отармын, – дигән, –
Теге мәлгуньне
Тотармын! – дигән.

**Котбетдин төлкене тота һәм...**

Беркем күрмәгән
Кайчан киткәнен,
Кай якка күпме
Җирләр үткәнен.

Тырналган бите,
Тырналган кулы,
Ертылган бүрке,
Тетелгән туны –

Котбетдин кайтты
Капчык күтәреп
Һәм әйтте иңнән
Карга ук бәреп:
– Эләкте тәки,
Менә ул теге!

Капчык кыймылдый –
Ахрысы, төлке!
Кемдер ышанмый,
Кемдер пышылдый:
– Бәлкем, бу хәйлә –
Бәлкем... этедер?
Күрсәтсен әйдә!
– Ә, ышанмыйсыз? –
Диде Котбетдин.
Капчык авызын
Чиште Котбетдин...

Ә көлтә койрык
Чыкты да чапты,
Булыр да икән
Җитез шулчаклы!

Котбетдин калды
Авызын ачып,
Төлкесе тагын
Китте бит качып...

– Ташлыйм бу эшне! –
Диеп, мылтыкны
Котбетдин ярсып
Селтәп ыргытты.
Оялып, башын
Капчыкка тыкты...

Кычкырды берәү:
– Тиде бит! Тиде!
Ауган төлкене
Өстерәп килде.
(Мылтык ташлагач,
Баш тартып аудан –
Түтәсе тиеп,
Төлке бит ауган!)
Котбетдин башта
Тамагын кырды,
Аннары үзе
Торып утырды.
Унга да сулга
Каранып торды
Һәм гайрәт белән
Мыегын борды –
Яшәгәнчә ул
Яшәргә булды,
Эшләгәнчә ул
Эшләргә булды!

## ИКЕНЧЕ КЫЙССА

Ике тәкә башы
бер казанга сыймый.

### Кинәт шул чакта җирләр селкенә...

Кыш үтте шундый
Зур эшләр белән,
Зур эш башкарып
Йөрешләр белән.

Шаулы көннәрне
Котбетдин уйлый.
Аучы күңеле
Авылга сыймый!

Ау вакытлары
Үткән булганга,
Мылтыксыз гына
Китә урманга.

Берүзе белгән
Сукмаклар буйлап
Атлый, үзенең
Уйларын уйлап.

Сызгырып кына
Шулай барганда,
Килеп чыккан ул
Зур бер аланга.

Агачлар – сирәк,
Кешеләр – куе.
Күрше авылның
Бу – сабан туе!

Ишеткән иде,
Чыккан хәтердән.
Котбетдин барып
Бәйрәмгә кергән.

Көрәш ярата
Абзый тормышта.
Тик үзе күбрәк
Карап тормыш ла...

Шау килә мәйдан,
Гөр килә мәйдан.
Бер шаян әйтә:
– Килдең син кайдан,
Мыеклы батыр?

Кәефле халык
Бер мәзәк итеп,
Этеп тә төртеп,
Җибәрә аны
Мәйданга кертеп.

Бәдәнле егет
Баскан уртага –
Әйтерсең менә
Таза Мортаза!
Дядя Степа
Шикелле егет,
Мин кем дигәндәй,
Тора бит көлеп:

– Ай-вай, кот бетте –
Килгән Котбетдин,
Мәшһүр төлкече!
Буламсың тагын
Адәм көлкесе!

Горурлыгына
Аның кагылма,
Котбетдин хәтәр
Андый чагында!
Мәргән учына
Төкереп алды,
Киндер сөлгене
Бөтереп алды,
Егет биленә
Китереп салды!

Теге шаярып
Алынган булды,
Көрәшкән сыман
Кыланган булды.

Пырых та пырых
Үзе гел көлә.
Кинәт шул чакта
Җирләр селкенә.
Әзмәвер ята –
Йөзләрен чыткан,
Билләрен тоткан...
Кемне кем еккан?!
Батыр икәнен
Тәмам оныткан, –
Котбетдин мәргән
Селтәп үк бәргән!

Мәйдан кул чаба:
– Кызык итте! – дип.
Котбетдин әйтә:
– Кызып киттем... – дип. –
Холкым яман бит,
Егет, гафу ит...

Ә Котбетдинне
Котлап чөйделәр.
«Яшәсен яңа
Батыр!» – диделәр.
Кәкре мөгезле
Тәкә бирделәр.

Кайта Котбетдин
Мылтыксыз аудан.
Эте, аксаклап,
Арттарак калган,
Тып та тып атлый
Мут тәкә алдан!..

## ӨЧЕНЧЕ КЫЙССА

Мөмкинне һәркем эшли,
мөмкин түгелне үткен эшли.

### Күзләре үткер, кулы нык аның...

Котбетдин ауга
Чыга яңадан,
Эзләми аннан
Һич тә яңа дан –
Шундый тиктормас
Булып яралган!

Ашкыну тоеп
Кыю йөрәктә,
Камыш аралап
Бүген йөрмәктә –
Көткән ул көзне,
Чыккан үрдәккә!

Кәефе әйбәт,
Сөенә шуңар –
Бүген эш пешәр,
Бүген юл уңар!

Күңел дигәнең
Ул тоя, димәк, –
Килә каршыга
Бер оя үрдәк.

Бак-бак, дип, алар
Биргәчтен тавыш,
Үти-үти, ди
Котбетдин, ялгыш...

«Ах җүләр, җүләр,
Түземлек җитми!»
Үрдәкләр туктый,
Өркеп тә китми.

Башларын һаман
Ия бирәләр,
Шатланган кебек
Килә бирәләр,
Койрыгын болгап
Шыңшый эте дә...

Котбетдин мәргән
Бераз көтте дә
Әкертен генә
Тартты чакманы –
Күзләре үткер,
Кулы нык аның.
Түгел арттыру,
Түгел бу ялган,
Өч үрдәкне бит
Аткан да алган!

Яле, һәйбәтләп
Биленә таксын,
Иңенә ассын,
Кулына тотсын,

Олы урамны
Иңләп бер кайтсын,
Халык шаккатсын!

Үрдәкләренә
Карап барганда,
Күрә бит тамга
Аякларында!..

Берәрсе, бәлкем,
Йомар иде дә,
Эченнән генә
Тынар иде дә...

Котбетдингә шул
Алдау-йолдау ят:
«Кеше белми дә,
Үзеңнән оят...».

Авыл советы
Рәисе аны
Уңышлы авы
Белән котлады:
– Керденме, кордаш,
Мактанырга дип?
Котбетдин әйтә:
– Акланырга... – дип.

Рәис мәргәнне
Бик җитди тыңлый:
– Ачыкламыйча,
Әйе, – ди, – булмый.
Ярый ла эшләр
Зурга китмәсә,
Зурга китмәсә –
Судка җитмәсә...
Хуҗасы белән

Уртак тел тапсаң,
Котылырсың да
Түләп, шәт, акча.

Килеп күрмәгән
Кеше калмады,
Тик танымады
Беркем тамганы.

Хәл белергә дип,
Хатын да килде...
– Үзебезнекен
Аткансың, тиле!

Хатын кайгыра,
Котбетдин бик шат –
Калды күңеле
Борчудан бушап.

– Чү! – дия рәис,
Шып була төркем. –
Әле бит сиңа
Булмады хөкем:
Үзеңнән үзең
Гафу үтен дә
Үзеңә үзең
Акчасын түлә!

Мәргән баш иде,
Ул болай диде:
– Котылуыма
Мин бик шат инде...
Димәк, үрдәкләр
Гел бушка килде?!
Гаепкә бүтән
Батмамын, – диде, –
Тамгасын бакмый
Атмамын, – диде.

## ДҮРТЕНЧЕ КЫЙССА

Белдем эшеңне, коярмын тешеңне.

### Кичен авылда өр-яңа хәбәр...

Иртән авылда
Таралган хәбәр,
Узынган икән
Бүре шулкадәр:
Авылга килгән,
Фермага кергән,
Сарык колагын
Чәйнәп бетергән...

– Аучыбыздан да
Тормаган шүрләп?
– Ә ул чыкмыйдыр,
Йолкыйдыр үрдәк!
– Хәзер шул аның
Бүресе улый –
Артыннан бер дә
Нужасы кумый!..
– Сәбәбе бүтән:
Аның, янәсе,
Үрдәккә беткән
Эре ядрәсе,
Бүре ядрәсе...

Авылдашлары
Сөйләп торганда,
Эз буйлап бара
Мәргән урманда.
Кыстау кирәкми
Мондый аучыны –
Патронга салып
Чыккан ачуны!

Күпме кирәксә,
Йөрер шулчаклы,
Тик бүре белән
Өзәр хисапны!

Нидер бар, тукта,
Тотын мылтыкка!
Чак бәреп екмый
Үтте бер поши.
Кемнәндер куркып
Чапканга охшый.

Гадәтләре бик
Күптәннән мәгълүм –
Бүтән кем булсын,
Бүтән кем кусын –
Бүредер, мәлгунь!

Тәмам ышанып
Көтсә бүрене,
Күрде берәүне,
Күрде каршында –
Бүре бүреге
Кигән башына.

Бүре бүреге
Генә кимәгән –
Бүре йөрәкле
Икән бу адәм.

Үзен күзәтеп
Торганны сизми,
Чапкан пошига
Мылтыгын төзи...

Котбетдин: – Тукта! –
Диеп кычкыра.
Күрә дә теге
Тизрәк ычкына!

Сикереп төпләр,
Түмгәкләр аша,

Йөгерә мөртәт
Хәйран тамаша –
Хәтта пошины
Узды лабаса!
Күр, ераклаша,
Кача бу, кача...

Шактый баргачтын
Артыннан чабып,
Туктый Котбетдин
Сулышы кабып,
Еш-еш тын алып...
Әмма теге дә
Әллә ни бармый –
Кычкыра башлый
Чарый да чарый.
«Коткарыгыз!» – ди,
Ул ярдәм сорый.

Котбетдин килә,
Шундый хәл күрә –
Аягын тотып,
Теге утыра,
Үзе үкерә.

Котбетдин көлә:
– Үзең качасың,
Үзең дәшәсең!
Ник аңа бастың,
Ул минем капкын!
Бүрегә куйдым –
Бик белеп каптың!

Кәнсәләргә дип
Котбетдин бара,
Үзе уйлана:
«Әйтерме рәис,
Ялгышкан, диеп –
Эләкте, бакчы,
Тагын тәпие
Тамгалы киек...»

Кичен авылда
Өр-яңа хәбәр:
– Әмма дә инде
Аучыбыз зәһәр –
Бүренең берсе
Капкан бит, каһәр!..

**БИШЕНЧЕ КЫЙССА**

Бүре тотар бурзай эт
Бөереннән беленер,
Бүре сугар ир-егет
Беләгеннән беленер.

## Йә, мондый хәлнең булганы бармы?

Котбетдин өчен
Җай чаклар бетте,
Басу капкасын
Чыккач та, эте,
Титаклап, өйгә
Борылып китте...

Сафтан чыккан шул
Дустын кызганып,
Котбетдин бара
Эчтән сызланып.

Хәтта мескенгә
Исем кушарга
Юк бит буш ара!
(Менә бүген дә
Бүрегә бара.)

Ә ялгыз йөрү
Күңелле булмас...
Эте урнына
Уйлары юлдаш.

Атлый да карый,
Туктый да тыңлый –
Аучың да үзең,
Этең дә үзең –
Тыңламый булмый!

Ни ул кыштырдый?
Ни ул чыштырдый?
Ахрысы, мескен,
Түзмичә җаны,
Килгәндер эте
Сагынып ауны!

Борылып карый,
Төшенә алмый.
Нәрсә әйтәсе –
Килә кем дисең? –
Килә тәкәсе!!!

Кире авылга
Куып та карый,
Куып та арый,
Әрләп тә арый:
– Йөрсен, – ди, – ярый,
Иярсен, имгәк!

Ни көтмәк кирәк
Мондый явыздан –
Сабантуйдан соң
Аны дан бозган.
Йә, мондый хәлнең
Бармы булганы –
Кем күргәне бар
Тәкә ияртеп
Ауга барганны?

Тәкә ди торгач,
Онтылган бүре.

Әҗәлен эзләп,
Әнә ул үзе
Килә ич бире,
Тонганмы күзе?

Нәрсә уйлыйсы,
Нәрсә көтәсе –
Бүре алдында
Ялкын көлтәсе!

Тагын бер тапкыр
Гөрселди мылтык!
Ә бүре юртып
Китте дә барды...

Буш патроннарны
Ялгыш алганны
Котбетдин бары
Шунда аңлады...

Килерсеңмени
Яңадан кайтып...
Ә юньсез тәкә,
Тешен ыржайтып,
Башын күтәргән –
Көлгән шикелле.

Ачудан мәргән
Гөрс! бер аңа да!
Тәкә сикергән...
Тәгәрәп киткән
Котбетдин мәргән.
Күптән ул болай
Тәгәрәмәгән –
Күрче, нишләде,
Күрче сөмсезне –
Ачуы чыгып,
Хуҗасын сөзде!

...Котбетдин аучы,
Күзләрен ачса,
Тәкәсен таный –
«Гафу...» дигәндәй,
Мыегын ялый.

– Тормыш булгачтын
Төрлесе була,
Ни хәл итәсең...
Минем характер
Икән синдә дә –
Кызып киткәнсең...

Ис җыйгач күрде:
Бер читтә бүре,
Ә бүре үле –
Аягын сузган,
Телен тешләгән.
Бер кызган көе –
Ай-һай-һай-һай-һай,
Тәкә нишләгән!..

Карт бүре икән,
Аучы шәйләгән –
Әйтәм, фермада,
Әйтәм, сарыкның,
Әйтәм, колагын
Гына чәйнәгән...

Урманнан кайта
Котбетдин мәргән,
Бозау кадәрле
Бүре күтәргән!
Батыр тәкәсе
Арттан ияргән.

Кемнең бу ауда
Күпме хезмәте,
Күпме өлеше –
Әйтеп тә тормас
Котбетдин кебек
Тыйнак бер кеше!

Тик бер сүзне ул
Әйтми калалмас:
– Бүредән, – дияр, –
Курыккан кеше
Урманга бармас!

### АЛТЫНЧЫ КЫЙССА

Татар тотыш карамый ышанмый.

### Котбетдин шикле кеше эзеннән бара...

Уңышлар башын
Әйләндермәгән,
Бәхеткә каршы,
Котбетдин мәргән
Яратмый бер дә
Һаваланырга!

Тәкә сөзгәннән
Дәваланырга
Китте көньякка,
Китте бер айга.

Баштан киеренке
Хәлләр узганга,
Алда җаваплы
Көннәр торганга,
Аңа бик тиеш,
Бик кирәк ял да.

– Рәхим ит! – диләр. –
Әйдә, хуш килдең!
Иң әйбәт җире
Бу безнең илнең.

Котбетдин бер көн
Җылыта билен.
Котбетдин өч көн
Җылыта билен...

Әкәмәт адәм
Түгел бу диген –
Дүртенче көнне
Инде пошына,
Канәгать түгел
Тын тормышына.

Бәлки, кемнәрдер
Ашар да йоклар,
Аучы булудан
Аучымы туктар?
Һич югында ул...
Күбәләк тотар!

Дәвалаулардан
Вакыт калганда,
Керә урманга,
Менә тауларга.

Әйтәсе дә юк,
Матур як бик тә.
Саклык та кирәк –
Якын җир чиккә...

Котбетдин карый
Тарлавыкларны,
Таш кыяларны,
Шарлавыкларны.

Күргән урыннар
Арта барсалар,
Күрмәгәннәре
Тарта баралар.

Беркөнне күрде
Чит бер кешене,
Кыланмышлары
Шикле кешене;

Атлый сак кына,
Ялт-йолт карана...
Димәк, өркерлек
Сәбәп бар аңа!

Посып та тора,
Җиргә сыланып,
Иртәнге чыкта
Беткән чыланып.

Сәер кеше бу,
Әйе, бик шикле...
Шпиондыр ул!
Бозгандыр чикне!

Кирәк сынарга –
Барырга эздән.
Килә Котбетдин
Югалтмый күздән.

Әнә компасын,
Картасын карый –
Кем булуына
Һич тә шик калмый!

Инде нишләргә?
Качар бу, китәр... –
Тукта! – ди мәргән. –
Кулларың күтәр!

Гайрәтле тавыш
Колакны яра!..
Сискәнеп, теге
Тукталып кала.
Ачулы караш
Төшереп ала
Һәм мәсьәләне
Төшенеп ала –
Автомат тормый
Төбәлеп аңа...

Тайпылып ала
Кинәт бер читкә,

Котылмак була,
Ахры, ничек тә!

Әйе, бик чая,
Әйе, бик җитез –
Үрмәли тауга
Ул ничек тиз-тиз.

Елга аркылы
Бүрәнә күрде –
Уйламады да,
Чыгып йөгерде.
Тотуы ансат
Булмас өлгерне...

**Шикле кеше Котбетдинне тота...**

– Ул бит һәрвакыт
Режим саклады,
Бу юлы нигә
Ашка кайтмады?
Котбетдин кайда?! –
Дип борчылалар,
Һәм иптәшләре
Эзләп чыгалар.

Бирешми мәргән,
Булса да ялгыз:
– Эләгерсең, – ди, –
Барыбер, явыз!

Бик ярап куйды
Йөреп чыныгу
Һәм дә спортта
Алган чын ныгу;
Юкса йә монда
Нишләр идең син,
Телеңне генә
Тешләр идең син!

Ә шикле кеше
Уйлап та бирми,
Киртә булалмый
Аңарга берни;
Боландай чаба,
Тиендәй сикерә!
Котбетдингә бик
Тыгызга килә...

Теге үзе дә
Нык кына арый –
Туктый да йодрык
Күрсәтеп яный.
Мәргән, иелеп,
Очлы таш ала.
Теге кинәттән
Аңа ташлана!

Һәм китә шуннан
Әүмәкләшүләр,
Тәгәрәшүләр!
Сикереп торышлар,
Тотып алышлар,
Егып салышлар...

Самбоны белә
Котбетдин мәргән.
Теге дә шактый
Каты өйрәнгән...

Көрәш нык бара –
Чыдасаң чыда...
Менә шпион
Егуын ега.
Мәргән – ялт! – өскә
Әйләнеп чыга!
– Булды бу! – дия. –
Каптырдым! – дия. –
Кулларын бәйләп
Кайтырмын! – дия.

Шпион моны
Өстеннән чөя...
Шактый нык төшә,
«Аһ» диеп куя, –
Котбетдин мәргән
Читкәрәк шуа...
Әллә тагын таш
Алмакчы була?

Шунда теге дә
Телгә килде бит:
– Кая качасың?!
Тукта! – диде бит.
Котбетдин хәйран:
– Кем кемне тота,
Нинди фокус бу?!
Ах, өйрәнәсе
Калган боксны...

Калган шул, калган,
Соңгарак калган.
Булмый шул инде
Тешләп терсәкне.
Үти алмыйча
Изге теләкне,
Дошман кулына
Мәргән эләкте...

Болай ди теге:
– Комачауладың
Заданиемә,
Кайтмый тор син дә
Азрак өеңә.
Җибәрсәм әгәр,
Ялгыш уйларсың,
Киттек бергәләп –
Шунда аңларсың!

**Шикле кешенең сере ачыла...**

Тау юлларыннан
Атлыйлар икәү.
Кайларга барып
Чыгарлар икән?

«Каршы килмәгән
Булыйм ди әйдә...» –
Котбетдин мәргән
Уйлый бер хәйлә.

Карышмый гына
Тик алга бара,
Ә юнәлеше
Бит заставага! –

Оттым дигәндә,
Отылсын әле.
Тоттым дигәндә,
Тотылсын әле!

Мавыгу белән
Котбетдин сизми –
Аларны читтән
Малайлар күзли.

Малайлар хәтсез,
Малайлар унлап.
Шул тирәләрдә
Йөргәндә уйнап,
Күргәннәр шушы
Ике кешене,
Икесе дә бик
Шикле кешене.

Һич көтмәгәндә
Алдылар урап,
Әйтмиләр уйнап,
Әйтәләр чынлап:
– Кулларыгызны
Күтәрегез! – дип.

Котбетдин бик шат
Мондый ярдәмгә!
Талпынып карый
Тик теге бәндә.

Котбетдин аны
Тотарга бара...
Мылтыклы малай
Ата һавага!

Ахрысы, берсе
Чапкан авылга –
Әнә кешеләр
Килеп төштеләр,
Тотып алдылар,
Бәйләп салдылар.

Оста башкара
Алар бу эшне!
Котбетдин мәргән –
Чын безнең кеше –
Безнекеләргә
Әсиргә төште...

– Мин үз кеше! – дип
Аңлатып карый, –
Шпион – теге! –
Дип әйтеп карый. –

Аны мин тоттым! –
Диеп тә карый,
Сүзенә беркем
Колак та салмый...

Мылтык тавышын
Алар ишеткән –
Чик сакчылары
Килеп тә җиткән.
«Шикле кеше»гә
Карыйлар көлеп.

Аптырый мәргән,
Бу хәлне күреп...

Тыңлый застава
Начальнигы аны,
Хуплый уяу һәм
Кыю булганын.

Малайларның да
Кыса кулларын.

Бүгенге хәлне
Ачыклап бирде:
– Ефрейтор бүтән
Киемнәр киде,
Тылга үтәргә
Кушылган иде.
Эзенә төшеп
Чик сакчылары
Тиешләр иде
Табарга аны.
Барып чыкмады
Өйрәнү безнең,
Әмма кабаттан
Ышандык бүген –
Сизгер саклыйсыз
Сез дә ил чиген!

...Кайгырмый мәргән,
Кайгыра димсең
Эш бушка киткәч:
– Чыны да булыр,
Дошман бетмәсә,
Шпион бетмәс!..

«Эһ-һем!» диеп, бер
Тамагын кырды,
Күптән бормаган
Мыегын борды,
Ахрысы, яңа
Планнар корды.
Нинди планмы?
Үзеннән сора!
Үзе кайдамы?
Әнә ич тора!

*1996*

## Ләбибә Ихсанова

Күренекле татар балалар язучысы Ләбибә Фаиз кызы Ихсанова 1923 елның 23 августында Киров өлкәсенең Нократ Аланы (Вятские Поляны) районы Түбән Шөн авылында туа.

1941 елда Кукмара район үзәгендә урта мәктәпне тәмамлагач, башта – туган авылындагы җидееллык мәктәптә тәрбияче (пионервожатый), аннары колхозда бригадир ярдәмчесе булып эшли.

1943 елда Казан дәүләт университетының география факультетына укырга керә.

Студент елларында каләм тибрәтә башлаган кыз, университетны тәмамлагач, тулысынча әдәби иҗат эшенә һәм журналистлык хезмәтенә чума.

Утыз ел буе төрле матбугат һәм мәгълүмат оешмаларында: Татарстан радиокомитетында, Татарстан китап нәшриятында, «Ялкын» һәм «Казан утлары» журналлары редакцияләрендә җаваплы вазифалар башкара.

Л.Ихсанова – балалар һәм яшүсмерләр өчен өч дистәдән артык проза китабы чыгарган язучы. Аның «Җир астында җиде көн», «Якты уйлар», «Нияз», «Нияз мәктәптә», «Тал бөгелә», «Робинзоннар лагеренда», «Саралан малайлары», «Милиционер малае», «Тузганак» кебек әсәрләрен укучылар яратып кабул итә.

1996 елда Л.Ихсановага шулай ук иң беренчеләрдән булып Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясе бирелә.

Ләбибә Ихсанова – 1958 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.



## ОЧТЫ, ОЧТЫ...

Кəриманең үзе өчен бик җайлы гадəте бар: берəр нəрсəгə əнисеннəн рөхсəт алырга кирəк булса, аның иң ашыккан, вакытсыз чагын сайлый. Анда инде əнисе күп уйлап тормый, йə шунда ук риза була, яки «юк» дип кырт кисə. Алай да чигенми Кəримə. «Юк» дигəн бер сүзгə ун сүзне алдан ук əзерлəп куйган була. Бүген дə шулай итте. Əнисе ишектəн чыгам дип торганда гына:

– Кинога барыйм əле? – дип сорады.

– Таһир белəн Заһирны кая куясың?

– Хəтимə əбигə кертермен.

Хəтимə əби – күрше карчык. Эшкə дə, кинога да барасы юк инде аның. Телевизор карый-карый да туеп беткəндер. Таһир белəн Заһир керсə, үзенə дə күңелле булыр. Озакка түгел бит. Киносы сəгать ярым барса, клубка йөгереп бару белəн йөгереп кайтуга ярты сəгать китсə, ике сəгатькə генə түзəр əле. Шулай дип əйбəтлəп аңлаткач, əнисе озак уйлап тормады, тиз күнде тагын.

– Алдан кереп сора, алып калырлык булса, барырсың. Тамакларын туйдырып кертергə онытма, – диде.

Кəриманең əнисе дə кызына кушасы эшлəрен кичтəн үк əзерлəп куйган диярсең, вакыты ни тыгыз булса да, исеннəн чыгармады:

– Идəнеңне ю. Кыяр белəн суганга су сип, – дип тə өстəде.

Эшлəмиме соң инде Кəримə! Йөгерə-йөгерə, җырлый-җырлый эшли инде ул аларны. Əле вакыт та бик күп. Идəнне ике кат юып, кыяр белəн суганга өч кат су сибеп чыгарга була.

Апалары кычкырып, тиргəп тормаганда, Таһир белəн Заһирга да рəхəт иде. Ул китап укып утырган арада урындыкларны əйлəндереп машина иттелəр дə буяулы идəннең бер башыннан бер башына чабышалар гына. Таратып ташламаган əйберлəре калмады. Миски капкачлары машина тəгəрмəче булды, апаларының мəктəпкə йөри торган сумкасы автобус тукталышына əйлəнде, идəн себеркесен юл буендагы агач иттелəр. Шулай кызып кына уйнаганда, Таһирның автобусы Заһирныкына бəрелеп авария булды. Иң элек «автобус тукталышы» авып төште, аннары миски капкачлары шалтыр-шолтыр килеп тəгəрəп китте.

Китабыннан башын күтəреп сəгатькə карап алмаса, Кəриманең идəндəге бу тəртипсезлеккə ул хəтле үк ачуы чыкмас иде əле. Вакыт ни арада үткəн, əле генə утырган кебек иде бит, инде кино башланырга да сəгать ярым гына калып бара. Ə бу базарны җыяр өчен генə дə ике сəгать кирəк.

– Хəзер үк җыегыз! Бөтенесен дə җыеп алыгыз! Күземə күрсəтмəгез! – дип, аяк тибеп кычкырды энелəренə.

Ике урындык арасына кулы кысылган Заһир тəмлəп, кычкырып еларга дип авызын ачкан җирдəн шып туктады. Таһир да урындыгын урынына мыштым гына утыртып куйды.

Шуннан соң алар икəү бергə диван почмагына сыенып, апаларының идəн юганын карап тора башладылар. Малайлар үзлəре тараткан əйберлəрен җыеп куярга өлгергəннəр иде инде. Ə калганнарын Кəримə

апалары аерым алып торасы итмәде, соңыннан тәртипкә китерермен дип, ишеккә таба тондыра башлады. Иң элек караватянына идәнгә җәйгән бәләкәй палас җилфердәп барып төште. Аннан күтәрелгән тузан малайларның борынын кытыклап, икесе берьюлы төчкереп җибәрделәр. Караватастында Заһирның агач мылтыгы ята иде. Аңа да чират җитте дип торганда, апалары алай ук эчкә үреләсе итмәде, юеш чүпрәген карават аяклары тирәсеннән генә чолгап алды. Ә сәгать баш очына бәләкәй чүкеч белән бәргән кебек текелди дә текелди:

– Ва-кыт... Ва-кыт... Ва-кыт... Ва-кыт...

Кәримә ашыга, кулы кая, нәрсәгә тигәнен дә карап тормый. Әтисенең өйдә кия торган йомшак башмакларын очырып җибәрде, электр үтүген тибәм дигәндә генә, ватылыр дип уйлады, ахры, тыелып калды, идәннән йолкып алгандай итеп күтәрде дә дыңгылдатып өстәлгә утыртты. Ишек төбенә җитә-җитә, очышлар күбәйде. Таһир белән Заһирга боларны карап утыруы кызык иде. Апаларының үзенең дә сумкасы бусагага шапылдап килеп төшкәч, Таһир түзмәде:

– Очты, очты, сумкалар очты! – дип куйды.

Апасын үртәп әйтүе түгел иде аның. Таһир белән Заһирлар балалар бакчасында шундый уен уйныйлар. Тәрбияче апалары: «Очты, очты, каргалар очты», – дип әйтүгә, барысы берьюлы кулларын күтәрәләр. Тәрбиячеләре кайчагында оча алмый торган әйберләрне дә әйтә, Таһирлар барыбер кулларын күтәрәләр. Апалары андый әйбер очмый бит дип әйткәч, җыйнаулашып көләләр. Кызык уен. Таһирның Кәримә апасын да шулай көлдерәсе килгән иде, ә ул әнә... күзен генә акайтып карады. Таһир үпкәләде:

– Әнигә әйтәм, үзең китап укып утырдың да хәзер безне ачуланасың, – дип шыңшый башлады.

Аңар Заһир кушылды.

Ә сәгать ашыктыра:

– Ва-кыт! Ва-кыт! Ва-кыт!

Инде идән дә юылып бетте. Өйдән чоланга, чоланнан ишегалдына очып чыккан әйберләрне Кәримә бер читкә җыеп куйды. Аның уенча ашыгыч түгел, йә кинодан кайткач, йә иртәгә барысын да рәтләп куярга мөмкин. Суган белән кыярга да су сибелде. Ике кат ук булмады булуын, бер катына да төшкән җиренә төште, төшмәгәненә юк. Ул хәтле су нәрсәгә, төнлә кояш кыздырып тормый ла, көндез генә эчәсе килә ул дип уйлады Кәримә. Кое янында әйбәтләп юынды, өйгә кереп өс-башын алыштырды, чәчен тарап үрде, инде бөтен эш бетте, Хәтимә әбигә кереп чыгасы гына калды. Анысын хәл кылынган эш дип саный иде ул. Заһир белән Таһирны ярата Хәтимә әби: йомыш белән кергән саен аларга бөрмә билле күлмәгенең тирән кесәсеннән йә җимеш, йә конфет алып бирә.

Шулай да Кәримә иртәрәк тынычланган булып чыкты. Күрәселәренең иң үкенечлесе алда икән әле. Ник дисәң, менә кайчаннан бирле туфлиләрен таба алмый җәфалана. Кайдан гына эзләмәде ул аларны, үзе чыгарып аткан әйберләрне дә кире таратып карады. Әнисе булса, җир йоткан дип әйтер иде, беркайда юк туфлиләр. Кәримә әнисенең туфлиләрен дә киеп карады, аягын бөгәрләп тыгарлык булды, алай да сыйдыра алмады. Бармакларны кисеп атасыңмыни, кай арада үсеп киткәннәр. Аптырагач, иске-москы әрҗәсеннән киеп ташланган иске туфлиләрен эзләп алды. Берсенең аркылы бавы өзелгән икән. Үкчәләренең ямьшәйгәнен күреп тормаслар әле, аякка юк дип кинога бармый калырмыни инде ул. Икенчесенең дә бавын йолкып атсаң, киярлеге бар.

Кәримә сыңар туфлиенең аркылы бавын бер тартты, ике тартты, бирешмәде бау. Пычак йә кайчы алып кисеп кенә төшерәсе иде дә бит, ашыккан чагында башыңа андый

акыллы уй киләмени ул?! Кыз бөтен көченә өченче тапкыр тарткан иде, туфлинең өслеге табаныннан аерылды да чыкты. Утырып елыйсы гына калды Кәримәгә. Үч иткәндәй, бая тынып торган сәгать тавышы тагын колагына килеп керде:

– Бет-те! Бет-те! Бет-те!

Фермадан, кичке савымны тәмамлап, әниләре кайтып керде.

– Кара! Сез өйдәмени? – дип сорады ул, гаҗәпләнеп.

Җавап бирүче булмагач, кызы янына утырып, иңеннән кочып алды да аның шешенеп беткән күзләренә карады.

– Ни булды?

– Берни дә булмады...

Кәримә кырт борылып әнисенең кочагыннан чыкты, авызын бүлтәйтеп читкә карап утыра башлады.

– Аның туфлиләре югалды.

– Ул безне ачуланды.

– Туфлине табып бирегез, дип әйтте.

Әйтеп калырга ашыккандай берсен-берсе бүлә-бүлә сөйләгән улларын кызның әнисе ишегалдына чыгарып җибәрде.

– Әләкләргә өйрәнеп тормагыз әле, барыгыз, бар, уйнап керегез.

Таһир белән Заһирның уйныйсылары килми иде. Уйныйсы түгел, сөйләшәселәре дә килми иде аларның. Малайларның инде күптәннән бирле ашыйсылары килә, курыкканга күрә генә Кәримә апаларыннан сорамыйча түзгәннәр иде. Әниләре чыгарып җибәргәч, ерак китмәделәр, баскыч төбенә чыгып утырдылар. Су буеннан үрдәкләр кайтып керде. Кайта-кайта аларның да карыннары ачкан, күрәсең, малайларны күргәч, йөгереп килделәр. Таһир аларга бармак башы хәтле кирпеч кисәге аткан иде, җыйнаулашып шуның артыннан йөгерделәр, алданганнарын белгәч, үпкәләделәр, «бак-бак-бак» дип, лапаска таба юнәлделәр, каршыларына чыккан Алабайдан куркып, тагын да яман бакылдашып, як-якка сибелделәр. Алабайның исә туймас корсакларда эше юк, бик олы эш башкарып йөргән чагы иде. Кәримәнең лапаска очып төшкән туфлиләрен тапкан ул. Шуның берсен әләктереп малайлар алдына килеп басты.

– Таһир, кара әле Алабайны, – дип кычкырды Заһир, шатланып һәм гаҗәпләнеп.

– Апаның туфлие бит бу, – диде Таһир һәм Алабайны муеныннан кочаклап алды. Күңеле булган эт туфлинең икенчесе артыннан чапты.

– Апа, Кәримә апа, туфлиең табылды, Алабай табып китерде, – дип, Таһир белән Заһир урыннарыннан сикереп тордылар.

Әгәр шушы малайлар урынында Кәримә үзе булса:

– Очты, очты, кинолар очты, – дип, аларны үртәргә дә күп сорамас иде. Кечкенә шул әле Таһир белән Заһир, алар бары шатлана гына беләләр.

## 1997

# Роберт Миңнуллин



Татарстанның халык шагыйре
Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин
1948 елның 1 августында Башкортстанның
Илеш районы Нәҗәде авылында туа.
Бала чагы Шәммәт авылында үтә.
Туган авылында, Аккүз, Югары Яркәй,
Карабаш мәктәпләрендә укып
урта белем ала, ике ел район газетасында
эшли, Казан дәүләт университетының
татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый.
Озак еллар «Казан утлары» журналында,
Татарстан телевидениесендә,
«Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй»)
газетасында җитәкче вазифаларын башкара,
1990 елдан Татарстан халык депутаты,
Дәүләт Советы депутаты булып
сайланып килә.
Р.Миңнуллин балалар шигырьләрен
1972 елда яза башлый. Ул – нәниләргә
атап язылган ике дистәдән артык китап
(татар һәм рус телләрендә) авторы.
1992 елда Р.Миңнуллин «Дөньядагы иң
зур алма» китабы өчен халыкара әдәби
бүләккә – Г.-Х.Андерсен исемендәге
Почетлы дипломга,
1998 елда «Күчтәнәч» китабы өчен
Татарстанның Г.Тукай исемендәге
Дәүләт премиясенә лаек була.
2005 елдан ул «Татарстанның халык
шагыйре» дигән мактаулы исем йөртә.
1997 елда балалар әдәбиятын үстерүгә
керткән хезмәтләре өчен
Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш
исемендәге премиясе белән бүләкләнә.
Роберт Миңнуллин – 1977 елдан
Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

# ҖИДЕ АБЫЙ ТАЙ ҖИГӘ

Яшь бер тайны
Җигәр өчен,
Шул бер тайны
Җиңәр өчен
И тырыша
Җиде абый,
И булыша
Җиде абый!

Тик тай дулый!
Кыргыйдыр ул,
Шуңа да тик
Тормыйдыр ул,
Шуңа күккә
Ыргыйдыр ул,
Шуңа җирне
Тырныйдыр ул!

Аны һич тә
Җиңеп булмый,
Хәтта якын
Килеп булмый,
Тибүе бар! –
Белеп булмый.

Тайны әйтәм,
Шундый көчле! –
Коеп куйган
Минем төсле!

Мине ләкин
Җибәрмиләр,
Җитмәс синең
Җегәр, диләр.

Алар мине
Белмиләр шул,
Минем көчне
Күрмиләр шул.

Җәфа чиксәм
Чигәр идем,
Мин ул тайны
Җигәр идем,
Мин ул тайны
Җиңәр идем,
Туйганчы бер
Җиләр идем...

Ләкин мине
Җибәрмиләр,
Якын барма,
Тибәр, диләр,
Йә әниең
Тиргәр, диләр,
Кирәк монда
Ирләр, диләр.

Ә үзләре
Җигәлмиләр,
Шул бер тайны
Җиңәлмиләр,
Адәм тәганәләре!

## ӨЛКӘННӘР

Бу өлкәннәр ни өчендер
Гел киресен эшлиләр.
Мин үзем чәй эчмим, алар,
Кыстый-кыстый: «Эч!» – диләр.

Урамга чыга башласаң:
«Ныгытып киен!» – диләр.
Ә үзләре ни өчендер
Ныгытып киенмиләр.

Йоклыйсы килмәгән чакта:
«Бар инде, йокла!» – диләр.
Йоклаганда: «Тор инде, тор,
Аунама юкка!» – диләр.

Уйнаганда: «Китап укы,
Уйнап утырма!» – диләр.
Укысам: «Башың авыртыр,
Бик күп укыма!» – диләр.

Әгәр дә өйдә утырсам:
«Бар, урамда йөр!» – диләр.
Ә урамга чыгып китсәм:
«Бик күп йөрмә, кер!» – диләр.

Эшсез йөрсәң дә ярамый:
«Бераз ярдәм ит!» – диләр.
Әгәр ярдәм итәм дисәң:
«Борчып йөрмә, кит!» – диләр.

Тотынсаң вак-төяк эшкә,
Алар бирә эресен.
Аңламассың – бу өлкәннәр
Эшлиләр гел киресен!

## ТОРАМ МЕНӘ ЕЛМАЕП

Әтиемнең малае
Бераз шаянрак.

Әниемнең малае
Бераз наянрак.

Әбиемнең оныгы
Бераз кирерәк.

Ә бабамның оныгы
Бераз эрерәк.

Абыемның энесе
Начаррак укый.

Сеңлемнең абыйсы
Артыграк йоклый...

Шул бер малай бит инде
Алар барсы да –

Торам менә елмаеп
Сезнең каршыда!

## ОЛЫ БУЛСАМ...

Олы булсам, мин улыма
Чын маэмай алыр идем.
Каникулда улым белән
Диңгезгә барыр идем.

Улымны көн дә бер тапкыр
Кинога кертер идем.
Көннәр буе машинага
Утыртып йөртер идем.

Бер бинокль, фотоаппарат,
Велосипед кимендә
Сатып алып бирер идем
Аның туган көнендә.

Их, зур булсам, әти булсам,
Нишләргә белер идем:
Ни сораса да, улыма
Гел алып бирер идем.

Ике уйлап тормас идем...
Ник көләсез?
Көлмәгез!
Үзенә дә кирәк икән
Диеп уйлый күрмәгез!

## ПИРАТ

Пират бара
Урамнан.
Курыкмагыз
Сез аннан!

Йөрми ул
Хәнҗәр асып,
Йөрми ул
Кораб басып.

Аның бит әле хәтта
Гомерендә бер кат та
Корабны
Күргәне юк,
Диңгездә
Йөргәне юк,
Бер дә су кергәне юк...

Алай булгач, ул пират
Каян килгән дисезме?
Шуны да белмисезме?

Ул бит Пират исемле
Маэмайның исеме!

## СҮЗ ТЫҢЛЫЙ ТОРГАН МАЛАЙ

Безнең Алмаз
Сүз тыңлый,
Сүзне
Берсүзсез тыңлый.
Каршы килми
Һич кенә –
Булсын аңа
Эш кенә!

– Ярый-ярый,
Эшлим, – ди, –
Эш яратам
Ич мин! – ди.

Булса башка бер малай,
И ялындырыр иде,
Эш тапкан
Булыр иде,
Булмый дип
Торыр иде,
Мең хәйлә
Корыр иде!

Ә ул тормый
Вакланып,
Риза була
Шатланып.

Тик оныта
Үтәргә,
Туры килә
Көтәргә.

Дәшәсең
Аңа кабат,
Әйтә ул
Күзгә карап:

– Ярый-ярый,
Эшлим, – ди, –
Эш яратам
Ич мин, – ди.

Тик оныта
Үтәргә,
Туры килә
Көтәргә.

Көтә-көтә
Туясың,
Үзең эшләп
Куясың!

Әмма ләкин
Алмазны
Ачуланып
Булмый бит –

Киреләнеп
Тормый бит,
Әйткән сүзне
«Тыңлый» бит!

## ӘНИ ЭШТӘН КАЙТКАНЧЫ

Әни таңнан
Эшкә киткән,
Бөтен эшне
Эшләп киткән!..

Нәрсә эшлик икән дип, без
И баш ваттык,
Баш ваттык –
Ахырда җаен таптык:

Банкадагы вареньены
Ялт иттердек
Бергәләп.
Чүлмәктәге

Каймакны да,
Табадагы
Коймакны да
Ашап куйдык
Бүлгәләп!

Безнең бәхеткә, шешәдә
Сөт тә никтер әчегән.
Шуңа күрә без ул сөтне
Салып бирдек мәчегә.

Чират җитте
Акмайга да,
Өлеш чыкты
Акбайга да!

Савытларны юып аннан
Тезеп куйдык өстәлгә.
Тагын эзләгән идек тә,
Савыт беткән өстәргә.

Савыт-сабалар өстәлгә
Таудай өелсен әле,
Чиста савытларны күреп,
Әни... сөенсен әле!

Сөенер шул!
Ә нигә?
Ул савытларны
Барыбер
Юасы бит... әнигә.

## БУТАГАН

Алмаз йөри урамда,
Эшләп йөри ул анда.

Чана шуу – бар эше,
Ап-ак булган бар төше.

Акбай, аны күрүгә,
Әй тотынды өрергә!

Аңламый Алмаз берни,
Өрерлек сәбәп күрми.

Ә мин аның Алмазга
Нигә өргәнен беләм:

Бутаган ул Алмазны
Аю баласы белән!

Башында – йонлач бүрек,
Өстендә дә – йонлач тун.

Өрер дә шул, ул үзе
Аю кебек булгачтын!

## ЮГАЛГАН КӨН

Тырай типкән кичә Фәһим
Һәм бер көнен югалткан.
Ярар, табармын әле, дип,
Фәһим үзен юаткан.

Ләкин ничек табарга?
Кирәк эзләп карарга.

Югалган көнен Фәһим
Көне буе юллаган.
Юллавын ул юллаган,
Юлы гына уңмаган.

Сорашып та караган,
Тик күрүче булмаган.

Кичә күргән идек, бүген
Күренмәде, дигәннәр.
Артыннан куып кара син,
Диеп киңәш биргәннәр.

Юк шул инде!
Югалган көн
Сине көтеп тора ди,
Койрыгын тоттыра ди...

Фәһим көнсез көенә
Кайтып кергән өенә.

Табалмаган кайгысыннан
Җибәргән Фәһим елап...
Тагын бер көн югалткан ул,
Югалган көнен юллап.

## ӘТИЕМ ПАЛАС КАГА

Сызгана да җиңнәрен,
Ала да сыек чыбык,
Кыйный әти... паласны,
Урамга алып чыгып.

Урамда уйнап йөргән
Малайлар, кыз балалар
Үрле-кырлы сикергән
Паласны кызганалар.

Әти көлә: «Бу палас
Тузанланып беткән, – ди, –
Тузаннарын кагарга
Кирәк булган күптән!» – ди.

Мин дә бит, үч иткәндәй,
Тузанга кергән идем,
Урамдагы тузанны
Туздырып йөргән идем.

Әтием палас кага,
Миңа да күз салгалый.
Бер паласка, бер миңа
Карап-карап алгалый.

Ахры, минем тузанны да
Каккаларга чамалый!

## МАКТАНЫРГА ЯРАТМЫЙ...

Мине беләсездер инде! –
Мәрдиев мин, Марат мин.
Мактарлык малай булсам да,
Мактанырга яратмыйм!

Миннән дә шәп укучы юк,
«Бишле» алдым бүген дә.
Шуңа мактанып торырга
Мин мактанчык түгел лә!

Мактанырга була, ләкин
Кирәк түгел ваклану.

Минем кебек шәп малайга
Килешми ул мактану.

Әгәр дә бик кирәк икән,
Иптәшләрем мактасын.
Йә килеп карый аласыз
Безнең мактау тактасын!

Башка малайлар шикелле,
Бәлки, мактаныр идем,
Болай да һәркем белә бит
Әйбәтлегемне минем!

## ӘЙТМИМ

Әни кайтып керде дә:
– Пыр тузган өй эче! – ди, –
Ах, тәлинкәм ватылган,
Кайсыгызның эше? – ди...

Тәлинкәне
Кем ватканны
Беләм бары мин генә.
Беләм дә...
Әйтмим генә.
Ярар инде, сорашмагыз!
Ярдәм итмәс үгетләр.
Әйтер идем, әйбәт түгел,
Сер сөйләсә егетләр.

Әйтмим аны әнигә дә,
Әйтмим аны сезгә дә.
Әйтмим булгач әйтмим инде,
Әйтмим берегезгә дә.

Әгәр дә ул серне чишсәм,
Көлер идегез бугай,
Тәлинкәне
Мин ватканны
Белер идегез бугай.

Хәйләкәрләр!

## БУЛАТЛАРГА КУНАККА!

Булат яши Әстерханда,
Алмаз яши Казанда.
Булатка ай-яй әйбәттер –
Күптән инде яз анда...

Хатлар килә ерактан –
Алмазга ул, Булаттан:

«Сездә һаман кыш әле,
Җимешләр әздер анда.
Кавын, карбыз, йөземнең
Оясы – Әстерханда!

Бездә Идел киң, – дигән, –
Кунак булып кил! – дигән. –
Сиңа бик уңай, – дигән. –

Әгәр дә булса көймәң,
Булмый хәтта ишәсең:
Иделдән агып кына,
Җырлап кына төшәсең!»

Алмаз шушы хаттан соң
Көн саен хәзер әнә
Кунакка әзерләнә.

«Язны гына көтәм, – ди, –
Әстерханга китәм, – ди, –

Казанда яз җитүгә,
Иделдән боз китүгә,
Мин бит үсеп җитәм, – ди, –
Бәләкәй малай булып
Бик күп йөрдем, җитәр! – ди...»
Язлар җитте, җәй булды –
Алмазга да җай булды!

Теплоходта бара ул:
Бүләкләре – Булатка!
Үзе белән әтисен дә,
Үзе белән әнисен дә
Иярткән ул кунакка!

## САБАНТУЙДА

Колга тора мәйданда –
Биегрәктер Айдан да!

Әтәч – колга башында,
Кызыктыра барсын да!

Тик меналмый беркем дә,
Мин дә бар шул төркемдә.

Менә миңа да чират.
Менәм,
Мин дә бит ир-ат!

Менеп киттем тиз генә,
Тиз генә, җитез генә!

Һәм карадым түбәнгә –
Ай-яй... биек менгәнмен,
Ничек менә белгәнмен?!

Ничекләр төшим җиргә?
Куркыта карарга да.
Торам шулай килалмый
Бернинди карарга да...

Үч иткәндәй, әтәч тә,
Бөтен көчкә кычкырып,
Китте кулдан ычкынып!

Ычкынды, җиргә очты,
Йоны гына учымда.
Әтәч урынына мин
Калдым колга очында.

Кирәкми әтәчегез,
Кирәкми бүләгегез –
Мине алырга гына
Менегез берәрегез!

## КЫЗЫЛ ТАВЫК

Безнең кызыл тавыкның
Чебиләре унбишләп.
Чебиләрен саклап кына
Йөртә микән ул нишләп?

Алар янына
Килсәм,
Килеп яратыйм
Дисәм,

Чебиләр
Тик тормыйлар,
Чебиләр
Тоттырмыйлар.

Кызыл тавык
Шунда ук
Килә дә
Очып кына,
Өстемә
Очып куна,
Котылам
Качып кына...

Кызыл тавык чебиләрен
Бер дә читкә таратмый.
Чебиләрен ярата ул,
Мине генә яратмый.

Чебиләрен яраттырмый,
Тоттырып та каратмый.
Әйтегезче, кызыл тавык
Нигә мине яратмый?

## КЫР КӘҖӘСЕ

Нишләтергә
Кәҗәбезне?
Аптыратты
Кәҗә безне.

Бер генә дә
Тыеп булмый,
Бер дә ябып
Куеп булмый.

Ача – кача,
Ача – кача,
Аптыратты
Кача-кача.

Ялан кырдан
Кайтып керми,
Куркыталмый
Аны берни!

Нигә куркак
Булсын ди ул?
Нидән куркып
Торсын ди ул?

Мин бит аның
Көчен беләм,
Кирәктә ул
Бүре белән

Сөзешергә
Хәтта әзер –
Кыр кәҗәсе
Бит ул хәзер!

## МӨГЕЗСЕЗ БОЗАУ

Бабайларга авылга
Кайтсам җәен кунакка,
Дәү әти һәм дәү әни
Тукый минем колакка:

– Бозаудан сак бул! – диләр, –
Усал, сөзгәк ул! – диләр.

Күргән инде мин аны:
Бозаулары – мөгезсез.
Мөгезсез ул беркемне
Сөзә алмый – күрерсез!

Белмиләрдер әле – мин
Үгездән дә өрекмим.

Чын баһадир кебек мин,
Чын матадор кебек мин!
Мин бит, әгәр теләсәм,
Үгезнең үзен егам!
Мин бит, әгәр теләсәм,
Үгезнең йөзен егам!

Мускулларны уйнатып
Киттем туры бозауга.
Алай бик усал икән,
Күрсәтербез без аңа!

Аннарымы? Аннары...
Дәвамы бик күңелсез:
Әлеге бозау мине
Сөзеп еккан... мөгезсез!

Авыртса да сөзгән төш,
Түзәргә була икән.
Теләсәң, мөгезсез дә
Сөзәргә була икән!

## КЕМ НӘРСӘ ТАРТА?

Тегермәнче минем әти –
Тегермәндә ул он тарта.
Абыйны да шунда кыстый –
Көн дә аның кылын тарта.

Ләкин абый гел баш тарта:
– «КамАЗ»ым бик
кызганыч, – ди, –
Әле эшли торган эшем
Күңел тарта торган эш, – ди.

Клуб идәне дер селкенә,
Минем абый биегәндә.
Ул бит Алып батыр кебек –
Ун пот тарта ким дигәндә!

Клубка китте ул бүген дә.
Тышта берәү гармун тарта.
Шул гармунны тыңлый-тыңлый,
Апам тиз-тиз сөрмә тарта.

Ә мине кич чыгармыйлар –
Җәйгән әни урынымны.
Чыгармыйлар, шуңа күрә
Тартып ятам... борынымны.

## МИНЕМ ТАНЫШ АВТОБУСЫМ

Яңгыр булсын,
Буран булсын,
Минем таныш
Автобусым
Тукталышта
Көтә мине,
Ишек ачып
Кертә мине,
Тирбәлдереп
Йөртә мине,
Мәктәпкә үк
Илтә мине –
Бигрәк якын
Итә мине.

Алып кайта
Аннан өйгә –
Әйбәт шул ул
Әллә нигә...

Җилдәй җитез,
Йөртә бик тиз
Минем таныш
Автобусым –
Ул бит минем
Автодусым!



## ЭНЕМНЕ ТИРБӘТКӘНДӘ

Әни юкта энемне гел
Тирбәтәм мин җай гына.
Елап та җибәрүе бар –
Аңа җиде ай гына.

Кичә дә, әни кайтканчы,
«Әлли-бәлли» иткәнмен,

Энем белән бергәләшеп
Эреп йоклап киткәнмен,

Әнинең кайтып җиткәнен
Йоклый-йоклый көткәнмен.

## КАЧЫШЛЫ УЙНАГАНДА

Бар да мине эзлиләр:
Янда гына гөжлиләр!

Тирә-якны таптыйлар,
Кая гына чапмыйлар,
Кая гына бакмыйлар,
Мине генә тапмыйлар...

Ә мин ятам тын гына,
Шыпырт кына, шым гына,
Көтеп ятам тик кенә –
Тапмыйлар соң ник кенә?!

Болытлар да каралды –
Төшә бугай караңгы.

Туңдыра да нигәдер,
Рәхәт урын – өйдәдер!

Була ла ул чыдарга,
Кирәк ләкин чыгарга!

Чыксам...
Кайтып киткәннәр,
Таралышып беткәннәр,
Мине мәзәк иткәннәр...

Итсәләр соң, итсеннәр,
Китсәләр соң, китсеннәр,
Шәп иттек дип йөрсеннәр,

Рәхәтләнеп көлсеннәр,
Ләкин шуны белсеннәр:

Җиңдем мин –
Отылмадым,
Барыбер
Тотылмадым!
Вәт!

## ЯЗДЫК

*(Сүз уйнату)*

Әни белән
Алмаш-тилмәш
Без май яздык,
Әби белән
Оекбашка
Без йон яздык.
Яза-яза,
Яза-яза
Шундый ардык –
Шаярышып,
Уйнап алдык –
Тәнне яздык.

Ә аннары
Апабызга
Без хат яздык.
Абый белән
Матур итеп
Кат-кат яздык.

Аннан хатны
Без почтага
Салып кайттык.
Кайтып керсәк,
Кайтып күрсәк,
Шаклар каттык.

Ник дисезме?
Апа тора
Каршыбызда –
Абый белән
Ава яздык
Артыбызга.

Күтәрелеп
Карарга да
Чак-чак баздык.
Тик торабыз –
Икебез дә
Телдән яздык!

## БАКЧА БЕЛӘН ХУШЛАШУ

Олы бәйрәм бүген бездә,
Зурлар инде күбебез.
Бакча белән хушлашабыз,
Бүген соңгы көнебез.

Тик елыйсы килә минем,
Инде ни хәл итәсе? –
Бакчадан, дуслар яныннан
Бер дә килми китәсе.

Тәрбияче апа елый...
Бу дөнья кызык кына:
Китәсе килми моннан да,
Мәктәп тә кызыктыра!

Күңелле дә, күңелсез дә...
Хәлемне белмиләр шул.
Китмәс идем, зур балалар
Бакчага йөрмиләр шул.

Гел карап торырмын инде
Шушы бакча ягына.
Нигә укытмыйлар икән
Шушы бакчада гына?!

## ТЫЛСЫМЛЫ ТАЯК

Үзе карап торуга
Усал түгел әллә ни,
Ә шулай да... шулай да
Тылсымчы минем әби!
Бер таягы бар аның –
Бетерә бар арганын!

– Барсам да кая гына,
Таянам таягыма,
Таянсам, көч арта, – ди, –
Аттан шәбрәк тарта! – ди.
Беләм инде – шаярта.
Ул бит гап-гади таяк,
Миллион андый таяк.
Ул бернигә ярамый,
Селкенеп тә карамый.

Көлә генә әбием:
– Син атланып кара, – ди, –
Үзе алып бара! – ди.

Шулай дигәч әбием,
Атландым мин таякка –
Чабыйм икән кай якка?
Тыеп булмый атымны,
Атым уктай атылды:
Дулый – тузан туздыра,
Чын атны да уздыра!

Әй чаба ул, әй чаба,
Тими җиргә аягы...
Чынлап тылсымлы икән
Әбиемнең таягы!

## АВЫРТКАН КЕБЕК КЕНӘ

Әллә нәрсә
Булды эчкә –
И авырта,
Түзәм көчкә.

Өйдәгеләр
Киңәштеләр,
Бик тиз генә
Врач дәштеләр...

Утыртты да
Бастырды ул,
Авызымны
Ачтырды ул.

Әйтте аннан
Күзгә карап:
«Синең, егет,
Эшләр харап!

Алдалыйсың
Син ни өчен?
Авыртмый бит
Синең эчең».

Доктор апа
Кызык итте:
Авыртулар
Бетте-китте!

Йөрим хәзер
Көлеп кенә.
Тик авырткан
Кебек кенә

Булган икән
Минем эчем –
Борчылмагыз
Минем өчен!

## *1997*

# Рөстәм Мингалим

Шагыйрь һәм драматург Рөстәм Мингалим (Рөстәм Гали улы Миңлегалимов) 1937 елның 15 августында Самара өлкәсенең Камышлы (хәзерге Келәүле) районы Йолдыз авылында туа.

Туган авылында – башлангыч, Дәүләткол авылында җидееллык мәктәпне тәмамлый. Бөгелмә авыл хуҗалыгы училищесында укый. 1955–1956 елларда Казакъстанда чирәм җирләрне үзләштерүдә катнаша; 1956–1958 елларда Ташкент шәһәре заводларында, соңыннан Бөгелмәдә төрле эшләрдә эшли.


1962–1967 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. Университетны тәмамлагач, «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында әдәби хезмәткәр, җаваплы сәркатип, Татарстан Язучылар берлеге аппаратында әдәби консультант вазифаларын башкара.

1977–1980 елларда Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршында оештырылган Югары әдәби курсларны һәм Дәүләт театр сәнгате институты (ГИТИС) каршындагы берьеллык театр курсын тәмамлый.

Ул – балалар өчен язылган күп кенә шигырь һәм пьеса китаплары авторы.

1997 елда Рөстәм Мингалимгә татар балалар әдәбиятын үстерүгә керткән хезмәтләре өчен Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге, 2005 елда Татарстан китап нәшриятында чыккан «Дәрт чүлмәге» китабы өчен Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премияләре бирелә.

Рөстәм Мингалим – 1970 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.



## ЧӘЧЕҢ СЫЙПАП, ҖИЛ ИСӘ

Тышта җәйге җил исә,
Елап тора Гөлүсә...
Чәчең сыйпап, җил исә,
Ник елыйсың, Гөлүсә?
Югалдымы яулыгың?
Ярый инде, югалсын, –
Бу зур кайгы түгел лә,
Нигә елап торасың?!
Әйттеме соң әниең,
Барма, диеп, уйнарга?
Бу зур кайгы түгел бит,
Моның өчен еларга!
Ияртмиме әтиең?
Син кайгырма, Гөлүсә!
Елап торма, Гөлүсә,
Чәчең сыйпап, җил исә.

Җил дә хәтта еламый,
Ә кайгысы күп аның,
Әнисе дә юк аның.
Үз өе дә юк җилнең,
Дөнья буйлап йөгерә ул.
Елап торган күп кызлар,
Күп малайлар күрә ул.
Җирдә бик күп әниләр
Елаганны җил белә,
Шуңа әле бу җилнең
Зур кайгысы бар менә,
Ә кайгысын күрсәтми.
Чәчең сыйпап, җил исә.

Җилгә кайгың сиздермә,
Елама син, Гөлүсә!

## ДУСЛАРЫҢ ГЫНА БУЛСЫН

Егылсаң, торып була,
Торсаң, йөгереп була,
Йөгерсәң, җитеп була –
Дусларың гына булсын!
Сөйләшеп, уйнап була,
Күп нәрсә белеп була,

Шаярып-көлеп була –
Дусларың гына булсын!
Күңелле яшәп була,
Үсеп һәм ныгып була,
Дошманны егып була –
Дусларың гына булсын!

## МИН ҖИЛӘККӘ КИЛДЕМ

Мин урманга килдем үзем генә,
Бераз куркыныч та икән монда.
Шуның өчен менә һаман-һаман
Сызгырынып йөрим мин юлымда.
Миңа юлдаш кебек сызгыруым, –
Шул вакытта туктап тыңлап торам.
Һәм кайдадыр, юри мине үртәп,
Әллә инде кошлар сызгырына?!

Кошларга бит минем тигәнем юк,
Алар мине үртәп йөрмәс болай.
Йөри булыр анда минем кебек
Җиләккә дип килгән ялгыз малай.
Күрсәм икән хәзер шул малайны
Йә ул мине килеп тапса икән?!
Сызгырынып болай йөрмәс идек,
Җиләк җыяр идек хәзер икәү!

## ТАМЧЫ ТОТАМ

Тамчы тотам,
Тамчы тотам,
Тамчы, тамчы,
Тизрәк там.
Әни миңа
Әйткән иде:
– Тамчы ташны
    тишә, – диеп.

Минем учны
    тишә алмый,
Кара, ничек
Тора биеп,
Тамчы, тамчы,
Тизрәк там.
Тамчы тотам,
Тамчы тотам.

## ҖИРДӘ ҖАЙЛЫ

Качышлы уйныйсы иде,
Уйныйсы иде качышлы!

Әллә кая таралганнар
Малайларның барсы да.
Баш өстендә кояш калган
Һәм әрәмә каршымда.

Кояш белән дә качышлы
Уйнап була булуын,
Мине аннан яшерә ала
Яшел таллар толымы...

Миңа җирдә җайлы да бит,
Кояшка алай түгел...
Аның күктә таллары юк,
Үзе дә малай түгел.

## Ә СӘГАТЬ КЕЛТ-КЕЛТ ИТӘ

Йоклаган сәгать иде,
Сатып алдык кибеттән.
Хәзер тора өстәлдә,
Йокламый ул бик күптән.
Күрсәтә ул вакытны,
Соңармаска икәнне,
Кунакларга күрсәтә
Китәр вакыт җиткәнне.
Кайтыр чагын әтинең
Сөйләп тора әнигә.
Әйтә ашың пешкәнен,
Кайнаганын чәйнең дә.
Көн уза да кич була,
Өй эче йоклап китә.
Ә сәгать келт-келт итә,
Ә сәгать келт-келт итә.
Җәй үтә дә көз була,
Көз уза да кыш җитә.
Ә сәгать келт-келт итә,
Ә сәгать келт-келт итә.
Кибеттәге шикелле
Йоклар иде бер тагын,
Йоклама, дип, әтием
Көн дә бора колагын.

## АЧЫП КУЙДЫМ КАПКАСЫН

Алдым төсле каләмнәр,
Зур итеп өй ясадым.
Аннан
Бакча ясадым.
Бакчасында
Солы үсә,
Бодай һәм тары да үсә,
Ни кирәк – бары да үсә!
Алма, чия,
Карлыган!
Бай ясадым бакчасын.
Койма белән урадым да
Ачып куйдым капкасын.

Килеп керде
Кәҗәләр,
Килеп керде
Тавыклар,
Үрдәкләр һәм
Сарыклар...
Минем бакчага
Чират –
Әнә килә
Дүрт-биш ат,
Сыерлар
Тезелгәннәр.
Капка ачык икәнне
Кай ара сизенгәннәр?

Ярый инде, керсеннәр,
Миннән рәхәт күрсеннәр.

## ДУСЛАРЫМ

Өебез урман буенда –
Якты Идел ярында.
Каргалар да, чыпчыклар да
Минем белән дус монда.
Һәм җиләкләр, һәм чәчәкләр,
Дус каеннар, имәннәр –

Безнең капка янына ук
Мине эзләп килгәннәр.
Килеп чыга төлке дус та
Минем хәлне белергә.
Мин чирәмдә кырын ятам
Ак казлар белән бергә.

## ҖӘЙНЕҢ ЭССЕ ЧАГЫНДА

Абый кайтты кунакка
Җәйнең эссе чагында.
Сагынган ул мине дә,
Мәктәпне дә сагынган.
– Син укыган мәктәптә
Укыдым ич мин дә, – ди. –
Барыйм әле мәктәпкә
Синең белән бергә, – ди. –
Күптән инде күргән юк,
Беткәндер, – ди, – үзгәреп.
Булгач андый теләге,
Барсын әйдә ияреп...

Башта залны карадык,
Чыктык классны күреп.
Киттек бакчага кереп...
Рәхәт икән бакчада,
Чөнки монда күләгә.
Мин утырткан агачлар
Монда мине күмәләр.
Ә абыйны күммиләр,
Кояш ялый түбәсен –
Үзе агач утыртмый
Киткәнгәдер, күрәсең.

## ЯҢГЫРЛЫ КИЧТӘ

Күк – кара такта,
Ә яшен
      яза да
            яза гына,
Нокталар да куеп тормый
Сүзләрнең азагына...
Баш хәрефне
      табып булмый,
Юл хәрефен
      табып булмый,
Унда сузыла,
Сулда сузыла.

Сузыла
      ап-ак җөй генә.
Ак җөйдән
Булат курыккан –
      тәрәзәдән чигенә.
Ак җөйдән
Фоат курыккан –
      тәрәзәдән чигенә...
Күккә соң
Куркыныч сүзләр
      яза микәнни яшен?
Кирәк булыр бу хакта
Әти белән киңәшү.

## ТУК-ТУК!

Бик кечкенә
Куян булган,
Күңеле нечкә
Куян булган.
Урманда ул
Шуны күргән:
Агач шакып,
Тукран йөргән.
Бер агачка
Тук-тук иткән,
Икенчене
Шакып үткән.
Өченчене
Шакып үткән,
Дүртенчегә
Тук-тук иткән.
Күңеле нечкә
Йомшак куян
Бу тукранны
Жәлләп куйган.
Адашкан бу
Дип уйлаган.
Өен тапмый
Дип уйлаган.
Хәтта бераз
Елап алган.

## УЗУЧЫЛАР

Безгә якын юл буенда
Бер чишмә чыга.
Җитә аның якты суы
Һәр узучыга.
Узучылар бар да ятып
Салкын су эчә.
Шунда зәңгәр чиләгемне
Калдырдым кичә.
Зәңгәр чиләк үзе җиңел,
Кечкенә, дидем;
Шул чиләккә су тутырып
Эчсеннәр, дидем.
Узучылар иркен сулап,
Басып эчсеннәр
Һәм юлларын, сусамыйча,
Җиңел кичсеннәр.
Шулай дидем, чиләгемне
Шунда калдырдым.
Әткәй биргән чиләгемне
Суда калдырдым.
Бүген килсәм, узучылар
Ятып су эчә.
Мин бит сезгә чиләгемне
Калдырдым кичә!
Нигә инде, узучылар,
Шулай иттегез?
Минем зәңгәр чиләгемне
Кая илттегез?

## ХӘЙ КҮРШЕСЕ ХӨСӘЕН

Хәй күршесе Хөсәен
Хәйдән көлә көн саен:
«Әтиеңнән башка син
Ашый да белмисең! – ди. –
Әтиеңнән башка син
Сөйли дә белмисең! – ди. –
Әтиеңнән башка син
Йөри дә белмисең! – ди. –
Шуңа гел әтиеңә
Тагылып йөрисең!» – ди.
Күп сөйләшеп тормый Хәй,
Машинага утыра.
Әтисе
Машина йөртә,
Хәй карап кына тора.
Өйрәнеп кенә тора
Һәм аңлап кына тора.
Әле бермәл Хөсәен
Хәй янына утырыр.
Машинаны Хәй йөртер,
Хөсәен карап торыр,
Елмаеп бераз гына.
Хәй кабатлар көн саен:
«Машина йөртергә сине
Өйрәтимме, Хөсәен?»

## БАТЫР БУЛАТ

Башакларга эленеп, сары
көн өлгерде.
Комбайнчы штурвалны
улына бирде.
Уян, Булат!
Судан кайта классташың,
Чәчләрендә син яраткан
ал тасмасы.
Уян, Булат! Уян әле!
...Ул уяныр.
Яшәр Булат...
Үсәр Булат.
Эшкә барыр:
Комбайнга ул утырса,
кырың җитмәс.
Ул утырса машинага,
юлың җитмәс,
Чалгы алса, артык чабар
ун кешедән.
Бар авылны шаккатырыр
эше белән.
Киләчәктә исеме булыр
Батыр Булат –
Булат үзе күптән йөри
шулай уйлап.
Шулай уйлап, матур булып
үсеп килә.
Хәзердән үк батырларча
йоклый белә.
Һәм сызгырып бер җыр чыга
борыныннан:
– Болай булса,
Батыр
булмас-с,
булмас-с
с-сыман.

## КРОКОДИЛ КҮРДЕК

Кичә киногa кердек,
Кинода
Зур су күрдек.
Әйе,
Бик зур су күрдек.
Суда
Крокодил күрдек.
Крокодил да
Бик зур иде,
Күзләре дә зур иде,
Авызы да зур иде.
Ул туры безгә килде.

Сикереп куйдым
Урында –
Әти тотты кулымнан.
Чын түгел ич, кино бу,
Улым, курыкма, диде.
Хәтта безнең елгада
Крокодил юк ла, диде.
Анысын мин дә беләм,
Кечкенә безнең елга –
Безнең янга крокодил
Килеп чыкмасын өчен
Шулай кечкенә булган.

## БАРАМ

Кай якларда торасыз,
Җирдә ничә бала сез?
Нинди җырлар беләсез,
Нинди телдә сөйлисез?
Һәммәгезне сагындым,
Бер генә күрер идем –
Сезгә татарча шигырь
Сөйләп тә бирер идем.
Тик сез миңа килмисез,
Аралар ерактыр шул;
Инде миңа чарасын
Табарга кирәктер шул.

Бер җитез болан булып
Мин сезгә барыйм әле.
Кайсыгыз мине таныр –
Шуны да карыйм әле.
Йә сезгә барам әле
Пар канатлы кош булып,
Чыкмассыздыр каршыма
Ук алып та таш алып.
Чәчәкләр исен җыеп,
Җил булып барам сезгә,
Тәрәзәгезне ачып,
Кертсәгез өегезгә.

## ЮЛГА ЧЫККАН БЕР МАЛАЙ

Юлга чыккан бер малай.
Белмим, кая бара ул?!

Болай дидем аңа мин:
– Юлчы малай, син аң бул!
Юл уртасы тау булыр,
Тау артында су булыр;
Дулкыннар уяу булыр.
Су арты урман булыр,
Урманда аю булыр

Йә анда бүре булыр, –
Икенең бере булыр...

– Йә икесе дә булыр, –
Диде малай шул вакыт.
Шәп белә бу юл хәлен,
Булмас моны туктатып.

Күрәсең, ул чыныккандыр,
Әзерләнеп чыккандыр.

## БАЛА БАЛЫК

Балык әйткән
Баласына:
– Әкрен уйна,
Ипләп уйна!
Бала балык
Тыңламаган,
И сикергән!

И уйнаган!
Сикереп ялгыш
Чыккан ярга –
Ярый яңгыр
Килеп җиткән,
Коеп яуган
Һәм коткарган.

## АЛМА ТӨШКӘН

Алма төшкән,
Тәгәрәп киткән.
Аны мәче
Куып җиткән.
– Кая киттең,
Кызыл алма? –
Дип сораган
Мәче аннан.

Тәгәрәүче
Эндәшмәгән,
Тәгәрәгән,
Алга киткән
Һәм ул үзе –
Алма түгел,
Кызыл йомгак
Булган икән.

## ТОРНАЛАР

Торрыйк-торрыйк
Торналар
Китеп барганны күрдем.
Мин дә, торрыйк-торрыйк, дип,
Артларыннан йөгердем.
Торналар белән бергә
Мин очарга уйладым.

Талпынып та карадым –
Кулым канат булмады.
Булмады шул, булмады дип,
Мин кайгырып та алдым.
Очып китми калганыма
Әнкәй шундый куанды.

## АК КУЯН

Абыем каядыр җыена,
Мине генә ияртми.
– Җылы өйдә тыныч кына
Рәсем ясап утыр, – ди.
– Иярт, абый, ни күрсәм дә,
Кайткач ясыйм, – дип әйттем.
Чаңгы такканымны көтте,
Абый мине ияртте...
Тик ерак бара алмадык.
Бер генә куян күрдек.
Борыным өши башлагач,
Әйләнеп өйгә кердек...
Абыем: «Куян яса!» – дип,
Өстәлгә кәгазь куя.
Ничек ясыйм ди инде мин
Ак кәгазьгә ак куян?!

## КЫЮЛЫК

Җыелдылар малайлар,
Чаңгы табып бирделәр:
– Без кыюны яратабыз,
Әйдә, шуыйк бер, – диләр, –

Шунысын да онытма,
Биек, – диләр, – тавыбыз.
Шуа белми шуганнарның
Җимергәли авызын!

– Егылу ул – кызык эш,
Егылу ул – шәп, – димен.
Чаңгы шуа белмәвемне
Тегеләргә әйтмимен.

Менсәк тауның башына,
Калды башны кашырга.
Ничек кенә төшәргә соң,
Кем артына басарга?

Егылуың шәп эш тә,
Егылмавың да әйбәт:
Чаңгыларны кулга тотып
Төшеп киттем җәяүләп.

## ГАҖӘП КУНАК

Кар коела,
Куна өскә.
Куна кашка,
Куна күзгә.
Кар коела,
Кунак булып
Килә җиргә,
Килә безгә.
Гаҗәп кунак,
Күпме килеп,
Өмет итми
Безнең сыйны.
Бозы белән,
Кары белән,
Уен белән
Сыйлый безне.
Йортыбыздан
Үзен читкә
Чыгарсак та
Көрәп-көрәп!
Гаҗәп кунак,
Һаман сыйлый,
Һаман килә,
Һаман керә.
Агачларны,
Бакчаларны,
Газоннарны
Сыйлап йөри.
Мулдан булсын
Язгы сулар,
Матур булсын
Языгыз, ди.
Машинага
Төяп-төяп
Озатсак та
Күпме генә!
Гаҗәп кунак,
Үз вакыты
Җитмичә ул
Китми генә.
Шаярмагыз,
Кумагыз, ди.
Куна кашка,
Куна күзгә...
Кар коела –
Кунак булып
Килә җиргә,
Килә безгә.

## *1998*

# Хәкимҗан Халиков



Балалар шагыйре Хәкимҗан Шәяхмәт улы Халиков 1933 елның 16 гыйнварында Әтнә районы Мамыш авылында туа.

1948 елда Чембулат җидееллык мәктәбен тәмамлагач, Әтнә педагогия училищесына укырга керә. Училищедан соң беркадәр Иске Өҗем мәктәбендә укытучы булып эшли.

1954–1960 елларда читтән торып Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала.

1963 елда Казанга күчеп килә. «Ялкын» журналында, «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында, Язучылар берлегенең матур әдәбиятны пропагандалау бюросында, «Идел» альманахында, «Совет мәктәбе» (хәзерге «Мәгариф») журналында эшли.

Х.Халиков, нигездә, балалар өчен шигырьләр иҗат итә. Аның нәниләр өчен дистәдән артык китабы («Йолдызлар ничәү?» «Шук бабай», «Энәбикә», «Эшләпәле дуслар», «Канатлы куян» һ.б.) дөнья күрә.

1998 елда Х.Халиковка Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясе бирелә.

Хәкимҗан Халиков – 1973 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Ул 2002 елның 12 февралендә вафат була.

## ТӘТИ КЫЗ

Курчак белән дә
Сөйләшә Зилә,
Муйнак белән дә
Серләшә Зилә.
Каз да, үрдәк тә –
Бар да дус аңа,
Су буендагы
Тал да дус аңа.
Һәрчак нур булыр
Йөзендә аның.
Мактап үтәләр
Үзен дә аның.
Кайберсе, туктап:
– Кем кызы син? – ди.
Зилә аңарга:
– Бик кызык син, – ди. –
Әни кызы мин,
Әти кызы мин,
Дәү әнинең дә
Тәти кызы мин.

## ЯЛГЫШМАСКА ӨЙРӘНӘ

Сеңлем бүген: «Беләсеңме,
Бармакларым ничәү? – ди. –
Бер кулымда – берәү, икәү,
Өчәү, дүртәү, бишәү», – ди.

«Шуннан», – дигәч, «Шуннан алты...
Сигез... ун, – ди, бутала. –
Ялгыштым ла, җиде белән
Тугыз калган уртада...»

Кабат-кабат саный торгач,
Барысы да көйләнә.
Кат-кат шулай ялгышып, ул
Ялгышмаска өйрәнә.

## ЕЛАК-МЫЛАК

Булган, ди, бер
Елак-мылак,
Ертык колак.
Энеләрен
Уяткан, ди,
Иртүк елап.

Елаган, ди,
Ашаганда,
Эчкәндә дә,
«Эссе!» диеп,
Җылы җилләр
Искәндә дә.

Елаган, ди,
Чебен очып
Үткәнгә дә,
Аягына
Чебеш басып
Киткәнгә дә...

Елак-мылак
Әле һаман
Елый, имеш,
Елаганга
Ике күзе
Кылый, имеш.

## БӘЛӘКӘЙ ЕГЕТ

Әннә кирәк булса да,
Мәммәм кирәк булса да,
Йоклар чагы җитсә дә,
Авызыннан имезлек
Читкә төшеп китсә дә,
Елый башлый энебез.
Әйтерсең лә: «Миңа, – ди, –
Имезлекне бирегез...»
Юкка түгел елавы,
Шулай нидер соравы.
Ала шундук көлеп тә,
Тиздән әле ул безгә
Күрсәтәчәк йөреп тә:
Ул бәләкәй егет лә.

## ЭНЕМ ДӘ БИИ

Сеңлем бии башласа,
Аннан калмый энем дә.
Апасыдай, аның да
Ике кулы билендә.
Бии әле хәзергә
Утырган килеш кенә.
Ә шулай да инде ул,
Күр, ничек килештерә!

## АЛГА БАРА

Алдымдагы энемә:
«Җитте инде сиңа, – дим, –
Тәпи-тәпи йөр әйдә,
Әле дә, – дим, – соңардың...»

Төшү белән идәнгә,
Атлап китте тып та тып.

Хәзер инде һич кенә
Булмый үзен туктатып.

Күрәсезме дигәндәй,
Безгә карап ала ул.
Ава-түнә булса да,
Һаман алга бара ул.

## ХӘЗЕР ИНДЕ ӨЧӘҮ БЕЗ

Энем дә бар, сеңлем дә,
Хәзер инде өчәү без.
Шау-гөр килеп үсәбез,
Сокланырсыз, күрсәгез.

Әти-әни юк чакта
Өйгә хуҗа өчебез.

Җиткән кадәр көчебез
Бөтен эшне эшлибез.

Энем белән сеңлемә
Торасы юк әйтеп тә:
Курчакларын үзләре
Өйрәтәләр тәртипкә.

## ҮЗЕБЕЗЧӘ БҮЛДЕК

Иртән әни өчебезгә
Бирде ике мандарин.
«Үзегезчә бүлегез», – дип
Өстәп куйды аннары.

Берсен, тизрәк үссен диеп,
Энебезгә бирдек без.
Икенчесен сеңлем белән
Кыл урталай бүлдек без.

## ПОЧМАКСЫЗ ӨЙ

Тәртип бозсам аз гына,
Күрсәтәләр почмакны.
Анда басып торудан
Туйдым инде шулчаклы.

Минем дә бит сеңлем күк
Чатыр чабасым килә.
Кайчак хәтта бу өйдән
Чыгып качасым килә.

Белсәң иде: әтиләр
Шуны аңлыйлар микән?
Өйне нигә почмаксыз
Итеп салмыйлар икән?

## КАЙТАСЫ ГЫНА КИЛГӘН

Минем энем күптән түгел
Шәһәрдә булган иде.
Өч көн генә торса да,
Шулкадәр туйган иде:
Күңеле тулган иде.
«Сагындыңмы?» – дигәч, «Юк, – ди, –
Кайтасым гына килде.
Яшел чирәм өстендә
Ятасым гына килде...
Кайтасым гына килде».

## КОТЫРГАН БОЗАУ

Безнең бозау
Үскән саен
Котыра.
Төртте беркөн
Әнисенең
Ботына.

– Тиле, – дидем, –
Тик торганда
Нигә син,
Чабып килеп,
Әниеңне
Сөзәсең?!

Инде миңа
Акайтасың
Күзеңне.
Менә чыбык:
Кыздырам бит
Үзеңне!

## БӘЛӘКӘЙ МАШИНИСТ

Энем тора
Бигрәк иртә.
Инде әнә
Поезд йөртә.

Вагоннары –
Урындыклар,
Юлчылары –
Уенчыклар.

Яшь машинист
Энем исә
Гел сөйләнә
Иренмичә:

– Ти-та-та-та,
Ти-та-та-та...
Ерак юлдан
Поезд кайта.

Күп шәһәрләр
Аша үтеп,
Поезд кайта...
Тү-түт, тү-түт.

Уф-ф-ф,
Уф-ф,
Уф!

## ОХШАТКАН

Һашим беркөн урамда
Алма ашап йөргән, ди.
Аны чучка күргән, ди,
Шундук чабып килгән, ди:

– Кем чапылдата дисәм,
Һашим, син икән, – дигән. –
Син дә безнең шикелле
Ашыйсың икән, – дигән.

## ШАЙТАН ЧАКЫРА

Ашаганда беребез дә
Аяк селкеп утырмый.
Тик Инсафның аяклары
Беркайчан да тик тормый.

Дәү әнием: «Нигә шайтан
Чакырасың, бала? – ди. –
Килсә бит ул аягыңнан
Эләктереп ала», – ди.

Шайтанын да әйтер идем –
Нигә тизрәк килмидер?
Шул Инсафның аягыннан
Нигә эләктермидер?

## ҮПКӘЛИ

Каз каңгылдаса –
Казга үпкәли.
Сазлыкка батса –
Сазга үпкәли.

Ташка абынса –
Ташка үпкәли.
Авызы пешкәч –
Ашка үпкәли.

Чынга ала ул
Уйнап әйткәнне.
Һәркем котырта
Шуңа Әхтәмне.

## ЙОКЛАГАНДА ГЫНА

Бу энемне әйтәм әле:
Әнә нинди тыныч бит ул!
Урынын да үзе җыйгән:
Әнә нинди тырыш бит ул!

Беркем белән әрләшми ул,
Кычкырышмый, талашмый ул,
Сугыш чукмарлары кебек,
Йодрык белән аңлашмый ул.

Тик уяна күрмәсен, дип,
Күзләребез анда гына.
«Ник?» дисәгез, шундый бит ул
Бары йоклаганда гына.

## БИТЕН ЮДЫРТТЫ

«Юын!» – диеп,
Күпме әйтәм
Үзенә,
Энем һаман
Колак салмый
Сүземә.

Балга баткан
Битен тагын
Юмаган.
– Бер корт тәмам
Бәйләнде, – ди, –
Уңмаган.

Абый, нигә
Минем янда
Безли ул?
– Шапшакларны
Яратмыйбыз
Безз, – ди ул...

Битен юып,
Энем йөзен
Балкытты.
Тик шуннан соң
Очып китте
Бал корты.

## АГАЧЛАР ДА БЕЛӘ

Чыксам әгәр бакчага,
Җимеш суза һәр агач:
Чия суза чияләр,
Алма суза алмагач.

«Ник?» дисәгез, берсен дә
Корткычка тидертмәдем.
Сусаган чакларында
Суга да тилмертмәдем.

Шуңа күрә дә алар
Җимешне мул бирә шул:
Яхшылыкның кадерен
Агачлар да белә шул.
Менә шул!

## НИК СУКТЫ ИКӘН?

Юл буенда ялгыз каен
Башын игән нигәдер.
Яшенен дә әйтер идем,
Ник аңарга тигәндер?

Ә карт каен елый, мескен,
Карап җәйге урманга.
Яшен сукты микән аны
Әллә ялгыз булганга?

## МИН БЕРЕНЧЕ!

– Тик берәрләп җыйсам да
Тәмле каен җиләген,
Менә, дуслар, тулды да
Инде минем чиләгем!

– Ул качкалак җиләкне
Ничек бик күп таптың син?
– Ә син, Инсаф, авызга
Җыйгансыңдыр яртысын.

## ГӨЛДЕР БУ

Баласына
Нидер сөйли
Күгәрчен:
– Гөлдер-гү-ү,
Гөлдер-гү-ү,
Гөлдер-гү-ү...

Тик күз генә
Тимәсен, – ди,
Күрәсең:
Гөлдер бу-у,
Гөлдер бу-у,
Гөлдер бу-у.

## ЯЛ ИТ ИНДЕ

Күргәнем юк дәү әнинең
Тик утырып торганын.
– Ял ит инде, арыгандыр
Аякларың, кулларың...

Дәү әнием, кет-кет көлеп:
– Бетсен инде эшем, – ди. –
Беләсеңме, тиз картая
Эшсез торган кеше, – ди. –

Эш ул – миңа физзәрәдке,
Һич тынгылык бирми, – ди. –
Эшсез торып, минем тизрәк
Картаясым килми, – ди.

## ИСКӘРТТЕ

Ни арада бу кадәрле
Кечерәйгән күлмәгем?
Әни югач, мин бит аны
Тик бер атна кимәдем.

– Әнием, дим, кара әле,
Җиңе бигрәк кыскарган.
Моны кисәң, әллә ниләр
Ишетерсең кызлардан...

Дәү әтием җитди генә
Әйтеп куйды шуннан соң:
– Җиңең кыска булса булсын,
Кулың озын булмасын.

## МАҢГАЕНА ЯЗЫЛГАН

– Дәү әтием, нигә синең
Җыерчыклы маңгаең?
Минеке күк шома түгел,
Нигә шулай – аңламыйм?

– Ниләр генә күрмәдем мин
Башлап гомерем языннан!
Җыерчыклар булып шулар
Маңгаема язылган.

## ӨЙГӘ КЕРГӘЧ...

Өйгә килеп керүгә,
Әниемне күрүгә,
Энем елый башлады.
Әни эшен ташлады:
– Ник елыйсың? Ни булды?
– Кинәт таеп егылдым.

– Еладыңмы урамда?
– Күрше кызы булганда,
Ничек инде елыйсың:
Авыртса да чыдыйсың.
Юкса миннән Гөлчәчәк
«Елак!» диеп көләчәк.

## ТУКТАТТЫМ

«Аша», – дисәң дә елый,
«Йокла», – дисәң дә елый,
«Җитте сиңа, хәзер үк
Тукта!» – дисәң дә елый.

«Үсмәгән син, имезлек
Кирәктер син бәбигә», –
Дигән идем, елаудан
Шып туктады Әдибә.

## ЯТИМ ПЕСКӘЙ

Дер-дер итеп, урамда
Елый песи баласы.
Ташлап киткән нәниен:
Кансыз икән анасы.

Өйдә җылы сөт биргәч,
Елавыннан туктады.
Ятим пескәй аннары
Рәхәтләнеп йоклады.

## ТӨШӘРЕН УЙЛАМЫЙ

Өебезнең кыегында
Мияубикә: «Ми-яу-у», – ди.
Әйтерсең лә: «Төшә алмыйм,
Ярдәм итче, ми-яу-у?» – ди.

Баскыч белән менеп, шундук
Алып төштем песине.
– Пескәем, – дим, – бик иркәләп
Боздым, ахры, мин сине.

Минем кебек, җирдә генә
Нигә уйнамыйсың син?!
Менгән чакта төшәреңне
Нигә уйламыйсың син?!

## БАТЫР КЫЗ

Каз ысылдап килгәнен
Кинәт күреп алды да
Барып басты Тәнзилә
Энесенең алдына.

Шып туктады ата каз:
– Ка-га-га, – ди, – га-га...
«Син батыр кыз икәнсең», –
Диде, ахры, аңарга.

## КАДЫЙР

Балык каптырырга баргач,
Кабалана-кабалана
Кармак эзли кесәсеннән,
Кармалана-кармалана.

Каптырды да алды шулчак
Кармак аның бармагыннан.
Кадыйр исә: «Кара-вы-ыл!» – дип,
Чак ычкынды кармагыннан.

## ЧЫЕЛДЫК

Нәни тычкан Чыелдык
Озын бау тапкан, имеш.
Аны шундук
Койрыгына
Таккан, имеш.

Җирдә иң зур койрыклы
Хәзер мин булам, дигән.
Аның белән
Мәчеләрне
Буам, дигән.

Бау очыннан бер песи
Каптырып алган, имеш,
Һәм Чыелдык
Чак-чак исән
Калган, имеш.

Ярый әле койрыгым
Үзелде, дип сөенгән.
Ояла, ди,
Чыгарга да
Өненнән.

## ЛӘМ-МИМ

Шундый уен уйлап таптык,
Шуңа тып-тын өебез.
Өчебез дә, сөйләшмичә,
Әрле-бирле йөрибез.

Әни телгә килде шулчак:
– Үпкәләштегезмени?
Су капкандай, барыгыз да
Шуңа дәшмисезмени?

– Без бит, әни, сездән күреп,
Яңа уен уйныйбыз.
Сез сөйләшә башламыйча,
Сөйләшмәскә уйлыйбыз.

## *1999*

# «Сабантуй» газетасы

«Сабантуй» (1924–1990 елларда «Яшь ленинчы») газетасының бер генә саны да тәүге адымнарын атлаган көннәреннән үк язучы, шагыйрь сүзеннән башка чыкмады.

Аның иң актив авторлары арасында Муса Җәлил, Әмирхан Еники, Хатыйп Госман кебек күренекле әдипләр булды.

Шул вакытта ук алар газетаны балаларның иҗат мәйданына әвереллдерделәр.

Яшь хәбәрчеләрдән Мөхәммәт Садри, Зәки Нури, Шәрәф Мөдәррис, Гали Хуҗиев, Мәхмүт Хөсәен, Мифтах Вәдүт, Мансур Гаяз өлкән әдипләрнең күңел җылысы ярдәмендә соңыннан үзләре дә зур язучылар, шагыйрьләр булып киттеләр.

Элек-электән үк газетаның һәр санында шигырь, хикәя, әкият, публицистика урын алды.

Биредә гомер-гомергә журналист булып язучы-әдипләр эшләгән. Алар: Фатих Кәрим, Абдулла Алиш, Нури Арсланов, Ләбиб Гыйльми, Галимҗан Мөхәммәтшин, Ибраһим Салахов һ.б.

Аннары: Марс Шабай, Ренат Харис, Рөстәм Мингалим, Венера Ихсанова, Саимә Ибраһимова, Рәшит Әхмәтҗанов, Хәкимҗан Халиков, Әхәт Гаффар һ.б.

Аннан да соңрак елларда: Роберт Миңнуллин, Зөлфәт Маликов, Мөдәррис Әгъләмов, Камил Кәримов, Хәйдәр Гайнетдин, Нияз Акмалов, Эльмира Шәрифуллина, Ркаил Зәйдулла, Ләбиб Лерон, Сәйдә Зыялы, Вакыйф Нуриев, Госман Садә, Рафис Корбан, Фәйрүзә Мөслимова, Ләлә Гыймадиева, Йолдыз Шәрәпова, Алмаз Гыймадиев һ.б.

Шәүкәт Галиев, Ләбибә Ихсанова, Илдар Юзеев, Галимҗан Гыйльманов, Солтан Шәмси дә «Сабантуй»ныкылар – газетаның редколлегия әгъзалары булганнар.



Бу язучыларның күбесе бала чакларында
каләмнәрен иң әүвәл шушы матбугатта чарлаганнар,
ул алар өчен тәүге иҗат мәйданы булып торган.
Татар балалар әдәбиятына хезмәт итүчеләрнең саны
газетаның даими авторлары хисабына тулылана бара.
Күренекле балалар язучылары – бүген дә
«Сабантуй»ның иң актив авторлары.
Алар газета белән тыгыз элемтәдә яшиләр,
аның бүгенге укучылары өчен
яңадан-яңа әсәрләрен бастырып торалар.
Шуңа күрә татар балалар әдәбиятын үстерүдә ул әдипләрнең,
шул исәптән газетаның да роле бар.
Абдулла Алиш исемендәге бүләккә ия булган лауреатларны
үстерүдә дә, аларның иҗатларын пропагандалауда да
газетаның ярдәме зур.
Ул яшь иҗатчылар трибунасы буларак та
80 елдан артык эзлекле эшләп килә.
Бу – массачыл эш, аның һәр санында дистәләрчә бала
үзенең әдәби әсәре белән катнаша.
Иң уңышлыларын редакция
республикабыз нәшриятлары белән берлектә
китап итеп тә чыгара.
Балалар әдәбиятын пропагандалауда
газета бүген дә даими эшләп килә,
шәһәр, авыл мәктәпләре белән һәрчак элемтәдә тора.
Абдулла Алишның 90 еллыгы уңае белән
«Сабантуй» 1998 елны «Алиш елы» дип игълан итте,
газетада ел дәвамында шушы уңай белән язылган әсәрләр,
мәкаләләр бирелеп килде.
1999 елда татар балалар әдәбиятын үстерүдәге
игелекле эшчәнлеге һәм Абдулла Алишның тормыш,
иҗат юлын яктырткан өчен «Сабантуй» газетасына
Татарстан Язучылар берлегенең
А.Алиш исемендәге премиясе бирелде.

*2000*

# Ләбиб Лерон



Ләбиб Лерон (Лемон Лерон улы Леронов)
1961 елның 11 ноябрендә
Татарстанның Мөслим районы
Түреш авылында туа.
Бала чагы Актаныш районының
Олы Имән авылында уза.
Казан дәүләт университетының журналистика
бүлеген тәмамлый.
Хезмәт юлын «Яшь ленинчы»
(хәзерге «Сабантуй») газетасында башлый.
Аннары Татарстан Язучылар берлегендә,
Татарстан телевидениесенең балалар өчен
тапшырулар редакциясендә эшли.
1989 елдан – «Салават күпере» журналында
әдәбият-сәнгать бүлеге мөхәррире хезмәтендә.
Ул әдәбиятның төрле жанрларында
(шигырьләр, шаян хикәяләр, комикслар,
әкиятләр, пьесалар һ.б.) балалар өчен дә,
өлкәннәр өчен дә бердәй иҗат итә.
Аның балалар өчен «Яңгырның ял көне»,
«Транзистор үч ала», «Тәгәрмәчле чана»,
«Таһир маҗаралары», «Борчак шыттырам»,
«Кояшны кочкан малай» һ.б.
китаплары дөнья күрә.
Ләбиб Лерон – Татарстан Язучылар берлегенең
Ш.Маннур, Ф.Хөсни премияләре,
Татарстанның М.Җәлил исемендәге
Республика премиясе лауреаты,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.
2000 елда аңа балалар әдәбиятын үстерүгә
керткән хезмәтләре өчен
Татарстан Язучылар берлегенең
А.Алиш исемендәге премиясе бирелә.
Ләбиб Лерон – 1990 елдан
Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

## ТАТАР БАЛАСЫ

Калфак кигән кыз баланың
Багып алчы йөзенә:
Нинди гүзәл татар кызы! –
Күз тимәсен үзенә.

Килешеп тора түбәтәй
Аның күркәм йөзенә:
Нинди матур татар улы! –
Күз тимәсен үзенә.

Үзе тыйнак, үзе горур,
Хак сүз булыр әйткәне.
Яратыр газиз Ватанны,
Сөяр әткәй-әнкәйне!

Дәү булгач та шулай калыр –
Татар баласы булып.
Әйтерләр:
– Татар кызы бу!
Диярләр:
– Татар улы!

## ХӘЕРЛЕ ИРТӘ!

Әтәчтән дә иртәрәк
Уяндым мин, әлбәттә...
– Хәерле иртә, әннәм!
Хәерле иртә, әттәм!

Үзем урын җыям мин,
Үзем юына алам...
– Хәерле иртә, әбкәм!
Хәерле иртә, бабам!

Мәктәпкә үзем барам,
Калалар мине мактап...
– Хәерле иртә, апам!
Хәерле иртә, мәктәп!

## СИЗМИ КАЛГАНБЫЗ...

Җәй узмас диеп
Уйлаган идек:
Таңнан кичкәчә
Уйнаган идек.

Сизми калганбыз
Көз килгәнен дә,
Тәүге яфраклар
Өзелгәнен дә...

Әле һаман да
Сизмәс идек без,
Көзнең килгәнен
Белмәс идек без –

Кыңгырау чыңы
Искә төшерде:
Көзнең килүен
Шунда төшендек.

## КӨЗГЕ БАКЧАДА

Кагылмыймын алмаларга,
Чәчәкләрне дә өзмим.
Читтән генә сокланып, мин
Күзәтеп йөрим көзне.

...Әллә инде күзәткәнне
Сизеп, көз миннән качкан?! –
Алма булып елмая ул
Түрдәге алмагачта...

Алмагачтан ары таба
Атламадым карыш та.
Кай арада көз алмадан
Әйләнде көнбагышка?

Сап-сары чуклары җилдә
Җилферди дә җилферди...
Көнбагышын чүпли чыпчык:
«Миңа әзер җимдер», – ди...

Күрмичә дә калдым көзне –
Яшерде сары чаган...
...Көз, яфракка әверелеп,
Очты күрше бакчага.

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЕНДӘ

Дамир абый әйтеп тора,
Кабатлап бара Сара:
– Мин барам,
Син барасың,
Ул бара...

Кинәт Сара туктады да
Уңга, сулга карады.
– Аңламыйча калдым, абый,
Ә без кая барабыз?

## ҖИЛДЕРӘЛӘР, ӘЙ, АТТА...

Бу ни хикмәт-тамаша?!
Әллә ялгыш күрәмме? –
Җилдерәләр, әй, атта –
Кәҗә, Сарык, Шүрәле!..

Җилдерәләр шул атта
Балалар да, Акбай да...
Былтыр абзый: «На!» – диеп,
Көч-дәрт өсти бахбайга...

Әгәр күрсә бу хәлне,
Таң калып, тел шартлатып,
Тукай абый үзе дә
Торыр иде шаккатып!



## БАКЧАБЫЗДА БЕР БАЛА БАР...

Бакчабызда бер бала бар –
Шундый да ипле инде:
Кайчак әбием әйткәндәй,
Бигрәк тәртипле инде!

Малайлар һәм кызлар белән
Бик әдәпле сөйләшә.
Үзендә булган тәм-томны
Барсына да өләшә.

Көчсезләрне кыерсытмый,
Рәнҗетми ул кызларны...
Ялгыш кына орынса да:
«Гафу ит!» – ди, кызарып.

Уйнаганда ул һәммәсен
Көлдерә, шаккатыра.
Тәрбияче апабыз да
Гел аны мактап тора.

Ул баланың кем икәнен
Син белмисең, мин беләм:
Мактануны белми торган
Ул малай үзем булам!

## ПОРТРЕТ

Портрет ясау җиңел түгел,
Ярый әле мин оста:
Җәнлек-җанварлар рәсемен
Ясадым бер минутта!

Буявын да тиз буядым,
Кулым бер дә армады...
...Үземне дә ясый идем –
Урын гына калмады.

## БУТАЛМЫШ ИЛЕНДӘ

Буталмыш дигән илдә
Бервакыт булдым мин дә.
Һәм шунда йөргән мәлдә
Мин күрдем мондый хәлләр.

Анда кәҗә:
– Мияу! – ди.
– Му-у! – дип, мәче мияулый...

Сабый әйтә:
– Миhаhай!
– Мhау! Мhау! – ди бахбай...

Анда сыер:
– Мәм-мәм! – ди.
– Мики-ки-ки! – ди маэмай...

Ә бит бездә бүтәнчә.
Бездә:
Мәм-мәм! – ди мәче...

Туктале, буталдым мин,
Нәрсәдер бутадым мин.
Әйдә, син матур итеп,
Бир әле дөрес әйтеп!

## КЫЗЫК КЫШ

Кыш беткәндә... кыш килде –
Быел кыш кызык итте...
Кар яудыра-яудыра,
Кыш тәмам кызып китте!

Башта билдән булган көрт
Мине дә узып китте;
Койманы һәм мунчаны...
Өйне дә узып китте!

...Ярый әле кышның, дим,
Үзен яз кызык итте:
Кояш булып чыкты да
Бөтен карны эретте.

## БУ КАЙ ВАКЫТ? ӘЙТ, БАЛАМ!

*(Тукайга ияреп)*

* * *

Күз төпләрен угалап,
Кояш уянып килә...
«Кик-ри-күк! Торыгыз!» – дип,
Әтәч куанып көлә.
Кеше эшкә кузгала –
Бу кай вакыт? Әйт, балам!

*(Иртә)*

* * *

Сайрар кошлар «чут» та «чут»
Гөрләшә дә серләшә.
Агачларның яфраклары
Лепер-лепер сөйләшә...
Күктә кояш чайкала –
Бу кай вакыт? Әйт, балам!

*(Көндез)*

* * *

Ак болытлар, кызарып,
Еракларга юл ала.
Биек таулар артына
Кояш кереп югала...
Көн сүрелә кай ара –
Бу кай вакыт? Әйт, балам!

*(Кич)*

* * *

Тәрәзәдән ай карый,
Йолдызлар җем-җем яна.
Акрын гына, талгын гына
Тынлык иңә дөньяга...
Кеше йокыга тала –
Бу кай вакыт? Әйт, балам!

*(Төн)*

## РАДИОГА САЛКЫН ТИГӘН

Энемнең тавышы беткән –
Көч-хәл белән сөйләшә.
Салкын тигән. Шуңа күрә
Мәтрүшкәле чәй эчә.

...Беркөн безнең радиога
Нидер булды – сөйләми.
Чыжылдый шунда... Йөткерә –
Берничек тә көйләнми.

Нишләтергә инде моны
Әйбәт сөйләсен өчен?
Энем әйтә:
«Салкын тигән.
Мәтрүшкәле чәй эчсен!»

## КӨЯЛӘЙ

Бияләйгә көя төшкән,
Бияләйне көя тишкән...
Карап торам бияләйгә –
Әверелгән көяләйгә!

## ЙӨРИ ТОРГАН УРЫНДЫК

Әтинең киң җилкәсендә
Алмаш-тилмәш утырдык.
Энем әйтә:
– Син, әтием,
Йөри торган урындык!

## ГӨЛЛӘР РӘХМӘТЕ

Мин сокланып карап йөрим –
Бүлмә тулы гөлләр белән:
Сез ничектер, белмим, ә мин...
Мин аларның телен беләм.

Безнең кебек түгел инде –
Үзләренчә сөйләшәләр...
Елмаешып, бер-берсенә:
– Гөлкәем, – дип эндәшәләр.

Ал кояшка карыйлар да:
– Бүген көн бик матур! – диләр...
Алар шулай сөйләшкәндә,
Яктырыплар китә өйләр.

– Бик сусадык. Безгә тагын
Сулар сипче, Әхмәт! – диләр...
...Мин су сибәм. Алар миңа,
Чәчәк атып:
– Рәхмәт! – диләр.

## ЯЗ

Карлар эри ашыгып,
Кояш көлә шатланып...
Сездә ничек? Бездә яз
Килә атка атланып.

Томырыла тулпар ат –
Тезгеннәре бушаган...
Сездә ничек? Бездә яз
Сылу кызга охшаган.

Былтыр үткән эз буйлап
Кошлар кайта ашкынып...
Сездә ничек? Бездә яз
Сайрый белә кош кебек.

Бозлар ага тыз да быз,
Сулар ага җәелеп...
Сездә ничек? Бездә яз
Дәвам итә җәй булып.

## СЫЕРЧЫКЛАР

Җылы яктан очып килде
Сыерчыклар-кошкайлар.
– Исәнмесез, малайлар! – дип
Дәшә безгә дускайлар.

Куанышып сайрашалар
Кояшлы, аяз күктә.
Без аларга кул болгыйбыз:
– Оябыз әзер күптән!

## АПРЕЛЬ

Апрель, апрель...
Ярсып-кайнап,
Бозлар аккан ай да ул.
Апрель, апрель...
Җылы яктан
Кошлар кайткан ай да ул.

Апрель, апрель...
Чәчкәләрне
Сагынып көткән ай да.

Апрель, апрель...
Халкыбызны
Тукайлы иткән ай да!

Апрель, апрель...
Ләйсән яңгыр
Яуган тәүге яз ае.
Апрель, апрель...
Җан-тәннәрне
Иркәләгән наз ае!

## КОЯШЛЫ ЯҢГЫР

Ява яңгыр...
Күктә – кояш
Һәм салават күпере!
Йөзеп йөри ак болытлар,
Ак күбектәй күпереп.

Ява яңгыр...
Һәммәбез дә
Әй сөенә, шатлана.
Күк йөзендә алсу кояш,
Җирдә – яшел тантана!

Ява яңгыр...
Әй сибәли
Җәйнең җылы яңгыры.
Баш очында серле аһәң –
Төсле җырлар яңгырый.

## КЕМ КАЙДА ЯШИ?

Бүре яши абзарда,
Мәче яши өнендә.
Сарык яши урманда,
Ә төлке – безнең өйдә.

Юк, болай дөрес түгел...
Сарык яши өнендә.
Төлке яши абзарда,
Ә бүре – безнең өйдә.

Юк, тагын дөрес түгел!..
Мәче яши абзарда...
Уф!.. Ягез инде, берегез
Дөрес әйтеп бирегез!

## КАЗЛАР ҺӘМ БӘБКӘЛӘР

Каңгылдаша-каңгылдаша,
Казлар үлән йолкыйлар.
Ә бәбкәләр, тәмләп кенә...
Тәмләп кенә... йоклыйлар.

## НӘКЫЯ

Иреннәрен бөрештереп,
Ирек сызгыра белә.
Бармагын авызга кабып,
Барый сызгыра белә...

Ә үземне, үземне –
Әйтеп тә тормыйм инде!

Тик шулай да кайчагында
Мин бик уфтанып куям,
Җилләр чыгарырлык итеп
Бер сызгырса Нәкыя!

Шундый итеп сызгырырга
Каян өйрәнгән диген?!
Кемнән өйрәнгән диген?!
Кыз башы белән.
Бигрәк инде...
Һе.

## НӘНИ ДИМӘГЕЗ МИҢА

Нәни димәгез миңа!
Илләр турында уйлыйм,
Җирләр турында уйлыйм мин,
Гөлләр турында уйлыйм.

Нәни димәгез миңа,
Нәни димәгез.

Июньнең бер иртәсендә
Нигә ал таң атмаган?
«Көт. Кайтам», – дип киткән бабам
Ник сугыштан кайтмаган?

Нәни димәгез миңа,
Нәни димәгез.

Ишетәм мин кайлардадыр
Зар елыйлар нәниләр.
«Берүк сугыш булмасын», – дип,
Теләк тели әниләр.

Нәни димәгез миңа,
Нәни димәгез.
Шулар турында уйлыйм мин...
Нәни димәгез!

## КОЯШНЫ КОЧКАН МАЛАЙ

Шатланып әни көлә,
Шатланып әти көлә! –
Кояшны кочардай булып,
Тәпиләп малай килә...

Әнисен кочкан малай,
Әтисен кочкан малай...
Ямь-яшел бәбкә үләнен
Учына кыскан малай!

«Ән-нә-нә» дигән була,
«Әт-тә-тә» дигән була...
Кояшка кулларын сузып,
Елмайган, көлгән була...

Төштә генә булса да
Кош булып очкан малай...
...Тәпи-тәпи атлап килә
Кояшны кочкан малай!

## ҖӘЙ КӨТӘ БЕЗНЕ...

Урман, аланнар...
Иркен болыннар...
Чәчәк... Күбәләк...
Нәни колыннар...

Аяз күк йөзе...
Кояш нурлары...
Челтерәп ага
Чишмә сулары.

Хәтфә үләннәр...
Зәңгәр күл буе...
Малай-шалайлар,
Кызлар көлүе...

Яшел гүзәллек
Җилкетә безне:
Түземсезләнеп,
Җәй көтә безне!

## АКБАЙ БЕЛӘН КОЯШ

Бакчадагы агачларга
Акбай карап шаккаткан:
Алмагач та, чияләр дә –
Һәммәсе дә ап-актан!

Аптыраган моңа Акбай –
Исе киткән, таң калган:
«Кичә генә кар юк иде,
Кай арада кар яуган?»

Акбайга карап торган да
Кояш елмаеп әйткән:
«Кар яумаган, Акбай дустым,
Агачлар чәчәк аткан!»

## СОКЛАНГЫЧ ДӨНЬЯ

Соклангыч та соң бу дөнья –
Кояшы бар, ае бар...
Чәчәк җыеп йөри сыман
Аланлыкта каеннар...

Үләннәрнең баш очында
Уйный күгелҗем рәшә...
Яшел күктә, йолдызлар күк,
Җиләкләр җемелдәшә...

Күбәләкләр, бөтерелеп,
Чәчәкләргә куналар...
Ак тузганак болытлары
Офыкларга юл ала...

## МИҢЛЕГАТА «БОРЧАК АТА»

Әй мактана, әй мактана Миңлегата,
Авызыннан берөзлексез «борчак ата»:
– Курыкмыйм, – ди Миңлегата, – бернидән дә,
Курыкмыйм, – ди, – аюдан да, бүредән дә...

Әйтеп куйды аңа кемдер шул чагында:
– Ләкин, – диген, – янда әти булса гына!

## ҖИЛ КӨЙМӘСЕ

Ясадым мин ак кәгазьгә
Сап-сары күл рәсемен.
Күл түгел лә,
Чүл рәсемен!
Күрәсезме?!
Ә-ә-әнә сары
Чүл өстендә
Йөзеп бара
Кәгазь көймә...
Сары дулкын,
Сары эзләр,
Суырылып,
Арттан килә.

...Йөзә көймә.
Куркып куям:
«Җилләр күккә чөймәсме?»
Чөйсә чөйсен, димен аннан,
Ул бит чүл көймәсе.
Җил көймәсе!

## МӘЧЕ БАЛАЛАРЫ

Бу мәчеләр,
Әллә миннән күрмәкчеләр, –
Койма башына үрмәләп
Менмәкчеләр.

Соң...
Егылып төшсәләр
Йә
Башларын тишсәләр...
Аһ!..

Ни буласын әллә инде
Белмиләрме
Бу мәчеләр? –
Койма башына
Һаман
Үрмәләп менмәкчеләр.

Искә төшкәч
Әле генә,
Мин бит менә
Менми торам,
Ни буласын белеп торам.
Шуңа күрә
Эчтән генә
Мәчеләрдән көлеп торам:
Әтиләре генә күрсен –
Колакларын борачак бит,
Кызартканчы борачак –
Аңларлар әле шулчак!

## САБАН ТУЕ, САБАН ТУЕ...

Әгәренки-мәгәренки
Көтмәгәндә алай-болай
Очар тәлинкәдән ялгыш
Төшеп калса берәр малай...
Нинди булыр икән уе,
Күрсә безнең сабан туен?
Ничек алыр сулышкаен,
Күрсә әгәр ике малай
Капчык белән сугышканын?
Күзе челт-мелт итәр микән,
Күргәч чүлмәк ваткан чакны?
Тынсыз калып торыр микән,
Күргәч атлар чапкан чакны?
Ниләр уйлар, күрсә әгәр
Капчык киеп йөгергәнне,
Озын колганың очыннан
Чуар әтәч төшергәнне?
Олы-чага, кызый-мызый,
Авызына кашык кабып,
Шул кашыкка күкәй салып
Йөгергәнне күрсә әгәр,
Торыр микән хәйран калып?
...Нәп-нәкъ шулай булыр иде,
Миндәй хәйран калыр иде.

## АВТОБУШЛАР

Циркка бармакчы идек:
Торабыз тукталышта.
Буш автобуслар выж да выж
Узалар туктамыйча.

Әнә тагын бер автобус
Җилдереп узып бара...
Бу юлы да утыралмый
Калырбызмыни карап?..

Китте.
Мин тагын каранам:
«Килмиме автобуслар?»
Энем әйтә:
«Ә соң кая
киттеләр автобушлар?»

## *2000*

# Рәшит Бәшәр



Балалар язучысы Рәшит Бәшәр (Рәшит Гафар улы Бәшәров) 1949 елның 7 октябрендә Татарстанның Кукмара районы Яңил авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, ул 1967–1972 елларда Казан дәүләт университетында укый. Лениногорск районында укытучы, район газетасы хәбәрчесе булып эшли. 1979 елда Чаллыга күчеп килә. «Таң йолдызы» газетасында – әдәби хезмәткәр, «КамАЗ» газета-китап нәшриятында – редактор, «Аргамак» журналында җаваплы сәркатип вазифаларын башкара. Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршында оештырылган Югары әдәби курсларда укып кайта. Бүген ул – «Мәйдан» журналының җаваплы сәркатибе. Рәшит Бәшәр, нигездә, балалар өчен шигырьләр һәм проза әсәрләре иҗат итә. Аның «Әйлән-бәйлән», «Бәйрәм», «Яшел алан», «Ай кызының зәңгәр чиләге», «Сандугачлы бишек», «Ачык капка» һ.б. китаплары дөнья күрә. 2000 елда Р.Бәшәргә Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясе бирелә. Рәшит Бәшәр – 1985 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

# БӘБКӘЛЕ БОЛЫН

Алар мине әниләре
Диеп, ахры, beләләр.
Томшыкларын суза-суза
Пипелдәшеп киләләр.

– Йомшакларым минем! – дип
Эндәшәм үзләренә.
Сары кояш томшыкларын
Төртәләр тезләремә.

Ипи бирәм, су эчертәм
Һәм сыйпыйм йоннарыннан.
Көн буена берничек тә
Киталмыйм яннарыннан.

Әллә ничек моңсу итеп
Карап торалар күзгә.
Сыеналар бер-берсенә,
Пипелдәүләре үзгә.

Дерелдиләр, кинәт кенә
Салкын яңгырлар яуса...
Их, шунда әниләренең
Канат аслары булса!

Җылы мамыкка күмелеп
Черем итәрләр иде.
Тыңлаусызларын ана каз
Бераз битәрләр иде.

Юк шул инде... Юк шул инде
Тилгәннәрне куркытырлык
Бик батыр әниләре.
Әрекмән астына поса
Инкубатор бибиләре.

Пипелдиләр...
Бу аларның
Күз яшьсез үксүләре.

Бәбкәгә дә рәхәт түгел
Әнисез үсүләре...

## МЫШ-МЫШ

Рамил, Рузил һәм Ралиф
Рәсем ясыйлар мыш-мыш.
Бигрәк кызык кыланмыш!
Рамил бизәк уйламыш,
Ралиф бизәк ясамыш,
Рузил буямыш мыш-мыш...
Ралиф кашый колагын:
– Менә, Рамил, ал агын!
– Җитмәде бит, сал тагын!
Яшелгә ак өстиләр.
– Сыек яшел төс! – диләр.
– Бу төс безгә төс! – диләр.

Яшел урам, яшел өй...
Ишетелә яшел көй...
Яшел ташка утырып,
Яшел песи мыраулый.
Антенна, яшел башын
Яшел болытка тыгып,
Өр-яңа бер җыр аулый.
Бакчада яшел бабай
Яшел җирне бораулый.
Әллә кайда, тирәндә
Тонык кына су шаулый.

Тишелде җир...
Һавага
Чөелде яшел фонтан.
Рәсем инде юпь-юеш.
Юешләнде бөтен эш.
Су акты, акты, акты...
Сусыз калган стакан
Тәгәрәде... Диванның
Астына кереп ятты.

Рамил дә суны җыймыш,
Ралиф та җыймыш мыш-мыш,
Рузил үзе буялмыш,
Ямь-яшел рәсем булмыш,
Чиста песидән оялмыш.

Дивандагы ак песи
Борын очына тигән
Ямь-яшел тапны юмыш...

Малайлар өчәүләшеп
Борын тартмыш
Мыш...
Мыш...
Мыш-ш-ш...

## ТАНЫШУ

Күрсәтим дигән идем
Русча белгәнемне,
Әтәч тә аңламады:
– Привет! – дигәнемне.

– Ки-ке-ри-күк! – диде дә
Очты кунды киртәгә.
Акбай әйтә: – Татарча
Исәнләш, – ди, – иртәгә!

## БЕЗНЕҢ КАЙСЫБЫЗ КУНАК?

Мин капкадан керүгә,
Көчек каршы йөгерә.

Әби бар дип тә оялмый,
Үрелеп битне ялый.

И шатлыгы әбинең:
– Зур булгансың, бәбием!

Исем китте, нәнием,
Коеп куйган әниең!

Кулга коймак тоттыра,
Көчек кызыгып тора.

Аңа бирәм яртысын,
Коймак ашап тик ятсын.

Әби бар дип тә оялмый,
Кулдагы майны ялый.

Күзгә карап торале:
– Бар, – ди, – тагын сорале!

Тәмләп коймак ашыйбыз,
Аннан туя башлыйбыз.

Мин торып баскач кына,
Өйалды баскычына

Сыерчык килеп куна:
– Син, – ди, – өйгә кер, кунак!

Мин шуны торам уйлап:
Безнең кайсыбыз кунак?

Монда әллә мин кунак,
Әллә кунак Акмуйнак?

## ЯШЕН

Шалаш эчендә бабай
Әкият сөйли безгә.
Ялтыр-йолтыр ак яшен
Уйный чалгы йөзендә.
Акбай ята, баш куеп
Бабаемның тезенә.

Коя яңгыр чиләкләп,
Бер кызык итәр кебек:
Атны, арбаны, безне
Агызып китәр кебек.

Әкият сөйли бабай...

Әкияттәге җеннәр
Качып беткәндер инде,
Яшенсез җирне эзләп,
Чабып киткәндер инде.

Туктады яңгыр кинәт...

Йөгереп чыктым тышка.
И җиләкләр эреләр,
Киләләр йөгерешеп,
Минем зәңгәр чиләккә
Керәләр тәгәрәшеп.

Ямь-яшел аланнарның
Күтәреп пәрдә читен,
Бизәкле сөлге белән
Урманым сөртә битен.

Тамчы тама керпеләр
Кыштырдаган аланга.
Имән төбендә ак ат
Сөт имезә колынга.

# АТ

Болытлар – тугай-тугай.

Арба шыгырдый юлда,
Печәнгә бара бугай.

Арбада яту уңай,
Тугай-тугай болытка
Елмаеп карый малай.

Атының колагына
Куныйм микән, юк микән дип
Баш ватып тора тургай.

Ак болытлар янында
Тургайлар – тугай-тугай.

Үләннәр арасыннан
Челтерәп ага чишмә,
Ат иелә чишмәгә,
Малай арбадан төшә,
Ыңгырчак бавын чишә.
Тугара да ак атны,
Чалгысын ала кулга.
Кырмыскалар йөгереп
Чыгып китәләр юлга.

Кыздыра да кыздыра,
Шундый эссе ник җәй соң?
Керә арба астына,
Көне бераз суынсын.

Йоклый малай тәгәрәп.
Болыт йөри агарып,
Болыт йөри кабарып,
Офык чыга каралып.

Ак ат болытны күрә,
Малай янына килә.
Малайның ак күлмәге
Кабарып ята җилдә.

Әкият түгел, бу чын,
Ат арбага җигелә,
Тартып китә арбаны
Чапкан печән бар җиргә.

Җил чәчен дулкынлата,
Ә малай йоклап ята.
«Белми, ахры, оят та!»
Килә аты, уята.

Күзләрен ачса малай,
Болыт килгән каралып,
Яңгыр суы эчәм дип,
Болын ята таралып.

Арбада яшел печән,
Ак аты карап тора,
Малайның ак маңгаен
Кытыклап ялап тора.

– Мин печәнне җыйнадым,
Мин печәнне төядем.
Авыр булыр пычракта,
Әйдә кайтыйк өйгә, – дим. –
Арып киттем мин бераз,
Синең беләк егәрле.
Тартып кайт син арбаны
Тege үргә кадәрле.

Шаккатып кала малай,
Җил кабарта күлмәген.
«Бу кадәр суытасын
Белмәдем шул, белмәдем.
Салкын боз явып китсә,
Юлларны кесәл итсә...»

Нишләсен, малай күнә,
Арбаны тартып килә.

Ак атка кайту уңай.
Яшен яшьнәгән саен
Дерелдәп китә малай.

## ШӘҺӘР ТӨЗИМ

Мин яңа шәһәр төзим,
Ул шундый шәһәр булыр:
Чәчәкле урамнарда
Машина чабып торыр.

Шәһәрнең уртасыннан
Зур елга агып торыр,
Йөзеп арган көймәгә
Дулкыннар кагып торыр.

Бу шәһәрдә кошларга
Таш атмаслар малайлар,
Усал малайлар күреп
Шаккатмаслар агайлар.

Абыйлар һәм апалар
Бик-бик тату яшәрләр,
Бер-берсенә һәрвакыт
«Исәнме!» дип дәшәрләр.

Төзүче булыр әти,
Әни булыр тегүче.
Абый белән без икәү
Машиналар йөртүче.

Мин яңа шәһәр төзим,
Ул шундый шәһәр булыр:
Чәчәкләр, агачларга
Тамчы сибелеп торыр.
Чәчәкләр биеп торыр,
Гел «Рәхмәт!» диеп торыр.

## БҮРӘНӘ ҺӘМ БҮДӘНӘ

Тәгәрәгән бүрәнә,
Бүрәнәгә тәпиен
Кыстырган, ди, бүдәнә.
Этеп тә төртеп карый,
Селкенми дә бүрәнә.
Ул кычкырган тавышка
Йөгерәләр, күр әнә:
Ун күбәләк, бер торна,
Биш кырмыска, йөз бөҗәк.
Хәл җыйыйк та әзрәк,
Ярдәм итик тизрәк!
Этик тә бүрәнәне,
Чыгарыйк бүдәнәне!
Су бөркеде чишмәдән
Бүдәнәгә бер тирәк:
– Өлкәннәрнең сүзен гел
Истә тотарга кирәк.
Тыңламагач әнине,
Тыңламагач әтине,
Тәгәри шул бүрәнә.
И бүдәнә, бүдәнә,
Тәпиеңне сындырып,
Ятарсыңмы үләндә?
Ун күбәләк, бер торна,
Биш кырмыска, йөз бөҗәк
Этәләр бүрәнәне.
Селкенми дә бүрәнә,
И сызлана бүдәнә.
Чабып килде бер малай,
Күтәрде бүрәнәне,
Аннары торна тартып
Чыгарды бүдәнәне.
И сөенде бүдәнә!
Бүрәнәнең өстенә
Менеп басты бүдәнә.

Нишләр тагын бүдәнә,
Тәгәрәсә бүрәнә?

## БАЛ СУЫРТУЧЫ АЮ

Аю чыкты бакчадан.
Бабай чыкты бакчадан.

Аю тәпән күтәргән.
Бабай тәпән күтәргән.

Утырдылар чирәмгә.
Бабай көлә шаркылдап,
Сакалына җил бәрә.
Аюның колагында
Күбәләкләр тирбәлә.

Бабай әйтә аюга:
– Талчыккан идем, ярый
Син булыштың әле, – ди.

Аю әйтә бабайга:
– Бал суырткан чагында
Тагын чакыр, яме! – ди.

Тәпәннән алып, аю
Ак күмәчкә бал яга.
– Эшләп ардың, аша! – дип,
Күмәч суза бабайга.

## ӘКИЯТ СӨЙЛӘ

Кояш та керә өйгә,
Җилләр дә керә өйгә,
Керәләр дә әйтәләр:
– Әкият сөйлә!

«Шүрәле»не укыйм мин,
Аннары шып... туктыйм мин.

Инде хәзер нишләргә
Дип аптырап торганда,
Ярый әбием өйдә,
Әби килә ярдәмгә,
Әбием, көйли-көйли,
Җилгә әкият сөйли.

Йолдызлар керә өйгә,
Аннан ай керә өйгә,
Керәләр дә әйтәләр:
– Әкият сөйлә!

Зөһрә кызның үзен
Бик күрәсем килсә дә,
Аның ничек яшәвен
Бик беләсем килсә дә,
Әкият сөйли белмим,
Әби күк көйли белмим.
Мин кызык әкиятләр
Сөйли белмим дип инде,
Йоклаган әбиемне
Дәшеп булмый бит инде!

## НИШЛӘП БЕТӘРЛӘР ИНДЕ?

Балыклы күлне алар
Күптән белгәннәр иде,
Бүген дә, балыкка дип,
Иртүк килгәннәр иде.
Күл ярында суалчан
Эзләп йөргәннәр иде,
Яңа читекләр белән
Суга кергәннәр иде,
Инде берәр шыртлака
Эләктергәннәр иде.
Күренә иде судан
Читекнең чите генә,
Бүре кармагы эләкте
Төлкенең читегенә.
Өзелде дә китте җеп,
Ертылды читек кенә.
Сары төлке кайгыдан
Әз генә елап алды,
Бүре дә тик тормады,
Сузып бер улап алды.

Үкси-үкси бер-берсен
Юатыштылар аннан,
Читеккә шәп күн тапкач,
Куаныштылар аннан.
Читек текteләр озак...
Ә читекме? Өр-яңа!
Андый читекнең әле
Булганы юк дөньяда.
Сөенешеп йөрделәр,
Тагын суга керделәр.
Күренә иде судан
Читекнең чите генә,
Төлке кармагы эләкте
Бүренең читегенә.
Өзелде дә китте җеп,
Ертылды читек кенә.

Читек тегәрләр инде,
Нишләп бетәрләр инде?

## КАРТАЙГАН АТ

Тешләре булмаса да,
Ул солы ашый иде,
Мичкә белән елгадан
Суын да ташый иде.

Кояш астында бераз
Утласын, димәделәр.
Машинага салдылар,
Районга җибәрделәр.

Болынга чаба Акбай,
Иптәшсез нишләр инде?
Сагынудан арба да
Ат булып кешнәр инде.

Өзелеп карый юлга,
Берүзенә күңелсез.
Атны эзләп, офыкка
Чабып китәр, күрерсез.

## ТЕГҮЧЕ КЫРМЫСКА

Төлкегә күлмәк текте,
Бүрегә күлмәк текте,
Пошига күлмәк текте,
Йөзләгән күлмәк текте –
Тәмам интегеп бетте.
Сарафан да текте ул
Күбәләкнең кызына.
Күбәләкнең кызына
Бөтен алан кызыга.
И мактана күбәләк,
Бытырдый да бытырдый:
– Мин хәзер иң атаклы
Артисткадан матур, – ди.
Яфракка килеп куна,
Чәчәккә килеп куна:
– Сезнең күлмәк бизәксез,
Сез, чәчәкләр, бик ямьсез.

Кырмысканың өенә
Оча-оча килде ул:
– Күлмәк тегүче энә
Шушымыни? – диде ул. –
Бигрәк шыксыз икән лә,
Салкын тимер икән лә. –
Кырмысканың кулыннан
Тартып алып энәне,
Ыргытты ул идәнгә.

Телсез калды кырмыска...
Түзеп тормады энә,
Күбәләк киеп килгән
Күлмәкне тиште энә.
Елый-елый күбәләк
Ачу китерер микән?
Кырмыскадан әллә ул
Гафу үтенер микән?

## САНДУГАЧ

Оясын бер читкә аттылар,
Чаптылар куагын, яктылар.

Тракторлар җирне актарды.
Сандугач тирбәлгән якты гөл
Кызыл балчык белән капланды.

Елый-елый ятим сандугач
Күкләрдә ялгызы тирбәлә.

Сөртеп алыйм диме яшьләрен,
Күкрәгенә җылы җил бәрә.

Чәчәксез, болынсыз, куаксыз
Нишләргә,
нишләргә
аңарга?
Өзеп-өзеп бертын сайрады
Һәм кояшка очты
Янарга!

## ШОМЫРТ ТОТТЫ ЯКАДАН

Кара шомырт тәлгәше
Торгач бик ымсындырып,
Берәр ботагын алыйм
Дигән идем сындырып.

Тотты да алды шомырт,
Кысып тотты якадан:
– Каракланма яңадан!

Күтәрә дә төшерә,
Кычытканга чактыра.
– Килегез, – ди, – күрегез! –
Кешеләрне чакыра.

Рәшәткә ярыгыннан
Мәче керде йөгереп.
И селкетә мыегын,
Шаккатты мине күреп.

– Синең мондый икәнне
Белмәгәнмен, – ди, – элек. –
Чыкты сызды бакчадан:
– Тор инде, – ди, – эленеп.

Сузыла да кычыткан
Тәпиемне пешерә.
Ә шомырт мине һаман
Күтәрә дә төшерә,
Күтәрә дә төшерә...

## ТАГАН

Тирбәнеп тора таган
Тупыллар арасында.
Йөгереп барасың да,
Кочаклап аласың да
Атылып китәсең бер,
Мәтәлеп китәсең бер.

Ап-ак сакалын сыйпап,
Бабаем көлеп тора.
Бабайның да минем күк
Очасы килеп тора.

Килде, тотты кулымнан:
– Очарбыз, – ди, – кош булып,
Әйдә, атыныйк, олан!

Мин дә кош булам, диеп
Сөенеп куйды таган.

*2001*

# Җәүдәт Дәрзаманов



Балалар язучысы
Җәүдәт Харис улы Дәрзаманов
1945 елның 13 октябрендә
Татарстанның Лениногорск районы Сугышлы
авылында туа. 1964 елда Иске Шөгер
урта мәктәбен тәмамлагач,
Казан дәүләт университетының татар
теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала.
Аның шуннан соңгы хезмәт юлы
журналистика белән бәйле:
Татарстан радиокомитетында – балалар
тапшырулары редакторы,
«Ялкын» журналында – әдәби
хезмәткәр, баш редактор,
кабат радиокомитетта әдәбият-сәнгать
тапшыруларының баш редакторы.
Җ.Дәрзаманов балалар өчен
шигырьләр һәм проза әсәрләре яза.
Ул – дистәгә якын китап
(«Төнге маҗара», «Безнең әлифба»,
«Айбулат», «Серле янчык» һ.б.) авторы.
Татар балалар әдәбиятын үстерү
һәм пропагандалау өлкәсендәге
хезмәтләре өчен Җ.Дәрзамановка
1994 елда «Татарстанның атказанган
мәдәният хезмәткәре»,
2002 елда «Татарстанның атказанган
сәнгать эшлеклесе» дигән исемнәр бирелә.
2001 елда Татарстан Язучылар
берлегенең А.Алиш исемендәге
премиясе белән бүләкләнә.
Җәүдәт Дәрзаманов – 1982 елдан
Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

## КҮЛМӘК ЮАМ

Күлмәкләрем
Бер дигән,
Бизәкләре –
Бөрлегән.

Чупырдатып
Суларны,
Көн дә юам
Шуларны.

Юам,
Җилдә киптерәм,
Кардай
Ап-ак иттерәм.

Уңган син, ди
Курчак та.
Әй күңелле
Шул чакта!

## ЕЛАК КУРЧАК

«Ың-ңа», – дисең алсам да,
Бишегеңә салсам да.

Хәзер әзер еларга,
Битең юмый калсам да.

Һич кенә юк көлгәнең,
Шыңшу бөтен белгәнең.

Еламыйлар гел генә –
Елмайчы бер, Гөлгенә!

Шулай дигәч, курчагым
Елап җибәрде тагын:

– Син үзең дә беләсең,
Бик тә килә көләсем,

Тик иреннәр көлми шул,
Алар көлә белми шул.

Бар белгәнем зар минем –
Елаткычым бар минем.

– И курчагым, матурым,
Акыллым син, батырым,

Кил, дәвалыйм үзеңне,
Тик елама, түз инде...

Елаткычыңны алыйм,
Үзең йокларга салыйм.

Әтием кайтыр кичен,
Орышыр моның өчен.

Мин дә шулай чыдармын,
Чыдамасам... елармын.

Ә син, күрерсең менә,
Инде көләрсең генә.

## БҮГЕН ГЕНӘ ҮСКӘН, АХРЫ

Безнең Фәнил бик дәү инде,
Тиздән бишен тутыра.
Әнә, бармак бөгә-бөгә,
Нидер санап утыра:

– Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты,
Җиде, сигез, ун, унбер –
Өч кат саный, биш кат саный,
Санап чыга тагын бер.

Аптырагач: «Абый, абый,
Санап кара син дә, – ди. –
Бүген генә үскән, ахры,
Унбер бармак миндә!» – ди.

## ТАКЫЯ

Чәчәкләр өзә Гөлназ,
Такыя тезә Гөлназ.
Аны әнисе кияр,
Әй рәхмәт, кызым, дияр.

Назлар Гөлназны, сөяр,
Сөяр дә күккә чөяр...
Чәчәкләр өзә Гөлназ,
Такыя тезә Гөлназ.

## КҮКЕЛЕ СӘГАТЬ

Көмеш телле агач сәгать
Суга дың да дың итеп.
Аның матур тавышыннан
Бүлмә тора зың итеп.

Эчендә бар күкесе дә,
Бездән качып тик тора.
Сәгать тулгач, ишек ачып:
«Күк-кү!» – диеп кычкыра.

Агач башындагы сыман
Ул күкенең оясы.
Әллә шуның оясына
Йомыркалар куясы?

Безнең күке очып китмәс,
Утырыр, чыдар иде.
Йомыркалардан да шундый
Сәгатьләр чыгар иде.

Чыккан берен бусы белән
Янәшә эләр идем.
Аларның озын гомерләр
Юравын теләр идем

Әтиемә, әниемә,
Әбиемә, бабайга,
Миңа, сиңа, әнә теге
Соры күзле малайга.

Ә хәзергә ялгыз күке
Бездән качып тик тора.
Вакыт җиткәч, ишек ачып:
«Күк-күү!» – диеп кычкыра.

## САНЫЙ БЕЛӘМ

Бишкә хәтле
Саныйм мин,
Саннарны да
Таныйм мин.

Биш казыкта
Биш чүлмәк,
Биш малайда
Биш күлмәк.

Өйдә нәкъ биш
Кеше бар,
Бабайның биш
Теше бар.

Йолдызымда
Биш канат...
Саныйм мин
Кабат-кабат.

## СИН УСАЛ ТҮГЕЛ ИКӘН

Усал бабай диләр иде,
Ә син әйбәт икәнсең.
Тәрәзәмә нинди матур
Бизәк салып киткәнсең!

Без балык тоткан елганы
Күзгә кебек иткәнсең.
Күзгә кебек иткәнсең дә
Ялтыравык сипкәнсең.

Бабай, инде карт булсаң да,
Әле яхшы күрәсең:
Елак куян малаена
Ак тун тегеп биргәнсең.

Уңган икәнсең, Кыш бабай,
Бер төндә тау өйгәнсең.
«Нәни дусларым шатланып
Уйнасыннар», – дигәнсең.

Мин шул тауда чаңгы шуам,
Әй шуам – очам гына!
Колагымда җил сызгыра,
Күз иярми чаңгыма.

Усал бабай диләр иде,
Шаян бабай икәнсең.
Сизмәдем дә – битләремне
Алланганчы үпкәнсең.

## КАМЫРАЯК

Киеп алдым
Тимераяк,
Тик дерелди
Минем аяк.

Бозга чыгып
Басу белән,
Барып төштем
Башым белән.

Бер килсә, гел
Килеп тора –
Бер кыз үртәп
Көлеп тора:

– Тыңламый шул
Тимераяк,
Үзең булгач
Камыраяк...

## КӨРӘК

Бусы минем көрәк,
Кар көрәргә кирәк.
Һәр көн иртүк торып,
Йөрим сукмак ерып.

Бер эшләгән көйгә
Сукмак салам өйгә.
Әти киңрәк көри,
Аннан зурлар йөри.

Керсәм хәлем бетеп,
Әни тора көтеп:
– Улым, аш әзер, – ди, –
Ашап ал хәзер, – ди.

Ашы бигрәк тәмле,
Чәйдә бөтнек тәме.
Миңа көн дә шулай
Пешер, әни, яме?!

## ЯҢА ЧАНА ЯҢА ШУЛ

Яңа чана
Яңа шул,
Җилдәй җитез
Чаба шул.
Шуа,
Буран туздыра,
Башкалардан
Уздыра.
Шатлыгыма
Чама юк –
Моның кебек
Чана юк!
...Очтым беркөн
Үзеннән,
Утлар чыкты
Күземнән.
Яңа чана
Яңа шул –
Салса, «җайлы»
Сала шул.

## ҖЕПШЕК КӨНДӘ

Бүген иртән көн җепшеткән,
Кар явып үткән иде.
Без, малайлар, мондый көнне
Зарыгып көткән идек.

Йөгереп чыктык урамга,
Кар атышып уйнадык.
И уйнадык, и уйнадык,
Тик барыбер туймадык.

– Әйдә, – диде шунда кемдер, –
Кар бабай ясыйк бергә!
Вил чапты кишер алырга,
Нил йөгерде күмергә.

«Ә» дигәнче үсте бабай –
Үзебездән дә биек.
Эчкә сыймый шатлыгыбыз –
Киттек тирәли биеп.

Күмер күзләр янып тора,
Тап-таман чиләк бүрек.
Кар бабабыз җанлы кебек,
Китеп бармасын берүк...

## КУЯН БҮРЕК

Башында куян бүрек
Каралган уйнап йөреп.
Орышты соң әнисе,
Беркөн шул хәлне күреп.

Баскан җирдә таптанып,
Тәлгать тора акланып:
– Кечкенә зыян ла бу,
Соң, әни, куян ла бу!

Яз җитә ич, җәй җитә,
Менә шуңа күрә, – ди, –
Минем куян бүрегем
Соры төскә керә, – ди.

## ЯЗ КИЛӘ

Кыш белән
Яз-сылу,
Тартышып,
Көчләрен
Сынашып
Алдылар.

Кыш бабай
Җиңелде,
Тамчылар
Күз яше
Шикелле
Тамдылар.



## ТАШКЫН

Чатнап эз салды бозлар,
Чыңлап кузгалды бозлар,
Чәчеп зәңгәр чаткылар,
Зыңлый-зыңлый актылар.

Текә ярлардан ашып,
Язгы су чыкты ташып –
Киңәйтте барыр юлын,
Чын диңгез булды болын.

## ӨЧ ТАБЫШМАК

* * *

Тунын тегеп кимәгән –
Инә һәм җеп тимәгән.
Инә һәм җеп тимәсә дә,
Тунның йоны инәдән.

*(Керпе)*

* * *

Авызы юк,
Теше күп.
Озын, көзен
Эше күп.

*(Тырма)*

* * *

Югалмаган – таптыра,
Эзләтеп баш ваттыра.

*(Табышмак)*

## ӘБИЕМ СҮЗЛӘРЕ

Исеме балан булса да,
Баллы түгел ул балан.
Менә сиңа шул баланнан
Бәлеш салам мин, балам.

Пешеп чыккач, бәлеш йөзе
Алма кебек алланыр.
Татлы булыр баланы да –
Шикәр кебек балланыр.

## ЧИРТКӘННӘР

Башымны кыңгыр салып,
Торам хәйранга калып.
Хәйләкәрнең хәйләкәре
Балык дигән бу халык:

Тагын кызык иткәннәр,
Борыныма чирткәннәр –
Чиртә диеп торганда,
Җимне «чиртеп» киткәннәр.

## ҮЗЕМНЕ ТОТТЫ БАЛЫК

Кармакларны алабыз да
Салабыз яңабаштан:
Кызык булмас, колак каксаң
Килеп капкан балыктан.

Тарта бугай, калкавычым
Вак дулкыннар тарата.
Алмый торам, балык халкы
Алдашырга ярата.

Инде тартам, алып булмый,
Балык зур – мин кечкенә.
Ярга селтәп атар идем,
Җитеп бетми көч кенә.

Вәт балык бу!
Шундый тартты,
Куйдым да бер чайкалып,
Аяк таеп, дөмберт суга –
Үземне тотты балык.

## ҖӘЙГЕ ЯҢГЫР

Болыт-малайлар туп уйный,
Уйный бездән күрепме?
Әй тибәләр кызып-кызып
Күктә мамык бүрекне!

Бер наяны бигрәк җитез,
Чаба гына – ут кебек.
Типкән иде, туптан очкын
Чәчрәп очты ук кебек.

Шулчак нидер чатнады да
Челпәрәмә ватылды.
– Ур-ра, гол! – дип, шат тамчылар
Җиргә табан атылды.

Түбәләрдә тыпырдады,
Тыпылдады тактада,
Коймаларны шакып узды,
Шыбырдады капкада.

Шатланышкан тал, тупыллар
Шаулашып кул чаптылар.
Таштан ташка
Сикерә-сикерә,
Гөрләвекләр актылар.

## АЛМАЗ

Бер итеге уңга карый,
Берсе карый сул якка.
Уңын сулга бутап кигәч,
Кыендыр ул аякка.

Бияләй – ишле-сыңарлы,
Бүрек каплаган күзен.
Әллә малай, әллә кыз ул,
Танып та булмый үзен.

Танымаса танымаслар,
Алмаз сөенә генә:
Инде бүген икенче көн
Үзе киенә менә.

## ТЫЛСЫМЛЫ ЧҮКЕЧ

Үстең инде, улым, дип,
Эш өйрәнсен кулың, дип,
Әти чүкеч тоттырды,
Бер кадакка суктырды.

Суктым ике, суктым өч,
Дүртенчегә бетте көч.
Көч беткәнен сизептер,
Бармакка төште чүкеч.

Әти, сукса, нык суга,
Кадактан да ут чыга.
Каян килә мондый көч,
Тылсымлыдыр бу чүкеч.

## НУР ДӘҮ БУЛГАН

Бәбием, ди
Әби дә.
Сабыем, ди
Әни дә.
Син әле
Нәни, диләр,
Мә сиңа
Мәми, диләр.
Нур үпкәли
Әнигә,
Үпкәли Нур
Әбигә:
Дәү малайны
Һаман да
Ник саныйлар
Бәбигә?
Ник үртиләр
«Нәни» дип,
Яза белә
«Әни» дип.
Яза белгәч
«Әни» дип,
Нур дәү инде,
Әйе бит?

## СОЛДАТ БУЛДЫМ

Каеш будым билемә,
Тасма тактым җиңемә,
Йолдызлы бүрек кидем:
– Мин солдат булдым! – дидем.
Иңемә мылтык астым,
Әти каршына бастым:
– Килдем, иптәш командир,
Әйдә, берәр фәрман бир.
– Смирно! – ди әти дә, –
Печән ашат бәтигә.
Бераз утын ярырсың,
Аннан... суга барырсың!
– Була! – дидем кырт кына
Һәм борылдым фырт кына.
Шуннан китте, и китте...
Мине чын солдат итте.
Бетте ялкау гадәтем,
Санаулы һәр сәгатем:
Иртүк торам, юынам,
Сөлге белән уынам,
Ялт иттерәм тешләрне,
Аннан эшлим эшләрне.
Бүлмәмдә тәртип хәзер,
Ни кирәксә, шул әзер.
Солдат булу шулай ул,
Өйрәнгәч, бик уңай ул.

## НАЗА ЙӨРИ БАКЧАДА

Кояш күптән батса да,
Наза йөри бакчада.
Су сибә чиләк-чиләк,
Авыз эченнән көйләп:

«Чәчәкләрем ал булсын,
Бал кортына бал булсын.
Үзем эшлим барын да –
Әниемә ял булсын».

Сузылып бар буена,
Чәчәкләр су коена.
Зур тамчы китсә тиеп,
Куялар биеп-биеп.

## 2002

# Галимҗан Гыйльманов



Галимҗан Хәмитҗан улы Гыйльманов 1957 елның 1 февралендә Башкортстанның Дүртөйле районы Әсән авылында туа.
1974 елда – Әсән урта мәктәбен, 1979 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый.
Татарстан китап нәшриятында, Татарстан Язучылар берлегендә эшли.
Бүгенге көндә ул – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү бүлегендә баш референт.
Г.Гыйльманов өлкәннәр өчен дә, балалар өчен дә бердәй яратып яза.
Ул – 18 китап авторы.
Аның «Гөрләвек = Ручеек», «Йөгерек гөрләвек», «Әбием сихерче бугай» кебек шигырь җыентыклары да, пьесалар тупланган «Көмеш тарак» китабы да, күпсанлы повесть, хикәяләре дә («Язмышның туган көне», «Туган көнсез малай», «Чуар колак», «Бүләк» һ.б.), «Татар мифлары» томнары да, җырлары, әкиятләре дә укучыларга яхшы таныш.
Татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен Г.Гыйльманов 2002 елда Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясе белән бүләкләнә, 2003 елда аңа «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән исем бирелә.
Галимҗан Гыйльманов – 1992 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

# БҮРЕЛӘР ҺӘМ ИОҺАНН СЕБАСТЬЯН БАХ

## 1

Электричкадан төшкәч, Ленар станцияне уратып алган пыяла кибетләр янында озак юанмады, күршедәге Бүреле авылында яшәүче әбисенә күчтәнәчкә кипкән җимеш, ярты кило лимон һәм берничә кап чәй сатып алды да җәяүләп кенә олы юлга таба китте. Әбисе яши торган авылга автобус йөрмәгәнен белә ул. Кичә кич буе әнисе шул хакта сөйләде:

– Бүрелегә илтә торган юлга чык та бара тор. Барыбер бер машина куып җитә ул. Үзең генә йөрмә. Берәрсе белән сөйләшепкилешеп барыгыз. Юлны белмәссең... Соңгы елларда ул якта бүреләр дә ишәйде...

Ленар шулай итте дә. Скрипкасы салынган футлярын иңбашына җайлап элде дә юлга кузгалды. Юлдаш булырдай кеше эзләп тормады. Тукталышта да туктамады. Унынчы сыйныфта укучы егет өчен бишалты чакрым нәрсә ул?! Бер сәгатьтә кайтып җитәчәк, билләһи! Ай күрде, кояш алды булыр!

Чынлап та, ярты сәгать дигәндә ярты юлны үткән иде инде ул. Ашыкмады. Юл өслегендә уелып калган машина эзе буйлап барды да барды. Көн салкынчарак булса да, күктәге нурлы кояш күңелләрне җылытып, дәртләндереп тора. Җем-җем килеп яткан февраль кары да, дөньяга ямь биреп, күзләрне камаштыра, язга күп калмаганлыгы хакында шулай хәбәр итәргә тели, ахры...

Өч ел кайтканы юк инде Ленарның. Элегрәк ел саен, хәтта елга берничә мәртәбә кайтып килә иде. Хәзер вакыты юк. Хәзер ул скрипкада уйный. Музыка мәктәбен тәмамлап, узган көздә консерватория каршындагы махсус училищега керде. Әле шушы көннәрдә генә Мәскәүдә булып кайтты. Яшь скрипкачылар конкурсында катнашты, лауреат булды. Соңгы ике елы шуңа әзерләнеп үтте дә инде. Ул анда Иоһанн Себастьян Бахның скрипка өчен язылган сонаталарын уйнады. Аны Мәскәү консерваториясенең Зур залында аягүрә басып алкышладылар. Менә шул бәхетле музыканы әбисенә уйнап күрсәтәсе килде, шуңа күрә үзе белән скрипкасын да алды. Әнисе: «Салкында бозыла», – дип каршы төшсә дә, Ленар үзенекен итте, әнисен тынычландырыр өчен, инструментын йоп-йомшак, апак шәльяулыкка төреп салды. Менә хәзер дә, биләүдәге сабый кебек, йомшак, җылы шәл эчендә рәхәтләнеп ятадыр...

Ничек дип игълан иттеләр әле? «Татарстаннан Ленар Самат улы Вәлиев, Иоһанн Себастьян Бах сонаталарын башкарып, беренче урынны алды», – диделәр. Ленар сәхнә уртасына Татарстан флагын күтәреп чыкты. Кул чабарга керештеләр. Бу юлы зал Татарстанны, аның яшелле-аклы-кызыллы төсләрен алкышлады.

Ленар, микрофон янына килеп, рәхмәт әйтә башлады. Шунда алдагы рәтләрдә утырган берәү, саф татар телендә:

– Татарча әйт, татарча! Син бит татар малае! – дип кычкырды. Аңа тагын берничә кеше кушылды. Ленар бераз каушап калды, чөнки ул татарча белми иде. Элегрәк, авылга кайтып йөргәндә, әбисеннән бераз өйрәнгән иде өйрәнүен... Соңгы елларда кайтмый башлады шул. Ә элек белгәннәрен генә оештырып әйтә алмас, мөгаен. Шулай да бөтенләй дәшми калырга теләмәде Ленар.

– Рәхмәт... Мин... әни... әти... Татарстан... яратам... – диде ул кыюсыз гына. Шунда ук бер як читтәрәк, олы, затлы урындыкларында чумып утырган әти-әнисенә карады. Ничектер бәләкәйләнеп, басынкыланып калганнар иде алар. Бая гына талантлы уллары белән горурланып, күкрәкләрен киереп, башларын чөеп утырган ата белән ана бу минутта бәхетсез, хәтта шомлы-сагышлы кыяфәткә төшкәннәр иде.

Ленар аларга ике төрле хис-кичереш белән карады. Бер яктан, «Берәр ничек ярдәм итегез инде, бөтен ышанычым сездә» дип уйласа, икенче яктан, аның карашында «Нәрсә инде бу? Нигә мине татарчага өйрәтмәдегез?» дигән моңсу сорау пәйда булды.

Шунда ук күңелендә ныклы бер уй яралды: «Моннан чыгып, исән-сау Казаныма кайтып җитә алсам, икенче көнне үк авылга, әбекәй янына китәм. Бөтен дәресләрне, музыканы, кинәт ишелеп төшкән данны, котлауларны ташлыйм да... Кайтып киләм! Бер атнага, өч көнгә, бер көнгә булса да кайтам! Әбекәй белән гел татарча гына сөйләшәм, аңламасам, аңлаганчы сорашам... Ә өйдә... Өйдә берни барып чыкмаячак... Әти белән әни икесе генә калганда да русча сөйләшәләр, кая инде татарчага өйрәнү...».

## 2

Авылга ике чакрымлап ара калгач, олы юлдан, басуны кистереп, авылга табан тайпылып ат юлы төшеп китә. Ленар шул чатта туктап калды, икеләнеп уйланып торды. Олы юлдан китсә, юл катырак, әмма озынрак, ә чана юлына керсә, юл шактый кыскара, әмма кар измәсе аякларның буынын ала, атлауны кыенлаштыра...

Ленар авылга ат юлыннан төшәргә булды. Бу яклап кайтса, урамга кереп тормыйча, үзләренең ындыр артларына килеп чыгачак. Аннары... аны уң кулда кала торган әрәмәлек тә, магнит кебек, үзенә тартып, чакырып тора. Җәй көннәрендә малайлар белән шул әрәмәлеккә менәләр иде. Аннан арырак урман башлана. Анда сугышлы уйныйлар, җиләк, чикләвек, шомырт җыялар иде. «Бүре чокыры» дигән уйсулыкка гына якын бармыйлар. Әбисенең сөйләгәне бар. Кайчандыр ул чокырда бүре өне булган. Кешеләр шул өнне пыр туздырганнар, ата бүрене, аның балаларын үтергәннәр... Ана бүре генә бик серле юкка чыккан. Ни үзе, ни мәете табылмаган... Шуннан башлап авыл кешеләре әрәмәнең ул төпкеленә якын бармаска тырышалар икән...

Алдагы калкулык артында яткан басу ягыннан эт өргән тавышлар ишетелә башлаган гына иде, Ленарның күңеленә ниндидер билгесез, хәтта шомлы тойгы килеп керде. Ул бер сәбәпсезгә борчыла башлады. Авылга якынайган саен, балачакның дулкынландыргыч хатирәләре шулай җанын тынгысызлыймы, әллә Мәскәүдән ияреп кайткан авыр тойгылар баш калкытырга азапланамы?

Юктыр. Бу бөтән тойгы. Тойгы гына түгел, тоем, сиземләү... Гел шулай – тоем барыбер бервакыт чынлыкка әверелә. Бу юлы да шулай булды. Ленар уң якта караеп торган әрәмәлек белән тигезләшүгә, куаклыкның аргы очыннан, язгы су аккан кебек, караңгы тасма шуып төшә башлады. Ниндидер күк, хәтта чуар тасма... Әмма тере тасма!

Ленар, әрәмәлектән каршына бормаланып төшеп килүче бу тасмага карап, дөресрәге, аның сихри-зәхмәти шаукымына юлыгып, баскан урынында катты да калды. Ышанасы гына килми, ул инде тоя, хәтта төгәл белә: ниндидер ерткычлар өере бу. Этләр... Кыргый этләр... Ә? Бүреләр? Бүреләр шул... Әнә алар ак кыр өстеннән, рухи затлар кебек, тавыш-тынсыз гына «агып» килеп яталар. Бер-берләренә тагылган кебек атлыйлар...

Ленарның күңеленә шом керсә дә, курку тиз генә кереп җитмәде әле. Ул гүя бу мәлдә бер хәтәр төш күреп ята. Хәтәр булса да, төш кенә бит ул. Әллә... берәр начар кино карыймы? Әнә ап-ак экран... Күкле-

чуарлы тасма... Бүреләр өере... Кызык киләләр... Башларын аска иеп, карны сөзгән кебек, алга таба салулап киләләр... Күтәрелеп тә карамыйлар, ичмаса. Әллә... юлдагы кешене күрмиләрме? Алайса, нигә Ленарга таба киләләр соң алар? Өн шул бу, өн... Өн ләса бу! «Бүре өне»ннән чыккан өн! Бетте баш!.. Харап булды!..

Ленарның үз гомерендә бүре күргәне юк. Мондый хәтәр хәлдә калганы да юк. Шуңа күрә бу хәлдә нишләргә кирәген ул белми. Бүреләр дә белмиләр, ахры. Әнә алар туктап калдылар, борылып, авылга таба карап тордылар... Аннары, кабат үз юлларына төшеп, үз ниятләренә кайтып, Ленарга төбәп кузгалдылар.

Каккан казык кебек басып торучы Ленар ялт итеп артына борылып карады, таяныч эзләде.

Олы юлда беркем юк. Булса ни, йөгереп тә барып җитә алмаячак ул аңа. Нишләргә? Нишләсен инде? Көтәргә... Ходай Тәгаләгә ышанырга... Табигатьнең үз акылына ышанырга... Аз гына вөҗданы булса, ул Ленарны рәнҗетмәячәк, кыерсытырга да ирек бирмәячәк...

Кырык-илле адымнар кала бүреләр тагын туктадылар, күтәрелеп карап тордылар. Бу юлы, Ленарга төбәп, бездән котыла алмассың, үлемеңә әзерлән, дигән кебек карадылар. Тагын кузгалдылар. Юлга җиттеләр. Алдан килүче ерткычларның эрерәге шул юл уртасында кинәт туктап калды, аның артыннан килүче дүрт бүре, парлап-парлап, юлның ике як читенә урнаштылар. Ленар аларны аермачык күрә, хәтта шул яктан һәлакәт шаукымы булып килүче сихри дулкыннарны да тоя... Шулай да ул бераз тынычланды, зиһенендә бәргәләнгән уйлар да, билгеле бер эзгә төшеп, салмак кына йөгерешә башладылар.

Бүреләр шул ук этләр кебек икән. Ләкин алар гәүдәгә эрерәк, йоннары төрле якка тәртипсез тырпаеп тора. Иң хәтәре – бу ерткычларның башлары зур, яңаклары киң... Аларның азау тешләре көчле. Колаклары да мулдан, йөнтәс, килбәтсез... Болай да иләмсез чырайларына зәңгәрсу-күмер күзләре тагын да хәтәр төс бирәләр. Ленар аларны күрми, әмма... күрә дә! Ул күзләр аның җанын-күңелен өтеп ала торган, бәгырен чокып керә торган караш булып килеп ирешәләр.

Бүреләр тагын кузгалдылар, каршыга килә башладылар. Бу юлы тезелешеп түгел, һәрберсе үз юлы белән килә иде. Димәк, алар Ленарны һәрьяклап кысрыкламакчы, уратып алмакчы булалар...

Ленар үзе дә сизмәстән арткарак чигенде. Тик артка барып нишләсен ул?! Авылга да йөгереп кенә җитеп булмаячак. Шунда гомере өзелер микәнни? Кызганыч булачак... Яшь бит әле ул. Әле яши генә башлады. Өметле музыкант, диләр иде... Талантлы татар, диләр... Инде конкурста да җиңде... Жәл... Әбисе дә жәл... Үз ындыры артында оныгының бүреләрдән талануын белсә, аның йөрәге шундук меңгә ярылачак, билләһи, ярылачак... Юк, болай гына үләргә ярамый. Нидер эшләргә кирәк. Бүреләр нәрсәдән курка соң әле? Мылтыктан... Уттан... Уттан! Тик нәрсәне яндырырга? Скрипканы! Скрипканымы? Юк, үзе шушы урында җан бирсә бирә, әмма скрипкасына тимәячәк. Бу – изге скрипка. Унсигезенче гасырда ук эшләнгән уен коралы. Аннары... аның шырпысы да юк. Ленар, бу авыр хәлгә эләккәч, беренче мәртәбә сөенеп куйды: аның шырпысы юк!

Тагын нишләп була соң? Ни кылып була?

Шул вакыт Ленарның ерак күңел төпкелендә тыйнак кына бер хатирә калкынып куйды. Кайчандыр кемдер аңа кара урманда аюга очрап, гармун уйнап исән калуы хакында сөйләгән иде. Кыргый җәнлекләр музыка яратучан булалар икән; моңлы итеп җырлаган яисә уен коралында уйнаган кешегә тимиләр, имеш...

Ленар, тиз-тиз генә иңбашыннан салып, кулына футлярын алды. Җиргә чүгәләп, аны юл өстенә куйды, бигеннән бушатты, ачып җибәрде. Бияләйләрен салып, юл читенә атты. Күкрәк баласы кебек ак биләүдә ят-

кан скрипкасын иплəп кенə кулына алгач, бераз уйланып торды. Бүрелəргə таба күтəрелеп тə карамады, скрипкасыннан карашын җибəрмичə, смычогын үрелеп алды, аннары, аягүрə басып, акрын гына уйнарга кереште. Күңеленнəн генə, юк-юк, пышылдап кына, үзалдына игълан итте: «Иоһанн Себастьян Бах. Соναталар...».

Бераз уйнагач, ничек сез анда дигəн кебек, бүрелəргə күтəрелеп карады. Əнə алар юл өстендə тезелешеп утыралар. Шактый якынайганнар. Көй, музыка тəэсир итте микəн – өнсез булып, туктап калганнар. Бу яңгырашның чынлап та җан ияләренə шаукымы бар микəн əллə? Бардыр. Ерткыч бүре булып та бу кадəр илəслəнеп, исəнгерəп утырмаслар иде...

Кулындагы скрипкада, алай гына да түгел, үзенең йөрəгендə ниндидер сихри көч тоеп, Ленар тагын да дəртлəнебрəк, ярсыбрак уйнарга кереште.

### 3

Ленар уйнады да уйнады. Бүрелəр бүтəн якынаймадылар. Лəкин юлдан да китмəделəр, беркетеп, кагып куйган кебек утыра бирделəр. Əлегə аңлау мөмкин түгел – Бахның дəртле-ярсулы, əмма бераз усалрак музыкасы бүрелəрне шулай тынычландыргынмы, əллə тəмам куркытып, шомландырып җибəргəнме? Юктыр. Куркытырсың аларны... Əнə бит озын йоннарын кабартып, очлы, күмерле күзлəрен төбəп, йотардай булып утыралар... Берсе генə, кечерəге, яшьрəге, башын əле бер якка, əле икенче якка кыегайтып, үзенең кызыксынуын яшерə алмыйча гаҗизлəнеп утыра... Ə икенчесе башын күккə чөеп, борынын күтəреп, улаган кебек тора. Тик тавышы гына чыкмый. Əллə чыгамы? Скрипканың көчле аһəңе генə ишеттермиме?

Ленарның бармаклары өши башлады. Скрипка кылларында ничек кенə тиз йөгереп йөрсəлəр дə, алар, əкренлəп, берни тоймас хəлгə килделəр. Кемнендер «Бармакларыңны сакла, аз гына өшеттеңме – син инде скрипач түгел» дигəн сүзе исенə төште.

«Ник китмилəр инде болар, күпме уйнарга була?» – дип уйлады Ленар. Уйнап торган килеш, эченнəн генə бүрелəрне юлдан китəргə үгетлəргə кереште: «Барыгыз инде, китегез, үз урманыгызга кайтыгыз. Ə мине əбием көтə... Аннары... өшедем дə инде, бармакларым бик өшеде...».

Бүрелəр аның уйларын аңламадылар, күрəсең, бер-берсенə каранып, кузгалышып куйдылар да тагын, тынып, баскан урыннарында катып калдылар.

Ленар уйнавын дəвам итте. Ул Бахның бишенчеме, алтынчымы сонатасын уйный иде, тау артыннан, əбисе йорты ягыннан төтен баганасы күтəрелде. «Əбекəй миченə якты, берəр тəмле əйбер пешерергə йөри, ахры», – дип уйлап алды Ленар. Шунда гына ул үзенең иртəннəн бирле авызына берни капмаганлыгын исенə төшерде. Аның эчендə дə бүрелəр улый иде... Сəгать ничəлəр бар икəн? Соңдыр шул. Əнə бит карның җемелдəвеге беткəн, күк йөзендəге кояш эреп юкка чыккан, таулар артындагы офыкка эңгер пəрдəсе тарала башлаган...

Ленар тəмам арыды. Уйнап түгел, басып торып арыды. Аяклары да шакыраеп каткан, күрəсең, кузгатырлык та түгел. Кузгатырга ярамый да. Кузгала башласаң, теге зəхмəтлəр хəзер килеп җитəрлəр...

Əллə сөйлəшеп караргамы? «Сезнең алда минем бер гаебем дə юк», – дияргəме? Алай дип əйтергə татарча белми бит ул. Ə болар – татар бүрелəре. Алар татарча гына аңлыйлар... Ə-ə?! Димəк, алар музыканың да татарчасын гына үз итəлəр. Бəлки, əнə шул татар көен көтеп утыралардыр да. Кызганыч, Ленар бер татар көе дə белми... Халыкара конкурсларда классиканы гына уйнарга туры килəчəк, дилелəр. Шулай да Ленар бер көйне белə... Белə иде... Хəзер ничектер... Икенчеме, өченчеме сыйныфта укыганда, ниндидер бəйрəмдə ул татар көе уйнарга тиеш булды. Укытучылар аңа Тукайның «Туган тел» шигыренə язылган музыканы бирделəр. Бу əсəр

Ленарга бик ошаган иде. Ул аны, татар көе кирәк булганда, үскәчрәк тә уйнап йөрде. Күптән уйнаганы юк инде...

Ленар хәйләгә кереште. Үзе Бах сонатасын уйный, үзе, сиздермичә генә, Тукайның «Туган тел»ен кыстырып, ияртеп җибәрә. Шулай хәтерен яңарта. Әлегә әйбәт чыкмый, әллә хәтере томаланып киткән, әллә зиһене өшегән... Әллә туңган бармаклары тыңларга теләмиме?

Бергә уйнаганда, Бах музыкасы белән татар көе кызык чыга икән... Атаклы немец композиторы скрипка өчен аз язган. Аның әсәрләрен скрипкачылар сирәк уйныйлар, чөнки уйнау кыен. Бах көендә тавышлар күп. Аларны бөтен килеш алып бару өчен осталык кына җитми, күңел байлыгы да, җан тоемы да кирәк. Ә бит татарның үз көе дә – күптавышлы, бай төсмерле көй. Ленар шуңа да якын итте микән әллә ул Бахны? Ул бит татар малае. Ә татар кешесе Бахны әйбәт уйнарга тиеш, чөнки Бах та, татар да көйне бертөрле аңлыйлар... Кызык бу.

Ниһаять, Ленар «Туган тел»не исенә төшереп бетерде. Әлегә, Бах музыкасына кушып, кисәкләп кенә уйный иде, хәзер тулысынча уйнап-башкарып чыгачак. Шуннан беләчәк инде: бүреләр татар көен аңлыймы, юкмы?

Караңгылык иңә башлаган кышкы япанга моңлы татар көе тарала башлауга, бүреләр тагын кузгалышып куйдылар, хәтта тынгысызлана башладылар. Ленар гаҗәпләнүеннән җылынып киткәндәй булды: әллә чынлап та тәэсир иттеме? Фан-тас-ти-ка!

Көй, моң шундый серле, хәтта сихерле әйбер бит ул. Ялгыз гына яши алмый. Аңа сүз кирәк, мәгънә кирәк. Көйле, моңлы кеше бу көй-моңның сүзен, мәгънәсен дә искә төшерергә, андый сүз булмаса, аны үзе уйлап чыгарырга тиеш була. Ә «Туган тел»нең сүзләре бар! Тукайның бу атаклы шигырен Ленар төгәл генә хәтерләми. Әмма матур, мәгънәле шигырь ул... Йомшак, ягымлы гына башланып китә. Шундук күңелләргә сарылып керә башлый...

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы...

Бу моң, бу сихри моң ерткычларның да ерткычы, явызларның да явызы булып йөргән бүреләрнең күңеленә дә барып иреште бугай. Шулайдыр шул, аларның да күңеле бардыр. Алар да җан иясе. Ә җан иясенең күңеле булмый калмас. Әнә бит ничек мөкиббән китеп, башларын өскә чөеп, йотлыгып тыңлап утыралар... Нәрсә уйлыйлар икән, нәрсә кичерәләр икән алар бу минутта? Бу моң алар өчен югалту, сагышмы, әллә... Әллә киләсе язга якты өметме?

Ниһаять, Ходай Тәгаләнең сәгате сукты! Ходайның илаһи ишарәсе, ымы бүреләргә барып иреште. Менә алар, бердәм кубып, дүрт аякларына калкындылар, аннары, Ленарга карап, дөресрәге, багып, хәтта багынып тордылар да килгән эзләре буенча китеп бардылар... Күк-чуар тасма, шуышып, «агып», әрәмә ышыгына кереп киткәнче уйнады әле Ленар. Аннары, буынсыз калып, гөрселдәп, юл өстенә авып төште, скрипкасы бер якка, бүреге икенче якка очты...

Берникадәр вакыт хәрәкәтсез ятты. Күзләрен йомып, күңелендәге хис-тойгыларын берәмтекләп барларга кереште. Үләсе килде. Аннары кабат яшисе килде... Әбисе күз алдына килеп басты. Аның җылы миче... Җылы түшәге... Җылы карашы... Сүзе...

Ленар, аякларын яза-яза, көч-хәл белән торып басканда, җир өстенә караңгы төшеп беткән иде инде. Ул, туңган кул-бармакларына хәлсез, әмма җылы тынын өрә-өрә, тирә-якта чәчелеп яткан әйберләрен җыештыра башлады. Ул инде бүреләр хакында уйламый. Ул хәтта әбисе хакында да уйламый. Ул берни дә уйламый... Аның күңелендә бер генә хис, тойгы бар. Ул аның йөрәге, бәгыре кебек, җаны кебек... Үзе газапланып әрни, үзе сөенә:

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!

## *2002*

# Роза Хафизова



Балалар язучысы Роза Сәет кызы Хафизова 1929 елның 6 февралендә Татарстанның Бөгелмә шәһәрендә туа. Лениногорск районы Сарабиккол авылында – җидееллык һәм Иске Шөгер авылында урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1947–1951 елларда Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә югары белем ала. 1951–1952 елларда Төмән өлкәсенең Тобол шәһәрендә укытучы булып эшли. 1952 елдан лаеклы ялга чыкканчы хезмәтен журналистлык эше белән бәйли: төрле газета редакцияләрендә эшли, 1962 елдан «Ялкын» журналының баш редакторы була.

Роза Хафизова әдәби иҗатын тулысы белән балалар өчен проза әсәрләре язуга багышлый. Ул – ике дистәдән артык китап («Курай-малай маҗаралары», «Кирлемән», «Әкиятләр», «Ак тәпи ник моңая?» һ.б.) авторы.

Матбугат һәм татар балалар әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен Р.Хафизовага 1974 елда Татарстанның, 1983 елда «Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән исем бирелә. 2002 елда Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясе лауреаты була.

Роза Хафизова – 1984 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Ул 2005 елның 20 августында вафат була.

# КҮҢЕЛ КҮЗЕ

Ландышлар чәчәк аткан чакта, Камил әтисе белән урманга барды. Әтисе юлда ук кисәтте үзен: «Урман зур ул, серле ул, күңел күзе белән карасаң гына бөтен нәрсәне күрерсең», – диде. Камил көлеп үк җибәрде: «Кешенең күзе маңгаенда гына була, күңелнең күзе булмый, шаяртасың», – диде. Әтисе каршы килмәде. «Шулаен шулай, тик күңел күзе белән карамасаң, маңгай күзе берни күрми ул. Шуңа күрә борынгылар, маңгай күзе – ботак тишеге, дигәннәр», – диде.

Урман аларны тын гына каршылады. Биек-биек наратлар кымшанмый да утыралар. Камил өскә карады. Агач башлары сизелер-сизелмәс кенә селкенәләр, әйтерсең үзара ни турындадыр сөйләшәләр. Ә алардан да өстә – зәп-зәңгәр күк. Урман өстенә зәңгәр чатыр корганнар диярсең. Ни турында сөйләшәләр икән бу агачлар? Бик беләсе килә иде моны Камилнең. Ул, уфтанып, әтисенә карады. Әтисе зур шул аның, агачларның ни турында сөйләшүен дә аңлыйдыр. Камил түзмәде:

– Әти, агачлар ни турында сөйләшәләр? – дип сорады.

Әтисе үзалдына елмаеп куйды, улының башыннан сыйпады да туктап калды.

– Яле, икәүләп тыңлыйк! Әнә, ишетәсеңме? Агачлар безгә әйтәләр: «Рәхим итегез, хуш киләсез урманга, – диләр. – Тик агачларның ботакларын гына сындырмагыз. Чәчәкләрне төбе-тамыры белән өзмәгез, үләннәрне таптамагыз. Юкса урман корыр», – диләр.

Камил ышанырга да, ышанмаска да белмичә тыңлап торды. Агачлар шаулавын никадәр генә аңларга теләсә дә, булмады. Кәефе китте. Әтисе улын аңлый иде.

– Ә синең кәефең кырылмасын. Агачларның теле чынлап та юк, аларны аңлар өчен синең күңел күзең булырга тиеш, – диде.

Камил озак кына эндәшми барды, аннары кисәк әйтеп куйды:

– Әти, агачлар кошчыкларны, киек, җәнлекләрне кыерсытмаска да кушалардыр әле, әйе бит? – диде, аннары, әтисенә охшатып, баш бармагын өскә күтәрде. – Чү, әйдә, тагын тыңлыйк!

Шулчак нарат башыннан нәрсәдер шапылдап җиргә төште. Камил сискәнеп китте, әтисенә елышты. Әтисе көлеп җибәрде, кулы белән нарат ботагына күрсәтте:

– Әнә, күрәсеңме, тиен-шаян сикерә. Синең урманга килгәнеңне күргән ул. Танышырга тели...

Камил нарат кәүсәсенә сарышкан тиенне күреп алды. Нәни генә бер йомгак, койрыгы үзеннән дә зур. Тиен, үзенең җитезлеген Камилгә күрсәтергә теләгәндәй, бер ботактан икенчесенә сикереп уйнады. Аның уйнавын карап тору кызык иде. Әнә ул ал тәпиләре белән нарат күркәсен эләктереп алды да, әйләндереп-тулгандырып карагач, җиргә атты. Камил көлеп җибәрде.

– Тиен, мин сиңа тимим! – дип кычкырды. Аның тавышын ишетүгә, тиеннән җилләр исте. Камил аның кая китеп югалуын күрми дә калды.

– Ул үзенең иптәшләре янына китте, – диде әтисе. – Камил – яхшы малай, урман җәнлекләренә тими, дип әйтергә.

Камилнең моңа күңеле булды.

Урман эченәрәк кергән саен, берән-сәрән ландыш чәчәкләре очрый башлады. Камил сакланып кына берничә чәчәк өзеп алды. Тамырлары белән йолыкмады, күпләп тә өзмәде, юкса урманда чәчәкләр бетәчәк. Ә өзгәннәрен әнисенә алып кайтачак ул.

Йөри торгач, зур гына аланга килеп чыктылар. Аланның бер ягында – төз наратлар, икенче ягында ап-ак каеннар тезелгән. Әйтерсең лә, ап-ак күлмәкләрен киеп, кызлар түгәрәк уйныйлар.

Каеннар гаҗәеп матур иде. Камил түзмәде, алар янына йөгерде һәм йөгергән шәпкә кинәт туктап калды, аптырап әтисенә таба борылды. Ямь-яшь бер каен урталай каерылып сынган иде. Аның сынган урынында сап-сары булып каен суы каткан. Камил дә, әтисе дә каенны бик кызгандылар.

– Харап кына иткәннәр каенкайны, суын эчәргә теләгәннәрдер инде, ниндидер юньсез кешеләр узган моннан, – диде әтисе.

Камил, кызганып, каен кәүсәсен куллары белән сыйпады. Әз генә эчкәрәк узгач, тагын бер каен кәүсәсендә сап-сары катык күрделәр. Кемдер агачның кәүсәсенә балта белән чабып калын кирт ясаган, шул кирткә каен суы тулып каткан иде.

– Каеннар авыртудан елаганнар-елаганнар да, яшьләре шулай катып калган, – диде әтисе. – Әйе шул, шәфкатьсез кешеләр узган моннан, начар кешеләр.

Камилгә каеннар бик кызганыч иде. Ул, бер сүз эндәшми, озак кына уйланып барды.

Урман авызына җиткәч, киң ябалдашлы карт нарат төбенә ял итәргә утырдылар. Камил наратның иркенләп, җәелеп үскән ботакларына игътибар итте. Урман эчендәге наратларның ботаклары очларында гына ич, әлеге нарат үзе бер урман булып утыра. Улының бу соравы әтисенең күңеленә хуш килде.

– Урман эчендә агачлар бер-берләре белән ярышып үсәләр, кояшка үреләләр. Шуңа күрә аларның ботаклары өстә була. Аста ботак җибәрсәләр, аларга кояш төшми. Ә аларга кояш кирәк. Менә бу нарат берсе белән дә ярышмый, иркенләп үсә, – диде әтисе.

Шулчак бер нәни генә кошчык, Камилләр турындагы ботакка кунып, ярсып-ярсып чыркылдарга тотынды. Камилләргә караган да оча-куна, ачулана-ачулана чыркылдый. Камил белән әтисе тын да алмый кошны күзәттеләр.

Кош чыркылдады-чыркылдады да өске ботакка күчеп кунды. Шулчак аның янына томшыгына селәүчән эләктергән икенче бер кош килеп утырды. Әлеге ачулы кош үз телендә аңа нидер әйтте. Тегесе, башын боргалый-боргалый, бер Камилгә, бер аның әтисенә карады. Ачулы кош яңадан аскы ботакка төшеп кунды һәм баягыдан да усалрак итеп чыркылдарга тотынды.

Камилнең әтисе көлемсерәп куйды:

– Бу кош безгә моннан китәргә куша бит әле, ачулана. Мөгаен, бу агачта аның оясы бардыр...

Камил ашыгып әтисенең сүзен бүлде:

– Оясында балалары бардыр. Әнә, әти кош җим алып кайткан.

– Әйе, улым. Әйдә, башка җиргә күчеп утырыйк. Юкса алар балаларын ашатырга, якын барырга куркалар, оябызны туздырмагайлары, диләр.

Камилләр башка агач төбенә күчеп утырдылар. Кошларга шул гына кирәк иде дә, шундук чыркылдаудан туктадылар. Ата кош, җимен балаларына биреп, кире очып китте. Камил аларның ояларын күрергә теләп текәлеп караса да, күрә алмады. Кайтыр юлга чыккач, моны ул әтисенә дә әйтте. Әтисе, аны юатып, аркасыннан сөйде.

– Аның каравы урманны күңел күзе белән карарга өйрәндең. Ә кош оясын күрергә кирәкми дә, – диде.

## 2003

# Рафис Корбан



Рафис Корбан (Рафис Харис улы Корбанов)
1957 елның 1 гыйнварында
Татарстанның Дөбъяз (хәзерге Биектау)
районы Кече Битаман авылында туа.
Зур Битаман урта мәктәбен тәмамлагач,
Казан дәүләт университетының
журналистика бүлегендә укый.
Студент елларында балалар өчен шигырьләр
иҗат итә башлый.
Бүгенге көндә ул – унсигез китап авторы,
шуларның унбише балалар өчен.
Р.Корбан – шулай ук балалар театрлары
өчен дистәдән артык пьеса авторы да.
Аның «Куркуын җиңгән Куян»,
«Ак күлмәктә кара елан», «Бардым күлгә,
салдым кармак» пьесалары –
Татар дәүләт «Әкият» курчак театрында,
«Патша кызы һәм көтүче» пьесасы – Чаллы,
Түбән Кама, Уфа татар
«Нур» театры сәхнәсендә,
«Керпе малае дуслар эзли» һәм
«Кәҗә белән бүре» әсәрләре
Казан татар яшьләр театрында куелалар.
1993 елда Р.Корбан «Капкорсак» китабы өчен
Татарстан Язучылар берлегенең
Ш.Маннур исемендәге,
2003 елда «Куркуын җиңгән Куян» һәм
«Алмалы төн» китаплары өчен
А.Алиш исемендәге премиясенә лаек була.
2007 елда аңа «Татарстанның атказанган
сәнгать эшлеклесе» дигән исем бирелә.
Рафис Корбан – 1990 елдан
Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

# БАЛАЛАР БАКЧАСЫНДА КӨЗГЕ БАЛ

КАТНАШАЛАР:

Алып баручы.
Көз.
Балалар.
Борчак.
Чөгендер.
Кабак.
Сарымсак.
Кишер.
Бәрәңге.
Суган.
Кәбестә.
Кыяр.
Помидор.

Залга Көздән кала барлык катнашучылар да керәләр һәм урындыкларга утыралар.

Алып баручы.

Көз көннәре килеп җитте,
Хушлашабыз җәй белән.
Бөтен җиргә яфраклардан
Алтын keләм җәелгән.

Кулларына сары яфраклар тоткан
балалар уртага чыга.

1 нче бала.

Җылы якларга кошлар да китә.
Көз агачларны сап-сары итә.
Алар коела җил искән саен.
Җилферди җилдә сап-сары каен.

2 нче бала.

Сентябрьдә чәчәк аткан,
Көз димәгән кашкарый.
Җылыт әле дигән сыман,
Үзе кояшка карый.

3 нче бала.

Күрмичә дә калдык җәйне,
Үтеп киткән ни ара.
Баш өстеннән җылы якка
Торналар очып бара.

4 нче бала.

Җәйне шулай озатабыз
Торналар белән бергә.
Әйтерсең лә җәй үзе дә
Торнага әверелгән.

5 нче бала.

Каеннар бишек шикелле
Күренә туган якта.
Сары чыбылдык эчендә
Көзгә моң йоклап ята.

6 нчы бала.

Баш очыннан җылы якка
Кыр казлары очалар.
Каңгылдашып, көзге моңны
Уятыр төсле алар.

7 нче бала.

Уяттылар да шул инде,
Ямансу булып китте.
Киек казлар китә бит дип,
Күңелем тулып китте.

Алып баручы.

Китте җәй безнең яклардан
Диңгез, таулар артына.
Көз алтын күлмәк кидерде
Агачларның барсына.

Җылытмый инде кояш та,
Көннәр кыскара бара.
Әбиләр чуагы белән
Көз алдый безне бары.

Сибәли салкын яңгырлар,
Кургаш болытлар йөзә.
Җирне хакимлек итәргә
Тапшырган Ходай көзгә.

Көз турында җыр башкарыла.

Алып баручы.

Көз җитте дә көз җитте дибез. Ә Көз үзе кайда йөри икән соң? Бәйрәмегезгә һичшиксез киләм, дигән иде бит.

Шунда ул аяк астында яткан яфраклар арасыннан бер хат таба. Ачып укый.

Кадерле нәни дусларым!
Тәбриклим бәйрәм белән.
Озакламый мин дә сезнең
Бәйрәмегезгә киләм.

Бу хатны ачып укуга,
Кул чабыгыз гөр килеп.
Ишетеп шуны, бәйрәмгә
Җитәрмен мин дә килеп.

Туктале, бу бит Көздән килгән хат булды. Нәрсә дигән, кул чабыгыз, дигәнме? Шунда мин дә килеп җитәчәкмен, дигән. Әйдәгез, балалар, гөрләтеп кул чабыйк әле. Бәлки, чынлап та Көз, ишетеп, килеп җитәр.

Кул чабалар. Ишектә Көз күренә.

Көз.

Сез мине чакырдыгызмы?
Сез мине көттегезме?
Менә килдем. Исәнмесез!
Мин дә сагындым сезне.

Мин башлыйм бәйрәмегезне!
Әйдә, ясап түгәрәк,
Җырлыйк, биик, шигырь сөйлик,
Күңел ачыйк бергәләп.

Көз турында җыр башкарыла. Яисә «Яфраклар биюе»н биергә мөмкин.

Алып баручы.

Көз килә, Көзгә бал була дип, безнең балалар бик күп шигырьләр өйрәнде. Әйдәгез, шуларны тыңлыйк әле.

1 нче бала.

Әйдәле, Көз, кил, утыр,
Балаларны карап тор.
Без шигырьләр сөйләрбез,
Аннан җырлап бирербез.

2 нче бала.

Саргайды яшел бакча,
Сары яфраклар оча.
Көн дә яңгыр сибәли,
«Утырыгыз өйдә», — ди.

3 нче бала.

Болыт кашын җыерса,
Яңгыр белән куркытса,
Без аннан тиз качабыз,
Кулчатырны ачабыз.

4 нче бала.

Җиргә яфрак коелган,
Сап-сары келәм булган.
Яфракларны без җыярбыз,
Дәфтәр эченә куярбыз.

5 нче бала.

Бүген бездә матур бәйрәм.
Бүген бездә Көзге бал.
Бүген көзге байлык белән
Бизәлгән безнең бу зал.

6 нчы бала.

Бөтен җирдә яфраклар
Алтынланып яналар.
Тирә-якка хушбуй исе
Тараталар алмалар.

Көз.

Әйе, дуслар, килмәдем тик
Яфрак сибеп уйнарга.
Килдем тагын сезне көзге
Муллык белән сыйларга.

Күрәсезме, күпме байлык,
Күпме муллык табында!
Муллык булса, бәйрәмнәр бит
Күңеллерәк тагын да!

Көзге муллык турында җыр җырлыйлар.

Алып баручы.

Балалар, көзге муллыкның ни икәнен сез беләсездер инде. Көз көне басулардан җыеп алынган иген, бакчалардан җыелган яшелчә, җиләк-җимеш ул. Ә аларның безнең өчен файдасы бик зур. Безнең бәйрәмгә көзнең байлыклары үзләре дә килде. Әйдәгез, хәзер аларны тыңлыйк.

Борчак.

Мин – борчак, мине кешеләр
Кырга чәчеп үстерәләр.
Җыеп алгач көзен, миннән
Тәмле ботка пешерәләр.

Чөгендер.

Мин – чөгендер. Мин дә кирәк
Кешеләргә ашар өчен.
Борщ пешерер өчен һәм
Винегрет ясар өчен.

Кабак.

Таныйсыздыр инде мине.
Әйе, әйе, мин – кабак.
Минем тәмне белим дисәң,
Бәлешемне ашап бак.

Сарымсак.

Аш тәмләткеч ясар өчен
Сарымсак та бик кирәк.
Кышын мине дус күрсәләр,
Чирләүчеләр бик сирәк.

Кишер.

Көчле, җитез булыйм дисәң,
Кишер ашап кара син.
Кишер – саулык чыганагы,
Кишердә күп каротин.

Бәрәңге.

Мин – бәрәңге. Пешерсәң,
Мин тәмле булам бик тә.
Мине йөртәләр хәтта
Икенче икмәк дип тә.

С у г а н.

Ә мин – суган. Әрчегәндә
Килсә дә яшь күзегезгә,
Мине ашап, салкыннарда
Суык тимәс үзегезгә.

К ә б е с т ә.

Ә мин булам кәбестә.
Мин бик тәмле бәлештә.
Миннән щи пешерәләр
Йә голубцы төрәләр.

К ы я р.

Кыярны һәркем таный.
Кыяр салатка ярый.
Әгәр дә куйсаң тозлап,
Кыяр саклана озак.

П о м и д о р.

Ә мин булам помидор –
Төп яшелчә салатта.
Тәмле генә түгел әле,
Витамин күп томатта.

А л ы п  б а р у ч ы.

Хәзер барлык яшелчәләр
Түгәрәккә басабыз,
Әйлән-бәйлән әйләнәбез,
Җырлап күңел ачабыз.

Җыр башкарыла.

Б а л а.

Көз – моңсу чак, ямансу чак,
Көн дә ява яңгырлар.
Тик безнең бакчада һаман
Яңгырый дәртле җырлар!

# БАКЧАДА МӘКТӘПКӘ ОЗАТУ БӘЙРӘМЕ

КАТНАШАЛАР:

Алып баручы.
Чыгарылыш төркеме балалары.
Кечерәк яшьтәге балалар.
Китап.
Дәфтәр.
Карандаш.
Ручка.
Бетергеч.
Ранец.
Ялкаулык.
Хурлык.
Тырышлык.
Зурлык.

Тантаналы музыка яңгырый. Залга тамашачы балалар, әти-әниләр һәм чыгарылыш төркеме балаларыннан кала барлык катнашучылар кереп утыра.

Алып баручы.

Ничә ел инде менә
Майның шушы көнендә
Безнең матур бакчага
Мәктәптән хәбәр килә.

Безнең бакча балаларын
Укытучы апалар,
Беренче сыйныфка дип,
Укырга чакыралар.

Бүген менә аларны
Бергә-бергә, әлбәттә,
Тантаналы рәвештә
Озатабыз мәктәпкә.

Тантаналы музыка астында залга чыгарылыш төркеме балалары керә.

1 нче бала.

Бакча белән хушлашабыз.
Җиде яшь тулды безгә.
Мәктәпкә белем алырга
Барабыз быел көзгә.

2 нче бала.

Зуп-зур булып үстек инде.
Килгән идек берегә,
Өйрәнеп кенә килгәндә
Яңа тәпи йөрергә.

3 нче бала.

Хуш инде, безнең бакчабыз,
Тәрбияче апабыз.
Сезне мәңге онытмабыз,
Укучы булгач та без.

4 нче бала.

Безне анда мәктәп көтә.
Безне көтә парталар.
Түземсезлек белән көтә
Укытучы апалар.

5 нче бала.

Мәктәпкә — белем иленә
Баруыбызга без шат.
Серле белем дөньясына
Бүген бирелә старт.

Җыр башкарыла.

Алып баручы.

Безнең балалар мәктәпкә барырга бик ныклап әзерләнделәр. Алар инде хәрефләр дә таныйлар, унга хәтле саный да беләләр. Әйдәгез әле, хәзер аларның үзләрен тыңлап карыйк. Мәктәптә аларны ниләр көтә икән?

6 нчы бала.

Телибез хәреф танырга,
Алфавитны ятларга,
Хәрефкә хәрефне ялгап,
Сүзләр тезеп язарга.

7 нче бала.

Санарга да өйрәнербез,
Тапкырларга, бүләргә.
Исәпли белер өчен бит
Кирәк саный белергә.

8 нче бала.

Бик күп китаплар укырбыз,
Күп нәрсәләр белербез.
Үскәч кирәк һөнәрләрнең
Серен үзләштерербез.

9 нчы бала.

Ә хәзергә без боларны
Белмибез шул, әлбәттә.
Боларның бөтенесенә
Өйрәтәләр мәктәптә.

Җыр башкарыла.

Алып баручы.

Безнең балалар инде мәктәпкә барырга әзер, дидек. Әти-әниләре алар өчен инде уку әсбапларын да сатып алып куйган. Ә бүгенге бәйрәмдә әсбапларның үзләрен тыңлап китик әле. Алар укучыга нәрсә өчен кирәк икән?

Зал уртасына әсбаплар булып киенгән балалар чыга.

Бала.

Укучы өчен кирәкле
Әйберләр без, күрегез,
Китап, дәфтәр, көндәлек,
Карандаш һәм бетергеч.

Ранец.

Ә мин менә букча булам,
Ранец дип тә аталам.
Укучы өчен кирәкле
Бөтен әсбапны салам.

Дәфтәр.

Мин – дәфтәр, мин һәрвакыт
Кар шикелле ап-акмын.
Төрле дәресләр өчен
Булам юллы, шакмаклы.

Китап.

Ә мин – китап, мине сез
Буямагыз, ертмагыз.
Күп нәрсәләр белерсез,
Мине укып чыксагыз.

Карандаш.

Мин – карандаш. Мин кирәк
Рәсемнәр ясар өчен.
Югалтма мине, ташлама,
Сындырма, сакла очын.

Ручка.

Ә мин – ручка. Укучыга
Мин кирәк язган чакта.
Кимермә минем башымны,
Авызыңа да капма.

Бетергеч.

Рәсем ясаган чагында
Бетергеч тә бик кирәк,
Кирәкмәгән сызыкларны
Бетерергә тизрәк!

Алып баручы.

Әйе, балалар, озак та үтмәс, сез беренче тапкыр мәктәп бусагасыннан атлап керерсез. Сезнең өчен яңа, серле, могҗизалы тормыш башланыр. Ләкин белем алуны энә белән кое казу дигәннәр борынгылар. Ул бик күп тырышлык, көч куюны сорый. Ә кешене һәрвакытта да тискәре сыйфатлар да сагалап тора. Әйтик менә ялкаулык. Ә ялкаулык ул – хурлык. Тырышлык исә – зурлык.

Хәер, бу дүрт төшенчә бүген үзләре дә сезнең янга килгәннәр. Әйдәгез әле, аларның үзләрен тыңлап карыйк.

Уртага муеннарына «Ялкаулык», «Хурлык», «Тырышлык» һәм «Зурлык» дигән элмә язулар аскан балалар чыга.

Ялкаулык.

Мин – ялкаулык!
Минем белән
Дус булсагыз әгәр дә,
Килмәс бернишлисе дә!
Чаңгыда йөрисе дә,
Мәктәпкә барасы да,
Укыйсы, язасы да!

Хурлык.

Ул чагында сезгә бик тиз
Хурлык килер, балалар.
Ялкаулар һәрбер эштә дә
Хур булып кала алар.

Тырышлык.

Мин – тырышлык. Мин кешене
Эшләтәм эш беткәнче.
Һәрвакыт көч биреп торам
Максатына җиткәнче.

Зурлык.

Кем тырыша, кем гел эштә,
Алда бара укуда,
Шул баланы хөрмәтлиләр,
Дан шуңа, зурлык шуңа!

Алып баручы.

Менә күрдегезме инде, балалар, мәктәптә сезне тагын ниләр көтә?! Ялкауланып, дәрес әзерләмичә килсәгез, хурлык көтә. Ә тырышып укысагыз, белемле, акыллы кешеләр булып үсәрсез. Сезнең хакта бары тик зурлап кына сөйләрләр.

Ә без сезгә ышанабыз, балалар, сез безнең ышанычны акларсыз, бары тик «яхшы» билгеләренә генә укырсыз.

Бүген сезгә үзләренең теләкләрен әле бакчабызда калачак нәни дусларыгыз, энекәшләрегез, сеңелкәшләрегез дә әйтергә тели. Тыңлап карыйк әле.

1 нче бала.

Безнең кебек йөрсәгез дә
Бакчага гына бары,
Сез бит инде – чыгарылыш
Төркеме балалары.

2 нче бала.

Әниләр безне бакчага
Илткән чакта, тиздән сез,
Аркагызга ранец асып,
Мәктәпләргә китәрсез.

3 нче бала.

Мәктәптә яхшы укыгыз,
Тәртип бозып йөрмәгез.
Бакчабызның маркасына
Тап төшерә күрмәгез.

4 нче бала.

Көндәлеккә «бишле» белән
«Дүртле»ләр кайтсын тулып.
Үсегез илгә файдалы,
Белемле кеше булып.

Җыр башкарыла.
Чыгарылыш төркеме балалары сүз ала.

1 нче бала.

Тәрбияче апалар,
Нянялар, музыкантлар!

2 нче бала.

Рәхмәтебез сезгә чиксез.
Безнең әниләр күк бит сез!

3 нче бала.

Безнең шушы чәчәкләрне
Кабул итеп алыгыз.
Безнең күңелләрдә изге
Затлар булып калыгыз!

Балалар тәрбиячеләренә чәчәкләр тапшыралар.
Музыка яңгырый.

# ЧЕБЕН-ЧЕБЕНЧЕК

*(Әкият)*

*Корней Чуковскийдан*

Чебен-Чебен-Чебенчек!
Күбенгән күп чәй эчеп.

Чебен басуга чыккан,
Бер көмеш тәңкә тапкан.

Аннан базарга барган,
Самавыр сатып алган.

Чәй эчәргә аннары
Дәшкән тараканнарны.

Тараканнар төшкәннәр,
Стаканлап эчкәннәр.

Ә бөҗәкләр –
Өчәр чәркә
Эчкән сөтләп,
Клиндерләп:
Бүген Чебендә бәйрәм!
Авыз итегез чәйдән!

Килгән Чебенгә борчалар.
Читек алып килгән алар.
Читекләре әйбәт, затлы –
Бар да алтын каптырмалы.

Чебен янына
Бал корты килгән.
Аңа бер мичкә
Бал алып килгән...

«Күбәләк апа!
Аша кайнатма!
Безнең сый әллә
Ошамый мәллә?»

Кинәт шунда бер Үрмәкүч
Күренде.
Әй өстери ул бер читкә
Чебенне.

Мескенне үтермәкче,
Чебенне бетермәкче!

«Кадерле кунаклар, ярдәм итегез,
Явыз Үрмәкүчнең башын кисегез!

Ашаттым да сезне,
Эчерттем дә сезне,

Бәла килгәч кенә
Ташлап китмәгез!»

Ләкин кортлар-бөҗәкләр
Курыкканнар,
Бөтен ярыкларга кереп
Посканнар:

Тараканнар бар да диван
Астында,
Кандалалар сәке астында
Барсы да.

Караватастында бөтен
Борчалар –
Сугышырга теләмиләр
Һич алар!

Урыныннан да кузгалмый
Берсе дә.
Мескен Чебен һәлак булса,
Үлсә дә!

Ә Чикерткә сикерә,
Гел кеше инде менә.
Терт, терт, терт, терт! – элдерә

Басма астына,
Куак артына
Һәм шып-шым тына!

Ә явыз җан һич кенә дә шаяртмый,
Ул Чебеннең аяк-кулын богаулый,

Үткен тешен йөрәгенә батыра,
Аның канын суырырга тотына.

Әй кычкыра Чебен,
Шундый акыра.
Ә явыз җан дәшми,
Тик авыз ера.

Әллә кайдан гына шунда
Озынборын очып чыга,
Кулындагы фонарь белән
Үрмәкүчнең күзен чага.

«Кайда явыз? Кайда бирән?
Мин курыкмыйм ул вәхшидән!»

Үрмәкүчкә килә очып,
Чыгара үткен кылычын.
Очкан шәпкә ала айкап
Һәм төшерә кисеп башын!

Чебенне кулыннан ала,
Тәрәзәгә алып бара:
«Явызның башын кистем,
Һәм сине азат иттем.
Ә хәзер, җанашым минем,
Өйләнергә сиңа телим!»

Шулчак бөҗәкләр, борчалар
Сәке астыннан чыгалар:

«Яшәсен Озынборын!
Җиңүчегә мәрхәбә!»

Утлы коңгызлар, килеп,
Чыктылар фонарь элеп –
Китте дөнья яктырып,
Китте дөнья яхшырып!

Кыргаяклар, чабыгыз,
Музыкантлар табыгыз;
Килсен алар бирегә,
Без телибез биергә!

Музыкантлар килде чабып,
Бом! Бом! Барабаннар кагып!
Әй бииләр билен борып
Чебен белән Озынборын.

Ә Кандала, Кандала!
Ул чүгеп-чүгеп ала!

Кортлар белән суалчаннар,
Күбәләкләр һәм борчалар,
Мөгезле коңгыз-жуклар –
Капкорсаклы мужиклар –
Бииләр кызып-кызып,
Күбәләкләрне узып.

Трал-лә-лә, трал-лә-лә,
Чебен-черки мәш килә.

Бар да бәйрәм итә бүген –
Кияүгә чыга Чебен
Батырга, каһарманга,
Кыю Озынборынга!

Кырмыска, Кырмыска!
Ул да биергә оста, –
Үзе хатынын кочкан,
Борчага күзен кыса:

«Сез бөҗәкләр,
Сез бик шәпләр
Ки-ки-ки-ки-кибәкләр!»

Итекләре шыгырдый,
Үкчәләре тыпырдый, –
Кандала, Черки, Борча
Бәйрәм итәр таңгача.

Күңелле бәйрәм бүген –
Кияүгә чыга Чебен!



*2003*

# Илсөяр Сөнкишева

Илсөяр Гали кызы Сөнкишева
1928 елның 26 мартында
Татарстанның Әлки районы
Иске Салман авылында
Абдулла Алишның апасы
Закирә Алишева гаиләсендә туа.
Куйбышев (хәзерге Болгар) педагогия
училищесын тәмамлаганнан соң,
бер ел туган авылында укытучы булып эшли.
Аннары Казан дәүләт педагогия
институтының татар теле һәм әдәбияты
бүлегендә югары белем ала.
Казан шәһәре мәктәпләрендә
татар теле һәм әдәбияты укыта.
91 нче номерлы мәктәптә эшләгәндә,
Абдулла Алишның тормыш һәм
көрәш юлы белән якыннан кызыксына башлый,
А.Алиш музеен оештыра.
Аннары А.Алиш музее эшчәнлеген
55 нче номерлы мәктәптә дәвам иттерә.
Аның турында бай материал туплый.
2003 елда А.Алиш турында
«Алиш батыр да, язучы да» дигән
истәлекләр китабын төзеп чыгара.
Шул хезмәте өчен
Илсөяр Сөнкишева Татарстан Язучылар
берлегенең А.Алиш исемендәге
премиясенә лаек була.

*2004*

# Йолдыз



Йолдыз Әдип кызы Шәрәпова
1962 елның 10 апрелендә
Татарстанның Буа районы Яңа Тинчәле
авылында укытучы гаиләсендә туа.
Яңа Тинчәле урта мәктәбен тәмамлаганнан соң,
Казан дәүләт университетының
тарих-филология факультетында белем ала.
Хезмәт юлын «Ялкын» журналында
башлап җибәрә: әдәби хезмәткәр булып эшли.
1986 елдан балачактан хыялланган хезмәтендә:
«Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй»)
газетасында әдәби бүлекне җитәкли.
Йолдыз беренче шигырьләрен
башлангыч сыйныфларда укыганда ук яза башлый.
Ә ныклап, аңлап иҗат итүе «Яшь ленинчы»
газетасында эшли башлаган чорларда була.
Газета Йолдызга иҗат кыйбласын табарга ярдәм
итә, аны балалар шагыйрәсе итеп үстерә.
1994 елда Йолдызның «Антенналы бәрәңге»
дигән беренче китабы дөнья күрә,
һәм ул «1994 нче ел китабы» конкурсында
II урынны ала. Бүгенге көндә ул – биш китап
(«Антенналы бәрәңге», «Зоопарк-әлифба»,
«Шигырьле чәй», «Колаклы коймаклар»,
«Җавапсыз сорау») авторы.
Йолдыз – 2002 елда Татарстан журналистларының
«Бәллүр каләм» бүләгенә,
2004 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья
күргән «Колаклы коймаклар» китабы өчен
Татарстан Язучылар берлегенең
А.Алиш исемендәге премиясенә лаек була.
Йолдыз Шәрәпова – 1995 елдан
Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

## ӘНИ ХӘЙЛӘСЕ

Безнең әни хәйләкәр.
Вәт җайлы куша эшне.
Әйтерсең өйнең бар эшен
Без эшләргә тиешле.
Менә әле бүген дә,
Иң рәхәт ял көнендә:
– Энегезнең оекбашы,
Белмим, кая киткән? – ди. –
Кемнәр генә безгә аны
Табып бирер икән? – ди.
Ә үзенең кулында –
Чүпрәк, сулы чиләк.
Оекбашны эзләгәндә,
Белмим, алар ник кирәк?
Әй эзлибез, эзлибез...
Диван астын карадык.
Аны карау ярады –
Анда чүп, анда тузан –
Тузан явымы узган?!
Күреп хәйранга калдык.
Озак уйлап тормадык,
Себереп чиләккә салдык.
Һәр бүлмәне әнә шулай
Чыктык әйбәтләп карап.
Табылсын иде оекбаш,
Табылмаса – эш харап.
Әй эзләдек, эзләдек,
Мүкәләдек, тезләндек.
Идән юылып беткән,
Хәтта шуны сизмәдек.
Ә оекбаш табылды –
Шкафта качып торган,
Бездән идән юдырырга
Әнием хәйлә корган.

## ҖАЕН ТАПТЫМ

Әнием юлга җыена:
– Син өйдә калырсың, – ди, –
Юлым озын, син кечкенә,
Еларсың, арырсың, – ди.

Арысам соң, алҗысам соң,
Анысы инде минем эш.
Арысам да еламамын,
Әнием янымда ич!

Шактый озак баш ваттым,
Уйладым, җаен таптым –
Иң зур чемодан эченә
Җай гына кереп яттым.

Әнием юлга җыена,
Чемоданы да әзер.
Менә инде минсез генә
Китеп карасын хәзер.

## ЮАТУ

Тукталышта – нәни көчек,
Ташлап калдырган кемдер...
Күзләре – кара карлыган,
Карыйлар мөлдер-мөлдер.

Өебезгә алып кына
Кайтыр идем дә сине...
Әнием шул рөхсәт итми,
Ачулана ул мине.

Без үзебез дә торабыз
Әле тулай торакта.
Фатир алу чиратыбыз
Әле би-ик тә еракта.

Безнең бәләкәй бүлмәдә
Урын җитми беркемгә.
Алып кайтсам да үзеңне,
Тормас идең бер көн дә.

Менә яңа фатир алгач...
Бул азрак түземле...
Шулай юаттым көчекне.
Кем юатыр үземне?

## ГӨЛЛӘР САГЫШЫ

Ничә көн инде әнием
Шифаханәдә ята.
Энем тәмам аптыратты:
«Әни, – дип, – кайчан кайта?»

Әнинең өйдә юклыгын
Гөлләре дә аңлыйлар.
Нигә берсе чәчәк атсын,
Яфрак та ярмыйлар.

«Әни кайчан кайтыр?» – диеп,
Тәрәзәдә күзләре.
Башларын түбән игәннәр,
Бик ямансу үзләре.

Энем әйтә: «Әниемне
Гөлләре дә сагынган.
Ул өйдә юккадыр инде,
Яфраклары салынган».

Әнием өйдә булмагач,
Күңелсез бездә көннәр.
Су сибәр диеп кемнәр,
Сулып утыра гөлләр...

## ТӘМЛЕ ҖИЛӘК

Әнием гел әйтеп килде:
Эшләп ашарга кирәк!
Тәмле була икән бигрәк
Үзең үстерсәң җиләк. –
Берне генә дия-дия,
Ашый яздым бер чиләк.
Үзләре гел ал гына,
Тәмнәре гел бал гына.
Авызда ереп бетәләр,
Телләремә салуга.
Чынлап әйтәм, ошаттым.
Тәмле икәннәрен белгәч,
Күлмәккә дә «ашаттым».

## САТАБЫЗ

Юасы да күп аны,
Җыясы да күп аны –
Уйлаштык, киңәштек тә
Сатарга булдык залны.
Залсыз да яшәрбез әле,
Бездә тагы өч бүлмә бар.
Әби әйтә: «Сыясың ул,
Булмаса күңелең тар!»
Туйдык чынлап бу залдан,
Туйдык бетмәс тузаннан.
Әти моны ишеткән дә:
«Үзем сатып алам, – ди, –
Берегезне дә кертмимен,
Ишеккә бик салам, – ди. –
Идәнен үзем юам, – ди, –
Үзем сөртәм тузанын.
Ни теләсәм, шуны эшлим,
Була тик минем залым».
Әтием залны алгач,
Өч кенә бүлмә калгач,
Юасы да тиз булыр,
Җыясы да тиз булыр.
Әйдә булсын әтигә,
Безгә соң ул зал нигә?!
Бу – безнең уртак карар.
Абыем әйтә: «Ярар,
Бераз булса да җайсыз,
Яшәрбез әле залсыз...»
Энемнең күзе дымлы:
«Әтием, сүзең чынмы?
Бик кыен булыр залсыз,
Телевизор тора залда,
Ничек яшәрбез ансыз?»

## НӘРСӘ КЕМНЕ ҮСТЕРГӘН?

Кишер үстерә, диләр бит
Әтием дә, әни дә.
Кишер белән дуслаштым мин
Авылда дәү әнидә.
Чүп үләннәрен утадым,
Сулар сиптем кич-иртән.
Кай арада җәйләр үткән,
Китәргә вакыт җиткән.
Әни күргәч танымады.
«Ай кызым, – дип, – дәү үскән», –
Әнием дөрес әйткән.
Әйе, кишер үстерә
Ялкауланмый эшләсәң,
Беләгеңә көч керә.
Мин сипкән суны эчкән,
Күр, кишер ничек үскән!
Файдалы үтте ялым,
Чынга ашты хыялым.
Иң эреләрен сайлап,
Әби бәлеш пешерде.
Мин кишерне үстердем,
Кишер мине үстерде.

## ЭЗЛӘДЕК

Әтиемнең балачагы
Йөгереп чыксамы шуннан,
Ак болыт түбәтәй кигән
Наратлар арасыннан,
Күрсәтер иде ул миңа
Җиләк күп урыннарны.
Ул бит шунда туып үскән,
Яхшы белә урманны.
Куышыр идек бергәләп
Күбәләкле аланда.
Хәтфә печәнле болында
Ял итәрбез арганда.
Мин күп нәрсәне белмим бит,
Мин шул шәһәрдә туган.
Әтиемнең малай чагы
Йөгереп чыксамы шуннан?..
Өметемне өзмәдем,
Авылга кайткач, әтинең
Балачагын эзләдем.
Әтием дә эзләде,
Моңсу иде күзләре.

## БИЛГЕ

Укырга кердем быел,
Билге бәясен беләм –
Сумка тулы шатлык кайта
Өйгә «бишле»ләр белән.
Билге куям мин үзем
Өйдәгеләр эшенә:
Әби һәрчак «бишле» ала
Пешергән бәлешенә.
Энекәшемнең тәртибе
«Өчле»гә тарта чак-чак.
Киреләнә, үзсүзләнә,
Тыңламый шул ул кайчак.
Әти белән әнинең дә
Барлык билгесе «бишле».
Алар эштә дә эшлиләр,
Өйдә дә бөтен эшне.
«Бишле» алсаң, син – көчле,
«Бишле» түгел ул «өчле».
Ләкин белмим үземә
Нинди билге тиешне.
Аны белә тик әти,
Әмма әлегә әйтми.
Ышаныгыз сүземә:
Кыен икән ул билге
Куюы үз-үзеңә.

## ПЫЧРАНМАГАН

Урамда да,
Урманда да
Кышын ап-ак кар ята.
Энем кышны ярата,
Энем карны ярата.
Тотып карый
Кулы белән,
Татып карый
Теле белән,
Ятып ауный
Туны белән.
Үзе көлә, шаяра,
Ап-ак була кай ара.
Әйтәм инде:
«Ярамый!»
Ә ул аңа карамый.
Әйтеп булмый
«Шапшак» дип,
Пычранмаган –
ап-ак бит!

## ҖЫРЧЫ БОЛЫН

Мондый да матур, шәп болын
Безнең авылда гына.
Җырлый-җырлый инеш ага
Болын янывннан гына.

Чәчәкләр инешнең җырын,
Җәй буе тыңлап ятып,
Ятлап алганнар, күрәсең,
Мин дә тиз алдым отып.

Кыңгыраулар да кушыла,
Тотыналар чыңларга.
Сезне кунакка дәшәмен
Болын җырын тыңларга.

## БЕЛМӘМЕШ

Мин – Белмәмеш. Белмәмешне
Юктыр белмәгән кеше.
Белмәмеш булган малайның
Бик ансат аның эше:
Әниең эш кушкан саен,
«Белмим» диеп тик торсаң,
Ә үзең сиздерми генә
Төрле хәйләләр корсаң,
Ботинкаларың бавын да
Бәйли белмәсәң әгәр,
Өйгә файда китермәсәң
Тузан бөртеге кадәр,
Шундый була Белмәмеш.
Ләкин миннән көлмәгез!
Мин бит әле бик нәни,
Үзе шулай ди әни.
Үсәрмен, өйрәнермен,
Белмәмеш булмам һаман.
Акыллы Беләмәнгә
Әйләнермен берзаман.
Менә күрерсез!

## БҮЛӘК

Сигезенче март бүген.
Безнең өйдә зур бәйрәм.
Әти чәчәк бүләк итте
Әниемә бер бәйләм.

Әни миңа әкият сөйли,
Кулларында бәйләве.
Нигә көн дә булмый икән
Бу әниләр бәйрәме?!

Идәннәрне юды, аннан
Сулар сипте гөлләргә.
Бүгенге көн охшамаган
Бер дә башка көннәргә.

Мин нәрсә бүләк иттемме?
Бик шәп бүләк ясадым:
Сөтемне дә эчеп куйдым,
Боткамны да ашадым.

## ӨЙРӘТӘ ТОРГАН ИШЕК

Ай, иртән торулары!
Кем уйлап тапкан аны?!
Кичтән ятасы килми,
Иртән торасы килми.
Өлкәннәр аны белми.
– Әйдә, тизрәк тор, – диләр, –
Соңга калырсың, – диләр, –
Әйбәт билгеләр бетәр,
«Өчле» алырсың, – диләр.

Мин бик торыр идем дә,
Баш авыр чүлмәк төсле.
– Әни, карап бетеримче
Баягы матур төшне!

Азрак йоклап, азрак уяу,
Төш күреп аягүрә,
Барам юынгычка таба,
Бер атлый, бер йөгерә.
Әни кызулаганга,
Барганга бик ашыгып,
Аннан инде күзләр дә
Бетмәгәнгә ачылып,
Шык итеп бәрдем башны!
Вәт безнең ишек башлы!

«Күзең ач!» та димәде,
Хәтта ялгыш тимәде.
Уып торам башымны,
Күзләрем дә ачылды,
Ялкаулану чире дә
Шул минутта басылды.
Вәт нинди безнең ишек,
Өйрәтә белә ничек!

## КОЛАКЛЫ КОЙМАКЛАР

Апам коймак пешерде
Беренче тапкыр.
Коймаклары шундый тәмле
Һәм шундый... матур.
Майлы һәм баллы булганга
Яраттык коймакларны.
Ләкин алар гади түгел,
Бар нәни колаклары.
Кайсында биш, кайсында өч,
Кайберләрендә алты.
Колаксызлар бөтенләй юк,
Берсе ярты колаклы.
Майга буялды бармаклар,
Иреннәр, колаклар да.
Үзебез дә охшап калдык
Колаклы коймакларга.

## КӨНЛӘШҮ

Абый мәктәбенә бармый:
Авырый – суык тигән.
Нигәдер бүген минем дә
Чыгасым килми өйдән.

Өйдә бит ул җан рәхәте.
Чынлап әйтәм, дөресен.
Начар билге дә куймыйлар,
Белмисең дип дәресең.

Иншалар да язасың юк,
Юк шигырь дә ятлыйсың.
Җылы юрган асларында
Көннәр буе йоклыйсың.

Әниең дә гел янында:
– Улым, хәлең ничек? – ди. –
Мәтрүшкәле чәй кайнаттым,
Бал белән куй эчеп, – ди.

Шуңа минем дә мәктәпкә
Бүген килми барасым.
Килә минем дә авырып
Өйдә генә каласым...

Ярый әле калмаганмын,
Ярый шул, ярый бардым.
Беләсегез килсә, бүген
Иң-иң зур «бишле» алдым.

Әйбәт билгемне белеп,
Шатланганымны күреп,
Әнием дә бит очымнан
Пәп итеп куйды үбеп.

Абыем юрган астыннан
Моңсу гына эндәшә.
Беләм инде, хәзер ул
Үзе миннән көнләшә.

## АВЫЛНЫ САГЫНГАНДА

Кыңгыраулы колынны
Авылда күргәнем бар.
Муеныннан кочаклап,
Өстендә йөргәнем бар.
Ә шәһәрдә колын юк,
Ләкин бар бит... урындык!
Аңа кыңгырау тактым,
Менеп утырып «чаптым».

Кыңгыраулы булса да,
Колын түгел урындык.
Нигә безнең фатирда
Чын колынга урын юк?
Соравыма җавап юк,
Шунысы авыр.
Урындыгым чың-чың елый –
Сагындыра авыл...

## ӘНИ СҮЗЕ

Әни безгә еш кына:
«Зоопаркка илтәм», – ди.
Энем риза: «Әйдә соң,
Булмадык бит күптән», – ди.
Әни әйтә: «Бер илтсәм,
Тиз генә алып кайтмам –
Зоопарк җәнлекләренә
Охшаган сез бар яктан.
Әтәчләр күк сугышасыз
Ду килеп, өй туздырып,
Хәтта кылана беләсез
Маймылны да уздырып.
Ә хәйләгә килгәндә,
Төлкене дә җиңәсез.
Киреләнергә дигәндә,
Дәү мөгезле кәҗә сез.
Шуңа зоопаркка илтсәм,
Бик тә теләп алырлар.
Әле алай гынамы соң?!
Рәхмәт әйтеп калырлар!»

Әни безгә шулай дия.
Беләм инде, шаярта.
Бездән башка нишләсен соң,
Ул бит безне ярата.
Шаяннар, шуклар булсак та,
Түгел аңа без артык.
Ә шулай да җиткәндер шул
Кеше булырга вакыт.

## КАЛГАН ЭШКӘ КАР ЯВАР

Рәхмәт инде ак карга:
Рәхәт иде ул барда.
Бөтен дөнья ак иде,
Чиста иде, пакь иде.
Инде менә яз килде,
Эреп акты юрган – кар,
Чыкты аның астыннан
Өеме белән чүп-чар.
Урамнар шундый шапшак,
Атлап йөрибез чак-чак.
Көздән беркем җыймаган,
Җыярга уйламаган.
Без ялкауларны күреп,
Кар яуган, куйган күмеп.
Көзен эш күпне белгән,
Безгә ярдәмгә килгән.
Инде менә кар бетте.
Чүпле җирне үзебезгә
Җыярга вакыт җитте.
Әгәр тагын җыймасак,
Күреп шушы чүп-чарны,
Бәлки, кабат каплап китәр,
Белеп булмый бу карны...
Юк инде, кар кирәкми,
Алдык кулга көрәкне,
Икенчесенә тырма –
Эшлә син дә, тик торма!
Эшли әби-бабайлар,
Эшли әти-малайлар,
Нык тырышалар бар да,
Эш калдырмыйк дип карга!

## КЫЯРЛАР НИК САРГАЙГАН?

Бигрәк тә эшле инде
Гаиләдә барчабыз да,
Вакыт таба алмыйбыз
Барырга бакчабызга.

Беркөн барып карасак
Бакчабызны, шаккаттык –
Бер кыяр түтәленнән
Өч чиләк кыяр таптык.

Ләкин – хикмәт, һәммәсе
Яшел түгел, сарылар.
Сары күзләрен багып,
Үпкә белән карыйлар.

Без югында үскәннәр,
Безне зарыгып көткәннәр,
Бигрәк каты көткәннәр,
Саргаешып беткәннәр.

Карадым кыярларга,
Бирелдем хыялларга.
Дәү әни искә төште.
Ул да кыярлар төсле...

## ТЕШ ТАБИБЫНДА

Әллә конфет күп ашадым,
Әллә юмадым микән?..
Беркөн, бик нык тешем сызлап,
Уянып киттем иртән.
Әни бераз җәлләде дә
Табибка алып барды.
Авызымны дәү ачтырып,
Табиб тешне карады.
Утырам котым очып,
Без-без итә әллә ни.
Тишә, тешне җәлләми.
Шөпшә безләгән кебек,
Нидер эзләгән кебек.
Утырам батыр гына,
Берни сизмәгән кебек.
Табиб апа алдында
Төшмәм бит инде җебеп,
Мин бит биш яшьлек егет!
Авырта, суккан шикелле
Дәү чүкеч белән башка.
Хәтта килә елыйсы,
Ничек кенә чыдыйсы?
Бераз гына еларга да
Уйлаган идем башта,
Тик курыктым, күз яшьләре
Миннән сорап тормас дип.
Түздем инде шуңа күрә,
Елыйсы килсә дә бик.
Шөпшә инде безләми,
Тештә нидер эзләми.
Апа бетерде эшен –
Авыртмый хәзер тешем.
Чыгам менә ишектән,
Пәһлеван батыр кебек.
Чираттагылар көнләшә.
Әниләре эндәшә:
«Менә ичмасам егет!»
Мин чыктым, ә бит аларның
Бар әле керәселәре,
Бар әле күрәселәре...

## КУРКЫНЫЧ УЙ

Интернетка керсәк тә без
Йә уен уйнасак та,
Тычканны ычкындырмыйбыз,
Без песи булмасак та.
Элек тычканнарны тоткан
Уңган песиләр генә.
Ә бүген тычканны тота
Һәммә кешеләр менә.

Олысы да, кечесе дә
Шул тычканга тотынган.
Күзләр экранга төбәлгән,
Китап кына онтылган.
Кеше тычкан тотып кына
Китапларны онытса,
Гаҗәп түгел, беркөн аңа
Койрык һәм... мыек чыкса...

## ЧҮП ЗАРЫ

Мине ташлап калдырдылар –
Салмадылар чүплеккә.
Хәзер аптырыйлар күпләр
Җирдә пычрак күплеккә.
Җирне чүпләү әйбәт түгел,
Моны үзем дә аңлыйм.

Ләкин аяк-кулым юк бит,
Савытка төшә алмыйм.
Күр инде бу хәлне син,
Оят, бик оят инде.
Кешеләр өчен кызарып,
Чүп-чар булып ят инде.

## САЛАВАТ КҮПЕРЕ

Коеп-коеп яңгыр яуды,
Һава сафланып калды.
Күктә кояш күренде –
Дөнья ямьгә күмелде.
Шуны гына көткән күк,
Аллы-гөлле булды күк.
Ай, төсләре бигрәк күп:
Кызыл, сары, зәңгәр, күк...
Биектә, баш очында,
Үрелсәң, тотарсың күк.
Күпергә дә охшаган,
Көянтә кебек тә ул.

Кайсы рәссам ясаган
Күккә мондый матур юл?
Җавап эзлим шуларга,
Сорауларым бик күп тә.
Арта торалар, кабат
Күз салу белән күккә.
Мин серен беләм бугай,
Сез дә торыгыз белеп.
Яңгырлар явып үткәч,
Кояш чыкканда көлеп,
Зөһрә кыз көянтәсен
Куядыр күккә элеп.

## КАНИКУЛДА

Каникулда бүгеннән.
Башланды рәхәт көннәр.
Каникул дигәннәрен
Чыгарды икән кемнәр?

Дәрес әзерлисе юк,
Юк мәктәпкә барасы.
Әти-әни эшкә китә,
Ә син өйдә каласың.

Теләсәң, чана шуып була,
Теләсәң – чаңгы шуып,
Ә мин өйдә генә ятам,
Йөремимен җил куып.

Өйдә минем дустым бар,
Телевизор атлы ул.
Аны карар өчен генә
Биреләдер каникул.

Башта мультфильмнар була,
Аннары концерт карыйм.
Кино башланган вакытка
Мин инде тәмам арыйм.

Телевизор да арый бугай,
Кайчак ап-ак экран.
Сурәт чыгуын көтеп,
Тик диванда утырам.

Ике атна үтеп китте,
Каникуллар да бетте.

Тагын дәресләр уйда.
Сумкалар бүген кулда.
Мин укуда, телевизор
Бүгеннән каникулда.

*2004*

## Мәрзия Фәйзуллина



Балалар шагыйрәсе Мәрзия Низам кызы Фәйзуллина (Тәрҗеманова) 1930 елның 11 июнендә Татарстанның Арча районы Шушмабаш авылында туа. 1946–1956 елларда Казанда төрле оешмаларда эшләгәннән соң, ул 1956 елдан гомерен балалар белән бәйли: нәниләр өчен шигырьләр яза башлый, балалар бакчасына тәрбияче булып эшкә урнаша. 1958–1964 елларда читтән торып Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршында оештырылган Югары әдәби курсларда укый. Аның диплом эше итеп әзерләгән «Балалар өчен шигырьләр» дигән кульъязмасына «бик яхшы» билгесе куела. 1963–1965 елларда шагыйрәнең берничә китабы рус телендә «Детгиз» һәм «Малыш» нәшриятларында басылып чыга. Ул – балалар өчен дистәдән артык китап («Гөлнар мәктәпкә бара», «Нәни булышчы», «Мияубикә», «Гаилә әлифбасы» һ.б.) авторы. 1990 елда М.Фәйзуллинага «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән исем, 2004 елда Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясе бирелә. Мәрзия Фәйзуллина – 1965 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

## ГӨЛНАР МӘКТӘПКӘ БАРА

Кечкенә толымнарына
Ал тасмалар таккан ул,
Ә алдына кардан да ак
Алъяпкычын япкан ул.

Кулларына сумка белән
Чәчәк бәйләме тоткан.
Мәктәпкә соңга калмыйм дип,
Ашарга да оныткан.

Әй Гөлнарга булышалар
Әтисе-әнисе дә.
Алъяпкычын буярмын, дип,
Читләп йөри песи дә.

Гөлнар киткәндә эндәште
Яраткан курчагына:
– Кулларымда әйбер бар шул,
Алалмыйм кочагыма.

Мин бүгеннән йөри башлыйм
Мәктәбемә укырга.
Син, мин киткәч, ник кайтмый, дип
Ямансулап утырма.

## ЧЕБИЛӘР ЗАРЯДКАСЫ

Нәни чебиләр барсы да
Сары майка кигәннәр.
Зарядка ясарга диеп,
Бер урынга килгәннәр.

Тавык аңлата, корт-корт... дип,
Үз телендә аларга
Зарядка ясаган чакта
Ничек канат кагарга.

Тик тавыкның әйткәненә
Колак салмый чебиләр.
Шуңа алар зарядканы
Дөрес ясый белмиләр.

Өлкән группага күчкәч,
Ятканда әйтәм әнигә:
– Мине иртәрәк уят!
Өлкән группага күчкәч,
Соңга калуы оят.

## БЕРЕНЧЕ МАЙ

– Шомырт, кемне яраттың,
Кем өчен чәчәк аттың?
– Ямьле язгы ай өчен,
Яз бәйрәме май өчен!

– Бик матур итеп шулай
Ник җырлыйсың син, тургай?
– Олылап язгы айны,
Котлап Беренче майны!

## ЯЛКАУ ЧЕБЕН

Кичкә таба чебен арган,
Тиккә җил куып йөреп.
Бик шатланган, үрмәкүчнең
Корган оясын күреп:

– Минем өчен гамак үргән,
Үрмәкүч нинди уңган! –
Шулай сөйләнә-сөйләнә,
Чебен барып та кунган.

– Без... зз... ял итә беләбеззз, – дип
Тирбәнгән ул гамакта...
Очмак булган. Шунда сизгән
Эләккәнен кармакка.

## КҮЛӘГӘ

Һәрвакыт тагылып йөри,
Һич качып булмый аннан,
Йә синең арттан иярә,
Йә атлап бара яннан.

Күпме генә йөгерсәм дә,
Ул да калмый йөгерә.
Аннан качып котылам тик
Ышыкка кереп кенә.

## УРМАН ДОКТОРЫ

Тукран һәрбер агачны
Тук-тук-тук сугып карый,
Көчле һәм очлы борыны
Шундый зур эшкә ярый.

Агач кимергән кортларны
Эзләп, чукып бетерә.
Урман докторы булып, ул
Бик күп файда китерә.

## ЧӘЧӘКЛӘР СӘГАТЕ

Бакчачы Гали абыйның
Бар бик яхшы гадәте:
Яз килдеме, безнең белән
Ясый гөлләр сәгате.

Бу чәчәкләр сәгатенә
Төшенүе бик җиңел –
Сәгать сигез икәнлеген
Әйтеп бирә хәтфә гөл.

Нәкъ сигездә ача хәтфә
Чәчкәсен – күз керфеген,
Матур алсу алкасында
Уйнатып чык бөртеген.

Сигезлегә охшап тора
Хәтфә үскән түтәлләр.
Аннан тугыз тулганлыгын
Күрсәтә бүтән гөлләр.

Бу чәчәкләр сәгатенең
Бик ерак китте даны.
Күрше урам балалары
Карарга килә аны.

## КҮГӘРЧЕН БАЛА ЧЫГАРГАЧ

Берзаман бала чыгарды
Чормадагы күгәрчен.
Аптырап миннән сорады
Энем, шуны күргәчтен:
– Йомырканы ватып чыккан
Нәни генә күгәрчен.
Тик йомырка эченә ул
Ничек итеп кергән соң?

## ЯШЕН

Су сибүче машинадай,
Су сибеп килә болыт.
Энем тәрәзә янында
Тора тамаша кылып.
Аннан дәшә: «Апа, кара,
Күктә әкәмәт кызык.
Болытка ут төртмәк була
Яшен, шырпылар сызып».



## ГӨЛЛӘР

Гөлләр үстергән кешене
Таныйлар, яраталар.
Аны шатландырыр өчен
Чәчәкләре аталар.

Көн дә су сипкән кешегә
Алар иярләшәләр.
Пышылдашып рәхмәт әйтеп,
Үзара сөйләшәләр.

## КАЗЛАР

Рәт-рәт басып, тәртип саклап,
Казлар күлгә баралар.
– Казлар, кая киттегез? – дип
Сорау бирә балалар.

Казлар бар да бертавыштан:
– Елга-га-га-га... – диләр.
– Ул елга түгел, күл! – дигәч,
– Ул ага... ага... – диләр.

## ЧЫРШЫ КҮЛМӘКЛӘРЕ

Яшь чыршылар киң итәкле
Күлмәкләрен кигәннәр.
Җитәкләшеп, бергәләшеп,
Юл буена килгәннәр.

Апа әйтте: «Болай эшләү –
Начар гадәт, бел менә:
Һәр чыршы күлмәк алыша
Җиде елга бер генә».

Энәле күлмәкләренә
Карап тордык сокланып.
Тик Равил берничә энә
Өзеп алды шукланып.

Без энәләрен йолкысак,
Чыршы күлмәксез калыр.
Җиде ел буена ничек
Күлмәксез яши алыр?

## ГӨМБӘЛӘР

Әйтерсең лә качыш уйный
Гөмбәләр безнең белән.
Мин ул шаян гөмбәләрне
Бик оста эзли беләм.

Ак, ал, кызыл гөмбәләрне
Табам да кисеп алам.
Мин аларны һич бутамыйм,
Җайлап кәрзингә салам.

Тик чебен гөмбәсе кебек
Агулысын өзмимен.
Нәкъ апабыз әйткәннәрен –
Яхшыларын эзлимен.

## ЕЛАК БӘБКӘ

Бар бәбкәләр йөгереп йөри,
Нигә чатанлый берсе?
Без апабыздан сорыйбыз:
– Шуны аңлатып бирче.

Апа әйтә:
– Ул сораусыз

Суга берүзе кергән,
Башкалардан аерылып,
Тирәндә йөзеп йөргән.

Усал чуртан, астан килеп,
Тәпиен тешләп алган...

## ҖӘНЛЕКЛӘР

Куркак куян, болан, поши,
Төлке, аю һәм бүре
Кышкы туннарын салалар,
Яз җитүгә, һәрберсе.

Җәнлекләрнең йон койганын
Кызылтүш күзләп тора
Һәм, аларны ваклап ташып,
Бик матур оя кора.

## ТЕЛӘСӘҢ, ЭШ ТАБЫЛА

Иртән торгач, гөлләремә
Сулар сибәм һәр көнне.
Аның матур чәчәкләре
Сокландыра һәркемне.

Курчаклар чиста булсын дип,
Аларның керен уам.

Ашап-эчкәч, һәрвакытта
Чынаягымны юам.

Оста кулларга һәрвакыт,
Теләсәң, эш табыла.
Эш эшләгәч, тәмле була
Аш та, чәй дә табында.

## ИКЕ КӨРӘК

Түтәлләр казырга чыккач,
Күрдек без ике көрәк.
Белмим, кемнәрдер аларны
Коймага куйган терәп.

Апа безгә сорау бирде,
Берсен кулына тотып:

– Ник монсы көмештәй балкый,
Ә монсын баскан тутык?

– Берсе аның күп эшләгән,
Көмеш төсле шунлыктан.
Икенчесе гел тик яткан,
Ялкаулыктан тутыккан!

## ТОРНАЛАР НИГӘ ОЗЫН АЯКЛЫ?

– Беләсеңме җирдән ничек
Очуын син торнаның?
– Беләм, бар бу күренешне
Читтән карап торганым!

Башта торна канат җилпеп
Атлый, йөгереп үтә.
Аннан соң, һаваны ярып,
Бик җиңел очып китә.

– Ә нигә соң озын була
Аяклары торнаның?
– Очып киткәндә канаты
Җиргә тимәскә аның.

## КҮГӘРЧЕН ҺӘМ САМОЛЕТ

Аякларын түшкә җыеп
Очып китә күгәрчен.
Энем аптырап сүз дәште,
Шушы хәлне күргәчтен:
«Самолет та, очкан чакта,
Яшерә аякларын.
Ә нигә соң күгәрчен күк
Җилпеми канатларын?»

## БАЛ КОРТЫ

Апам безнең бакчабызда
Матур бер гөл үстерде,
Ул гөл ап-ак чәчәк атты,
Бик матур төскә керде.

Апам кунакка киткәчтен,
Шуны өзәргә булдым.
Алам диеп, гөлгә таба
Тиз генә кулым суздым.

Шулчак бал корты, безелдәп:
«Чәчәкне ө-з-ззз-мә! – диде. –
Сезгә тәмле бал җыярга
Кирәк ул безззгә», – диде.

## ЯҢА ҺӘМ ИСКЕ АЙ

Кискән кабак телеменә
Охшап тора үзе бик.
Кайсы якка каравыннан
Исеме үзгәрә тик:
Уңга таба кырын ятса,
Яңа туган ай була.
Иске ай диеп йөртәләр,
Кырынайганда сулга.

## ЧЕБИЛӘР

Тышта бик җылы булса да,
Тун кигәннәр чебиләр.
Яңа гына тусалар да,
Йөгерешеп йөриләр.

Эремчек, тары ярмасы,
Суалчан яраталар.
Суалчан дип, ботинкамның
Бауларыннан тарталар.

Көш-көш дигәч китсәләр дә,
Тагын килеп тарталар.
Тарта-тарта, ботинкамның
Бауларын чуалталар.

## КУРЧАГЫМ, ЙОКЛА ИНДЕ

Уйнау качты,
Йокы басты
Инде үзеңне.
Йә ачтыра,
Йә яптыра
Йокы күзеңне.

Бәбекәем,
Бәгырькәем,
Күзең йом инде.
Кояш баткан,
Ай калыккан,
Вакыт соң инде.

## ПЕШКӘН, ӘЛЛӘ ПЕШМӘГӘН

Мин йомыркалар пешерәм
Кухняда әни белән,
Аларның пешеп җиткәнен
Тикшереп карый беләм.

Моның өчен әйләндерәм
Алып йомыркаларны.
Кайсылары шәп әйләнә –
Пешкән була алары.

## ТИМЕРАЯК ШУГАНДА

Бозга кергәч, уңга-сулга
Китте минем аяклар...
Буйсынырга теләмәгәч
Миңа тимераяклар.

Боз өстенә килеп төштем
Аяк атлаган саен.
Шактый азаплангач кына
Таптым мин моның җаен.

Инде курыкмыйча шуам,
Иптәш булгач мендәрем.
Шунысы җәл – бу турыда
Алданрак белмәдем.

## ЧИШМӘ КАЯ ЧАБА?

– Кая чаба чылтыр чишмә?
– Болын аша елгага.
– Ә елга кая юл тота?
– Агыйделгә ул ага.

– Агыйдел туктап торамы?
– Юк, ул чаба диңгезгә.
– Аннан нишли чылтыр чишмә?
– Бусы да ачык безгә.

Әгәр дә кояш кыздырса,
Күккә менә пар булып.
Күпләр аңар күз төбиләр,
Яварммы дип бу болыт?

Яңгыр белән агып төшә
Өй түбәсе калайдан...
– Чишмә тагын кая чаба,
Сорыйм кайсы малайдан?

## ҮРДӘК

Үрдәк рәсемен ясыйм мин,
Кулымда карандашым.
Зур түгәрәк булыр гәүдә,
Ә кечкенәсе – башы.

Гәүдәсе һәм башы булгач,
Аннан ясыйм муенын.
Кишергә охшатып сызам
Үрдәкнең зур борынын.

Канатларын, аякларын
Бик ансат һәм тиз ясыйм.
Тирә-якка карар өчен,
Бит өстенә күз ясыйм.

Шуннан соң гына җибәрәм
Үрдәкне мин елгага –
Нәни дулкыннар чыгарып
Йөзеп китә ул алга.

## КЕРПЕ

Керпе безне күрү белән
Йомарланды шунда ук.
Нәкъ машина килгән төсле
Тавыш чыгарды: «Тук-тук!».

Күзем төшү белән миңа
Бу керпе ошап калды.
Рәсемен ясарга диеп,
Каләм, блокнот алдым.

Ничек итеп башлыйм, диеп
Карап тордым текәлеп.

Каләмем белән ясадым
Башта ярты түгәрәк.

Аннан ясадым аяклар...
Колакка таптым урын.
Керпегә охшый башлады,
Хасил булды күз, борын.

Аннан энәләр ясадым.
– Нигә кирәк соң алар?
– Шуларны чәнечке итеп
Керпе ташый алмалар.

## СЫЕР

Башта ике түгәрәкне
Ак кәгазьгә төшердем.
Аннан аларны гәүдә һәм
Баш итеп килештердем.

Коточкыч итеп ясадым
Зур-зур ике мөгезен.
«Үгез булып чыкмасмы?» – дип
Куркып калдым мин үзем.

Усал үгез итмәс өчен,
Ярый юлын тиз таптым...
Сөтле җиленен ясадым,
Аннан койрык та тактым.

Күзләр, аяклар ясадым.
Кабул итеп алыгыз.
Инде һәр көнне иртә-кич
Җылы сөтен савыгыз.

## СУГАН ТУРАГАНДА

Ашка салырга суганның
Сайлап алдым олысын.
Әрчи башлагач еладым,
Килмәсә дә елыйсым.

Күзгә керә әчесе,
Ничек кенә әрчисе?!
Ашка суган турыйм мин,
Көлә-көлә елыйм мин!

Әрчүен әрчедем инде,
Эшнең бетте зурысы,
Пычак белән вак-вак итеп
Калды аны турыйсы.

Ашка суган турыйм мин,
Көлә-көлә елыйм мин!

## ИСЛАМ ДИНЕ

Исламның нигезләре биш –
Күп түгел алар, бик аз:
Иман, намаз, руза тоту,
Зәкят бирү һәм дә хаҗ.

Ислам динен тоткан кеше
Мөэмин-мөселман була.
Ходай кушкан хак дин белән
Дөньяда гамәл кыла.

## КЫШ БАБАЙ


Җилкәсенә капчык асып,
Кыш бабай килеп керде.
Төрле кызык сүзләр әйтеп,
Бүләк өләшеп йөрде.

Аннан Кыш бабай, тыпырдап,
Бик шәп бии башлады.
Биемәскә, аягында
Безнең апа башмагы!

## ЧАНА ШУГАНДА

Тау башыннан түбән таба
Рәхәт чана шуарга.
Тик тауга менүе авыр,
Бик арыла шуңарга.

Мин, зур үскәч, бу чанага
Мотор куярмын әле.
Рәхәтләнеп тауга каршы
Чана шуармын әле.




*2004*

## Татарстан Республикасы «Мәгариф» милли нәшрияты

«Мәгариф» нәшрияты 1991 елның май аенда Татарстан китап нәшриятыннан аерылып чыга. Ул, илдә үзгәртеп кору чоры башлангач, милли мәгарифне торгызу һәм үстерүне күз алдында тотып гамәлгә куела. Аның төп вазифасы – уку-укыту әсбаплары: барлык уку йортлары өчен дәреслекләр, педагогик, фәнни-популяр әдәбият, укытучылар һәм тәрбиячеләр өчен методик кулланмалар, сүзлекләр һәм белешмәлекләр, әдәби хрестоматияләр нәшер итү. Куелган бурычларны максатчан рәвештә тормышка ашырып, нәшрият, нигездә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы заказы буенча төрле характердагы китаплар бастырып килә. Анда шушы еллар эчендә 1700 дән артык исемдә китап дөнья күрде. Дәреслекләр һәм уку әсбаплары нәшер итү белән бергә «Мәгариф» «Балалар күңеле = Колокольчик», «Җәйнең җиде төсе», «Гөрләвекләр кайтавазы» җыентыкларын, «Сабантуй» газетасы, «Ялкын» журналы авторларының «Безнең йолдызлар яктырак», «Җилләрдә чәчәк исе» тупланмаларын бастырып чыгара. Шушы хезмәтләре өчен 2004 елда «Мәгариф» нәшрияты Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясенә лаек була.

## *2005*

# Энҗе Мөэминова



Энҗе Һилалетдин кызы Мөэминова
1924 елның 18 маенда
Татарстанның Әлмәт районы
Яңа Кәшер авылында туа.
1941 елда Әлмәт урта мәктәбен
тәмамлагач, ул укытучы булып эшли.
Бер үк вакытта читтән торып
Казан дәүләт педагогия институтында укый.
Ике елдан Ташкентка күченеп,
анда Ташкент педагогия институтында
математика буенча югары белем ала.
1948 елда Әлмәт районының
Габдрахман авылына кайтып,
гомере буе мәктәптә математика укыта.
Ул – балалар өчен дистәләгән китап
(«Үрдәгем үпкәләде», «Әйдәгез танышыйк»,
«Дуслар җыелгач» һ.б.) авторы.
1994 елда Э.Мөэминовага «Татарстанның
атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән исем,
2005 елда «Бәйрәмнәр» китабы өчен
Татарстан Язучылар берлегенең
А.Алиш исемендәге премиясе бирелә.
Энҗе Мөэминова – 1963 елдан
Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.
Ул 2009 елның 2 мартында вафат була.

## КЕМ КИТЕРӘ БӘЙРӘМНЕ?

Бәйрәмнәр килә илгә,
Бәйрәмнәр килә өйгә.
Бәйрәмнәр килә сезгә,
Бәйрәмнәр килә безгә.
Китерә ул кунаклар,
Пешертә ул коймаклар.

Яңа күлмәк тектерә,
Үзен оза-а-ак көттерә.
Бәйрәмне кем китерә?
Чәчәкләр, гөлләр микән?
Бураннар, җилләр микән?
Китаптагы шигырьләр,
Бәлки, әйтеп бирерләр.

## КӨН ДӘ БУЛЫШАМ

Минем дә бәйрәм ул
Әниләр бәйрәме!
Сагынып көтәм бит
Мин дә ул бәйрәмне!
Әнием гел матур
Булсын дип тырышам:
Мин аңар һәр эштә
Һәр көнне булышам!
Суырткыч белән мин
Суыртам тузанны.
Әнием яратмый
Урын-җир тузганны.

Тәртипкә китерәм
Үземнең бүлмәмне,
Су сибеп үстерәм
Өйдәге гөлләрне.
Әнигә мин шулай
Һәр көнне булышам.
Әнием гел матур
Булсын дип тырышам.
Мин аңа бүләккә
Матур гөл үстерәм.
Әнигә бәйрәмне
Мин шулай китерәм!

## БӘЙРӘМ КИТЕРДЕК ӘБИГӘ

Туган көне дә түгел,
Чакырмады да үзе,
Чакырмаса да, килдек –
Бик-бик сагынган идек!
Кыш көнендә, урамда
Карлар явып торганда,
Әбекәйгә бүләккә
Чәчәк алып килдек без,
Шатландырыйк, дидек без.
– Мондый матур чәчәкләрне
Кайда үстердегез? – дип. –
Сез бит бүген безнең өйгә
Бәйрәм китердегез, – дип,
Әй шатланды соң әби!
Чәчәк бирдек әбигә –
Бәйрәм китердек өйгә!

## МОҢСУ БӘЙРӘМ

Бәйрәмнең тагын да
Матуры, олысы,
Кояшлы май кебек
Яктысы, җылысы –
Бабамның сугышта
Кан коеп алганы –
Зур Җиңү бәйрәме
Дигәне бар әле!
Өр-яңа кулмәген,
Иң матур костюмын
Кия дә бабаем
Ул көнне өстенә,
Сандыктан ала да
Күптөрле орденнар,
Медальләр тага ул
Пиджагы түшенә.
Урамнар бәйрәмчә
Бизәлгән булса да,
Кояш гел һавадан
Нур чәчеп торса да,
Кешеләр ул көнне
Кайгылы тоела.
Елыйсы китереп
Яңгырый җыры да.
Ул көнне кешеләр
Һәйкәлләр каршында
Баш иеп, тын гына
Торалар барсы да.
Һәйкәлләр тирәсе
Чәчәккә күмелә.
Шул чакта минем дә
Яшь килә күземә.

## САБАНТУЙ

Сабантуй бәйрәме
Тора гел алыштан:
Ул көнне теләгән
Һәр кеше ярыша.
Иң элек батырлар
Көчләрен сынаша:
Кем калыр батырга
Бу көрәш-сынашта?!
Яшүсмер малайлар
Көрәшә иң элек.
Бабайлар да хәтта
Алалар җилкенеп.
Судьялар күзәтә,
Җиренә җиткереп.
Кешеләр торалар
Кул чабып, көч биреп:
– Хәрәмләшмә, егет, алдашма!..
– Хәйләләп егарга маташа!..
– Биленнән урап тот, биленнән!..
– Бирешмә!..
– Егып сал, егып сал тиз генә!..
– Һоп әйдә! Һоп! Һоп! Һоп!..
– Молодец икәнсең – булдырдың!
– Ну, малай, шәп аста калдырды!..
– Егетнең асылы икәнсең, асылы!..
– Менә бит кем быел Сабантуй батыры.
Гөр килеп, батырны
Чөяләр һавага.
Иң олы бүләкне
Бирәләр аңарга.
Иң матур сөлгене
Бәйлиләр биленә!
Зур, симез тәкәне
Салалар иңенә!
Чәчәккә күмелгәч тугайлар,
Июньнең иң матур көнендә
Болынның иң матур җиренә
Килегез Сабантуй күрергә!

## ЭШ ТАБЫЛА КЕМГӘ ДӘ

Бөтен кеше эштә бүген,
Бөтен кеше өмәдә.
Өмә булгач өмә инде,
Эш табыла кемгә дә.
Гөр-гөр килеп, күгәрчен
Биеп йөри тирәдә.
Алсу белән Гүзәлия
Аларга җим сибәләр.
Әтиләр түтәл күтәрә,
Гөл утырта әниләр.
Арбадагы бәбиләрне
Тирбәтәләр әбиләр.
Бабайлар өйрәтеп тора,
Чокыр казый малайлар.
Агач утырта урамга
Олы-олы агайлар.
Бөтен кеше эштә бүген,
Бөтен кеше өмәдә.
Өмә булгач өмә инде,
Эш табыла кемгә дә.
Өмәне көтеп алалар
Көткән кебек бәйрәмне.
Нинди көн соң өмә көне?
Эш көнеме? Бәйрәмме?

## «САГЫНУ ЧИРАТЫ»

Бу ни хәл соң? Ял көнендә
Маратларның өенә
Ишек төпләреннән башлап
Бала-чага тезелгән.
Марат алар каршысында
Елмаеп, көлеп тора.
Ул аларга алсу-кызыл
Алмалар биреп тора!
– Нәрсә бирәләр соң анда?
– Мороженый саталармы?
– Әллә фокусчы килгәнме?
– Конфет тараталармы?
Узган-барган шулай диеп
Сүз катып үтеп тора.
Ә чират үсеп тора!..
Малайлар, кызлар гөрләп
Җавап бирәләр бердән:
– Марат бөтен җәй буена
Авылда торып кайтты...
– Без аны бик-бик сагындык...
Бу – «сагыну чираты»!..
Чират гел үсеп тора,
Алмалар бетеп тора.
Тәмле дә соң алмасы! –
Оныкларын ярата шул
Әби белән бабасы.
Марат алар күчтәнәчен
Дусларына тарата.
Ә дуслары чын күңелдән
Рәхмәт диләр Маратка.

## БҮЛӘК ИТСЕННӘР ИДЕ

Их, рәхәт тә соң кунакта
Бабай белән әбидә!
Китәсе килми бер килгәч,
Кайтасы килми өйгә.
Әйтеп карыйм әле бүген
Әти белән әнигә,
Бүләк итсен алар мине
Бабай белән әбигә!
Бабай белән әбигә дә
Күңелле булыр иде.
Алар миңа кәнфит кенә
Ашатып торыр иде.
Иртүк уятмаслар иде,
Барырга дип бакчага.
Көндез йоклатмаслар иде,
Йоклаткан күк бакчада.
Бабай белән икәү бергә
Балыкка йөрер идек.
Әби көн дә тәмле ашлар,
Коймак пешерер иде.
Бераз үскәч, мин аларга
Ярдәм итешер идем:
Җиләкләргә, чәчәкләргә
Сулар сибешер идем...
Әти белән әнине мин
Сагынмас идем бер дә.
Бик сагынсалар, үзләре
Килер иде күрергә.
Күндердем инде мин моңа
Бабай белән әбине!
Ничек ризалаштырырга
Әти белән әнине?!

## ЯҢА ЕЛ

Күктән ап-ак чәчкә ява.
Чәчкә түгел,
Җем-җем итеп,
Тәңкә ява!
Балаларның йөзләрендә
Шатлык арта.
Тирә-якта аклык арта,
Сафлык арта.
Әнә кара!
Ак бүреген кигән таулар,
Ак мамыктан шәл ябынган
Бөдрә таллар,
Барыр юллар һәм сукмаклар
Ап-ак булган.
Бар дөньяга якты тулган,
Аклык тулган.
Бар табигать, бар күңелләр
Бәйрәм көтә,
Ак чәчәкләр талпынышып
Бии күктә:
«Бәйрәм җитә,
Бәйрәм җитә!»

## ӘЛЛӘ ФОКУСЧЫ МИКӘН?

Фокусчы фокус күрсәтә,
Карап тора бар кеше.
Ышанмастай эшләрне ул
Ышандырырлык эшли:
Юк нәрсәне бар итә ул,
Салкын суны ут итә.
Таяк белән бер селтәнсә,
Күгәрчен очып китә.
Авызыннан ут бөрки ул,
Аждаһа дип белерсең.
«Мин хәйләли белмим, – ди ул, –
Күрсәтәм, – ди, – дөресен».
Беркөнне безнең Марат та
«Фокус» күрсәтеп алды:
Күз ачып йомган арада
Ике конфет югалды!
Без эзлибез, табалмыйбыз.
«Эзләмәгез һаман, – ди. –
Мин аны яшердем бит, – ди, –
Алып булмый аннан», – ди.
Өч яшьлек «фокусчы»бызга
Ышанмаска буламы? –
Күз ачып йомган арада
Ике конфет югалды!

## ҮЗ ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘШӘ

Әтисе дә сөйләшә,
Әнисе дә сөйләшә.
Шулай булгач, нигә әле
Айдарга сөйләшмәскә?! –
Теле бар бит аның да!
Кара-каршы сөйләшергә
Әбисе бар янында.
– Әт-тә,ән-нә, тәт-тәт-тә!..
Әб-бә, баб-ба, тәт-тәт-тә!..
Айдар шулай матур итеп
Үз телендә сөйләшә.

## БЕР ХИКМӘТ БАР...

Минем энем үсте инде,
Ике яшь тулып килә.
Әни юкта безнең белән
Уйный, шаяра, көлә, –
Уйламый да еларга!
Әнине күреп алуга,
Нидер була үзенә:
Көйсезләнә, чәбәләнә,
Тыялмыйбыз без генә,
Аптырыйм мин шуңарга!
Аны күргәч, ник күзенә
Елак тыгыла икән?
Әниләрдә әллә берәр
Елаткыч була микән?
Бер хикмәт бар шулай да!..

## СЫБЫЗГЫ СЫЗГЫРТАЛАР

Кошлар безнең бакчабызда
Сыбызгы сызгырталар.
Сыбызгы сызгырталар да
Йокымнан уяталар.
Шәп тавышлы сыбызгылар
Кибеткә кайта микән?
Әллә аны кем дә булса
Урманда сата микән?
Сатучыны әти белән
Табалсак без тиз генә,
Иң матур сыбызгыларны
Сайлап алам үземә.

## БАЛЫКЧЫ

Нинди тылсымлы сүздер бу –
«Балык», «балыкчы» сүзе.
Уятып торучы да юк,
Шул сүз искә төшү белән,
Йокы ачыла үзе.
Таңнан алып төнгә кадәр,
Ашамый-эчмичә дә,
Бер кузгалмый утырып була,
Ләм-мим сүз дәшмичә дә.
Калкавычтан күзне алмый,
Чирткәнен көтә-көтә,
Күпме вакыт та үтә...
Нинди кыбырсык булсаң да,
Сабырлыгың, шәт, җитәр.
Калкавыч чак сизелерлек
Селкенгәләп куюга,
Кармагыңа алтын балык
Эләккәндәй тоела.
Көннәр буе яр буенда
Утырасың ымсынып:
Менә-менә җәен балык
Килеп эләгер сыман.
Булган хәл итеп сөйлисең
Булмаганны, булганны.
Аны шулай сөйләүнең бит
Һичкемгә юк зияны!
Шагыйранә ялган ич ул
Балыкчының ялганы!

## ИҢ ОЛЫСЫ КЕМ БЕЗДӘ?

Мин олырак энемнән,
Апам олырак миннән.
Әти олы әнидән,
Әби олы әтидән.
Әтидән олы – бабай.
Иң олысы ул бугай!
Бабай үзе нигәдер
Энемне иң олы ди.
«Без бит аның колы,
Бишегендә көе дә
Биетә, – ди, – мине дә.
Барыбыздан көйләтә,
Үз дигәнен үтәтә».
Чыннан да шулай бугай,
Алдамас инде бабай!..
Елаклыгын ташлагач,
Тәпи йөри башлагач,
Бәләкәйләнер әле,
«Абый» дия башлагач.

## НИЧЕК ТЫҢЛАТЫЙМ?

Гимнастка апа әнә
Тупны ничек уйната!
Аның кебек булдыра алмыйм,
Көне буе уйнап та.
Ничек кенә тырышсам да,
Тубым мине тыңламый:
Үз дигәнчә сикерә ул,
Мин дигәнчә уйнамый!
Моңардан да тискәре туп
Башка беркемдә юктыр!
Өйрәтегез әле мине:
Ничек тыңлатыйм тупны?

## УЛ АЛДАН КИЛЕП ҖИТКӘН

Мин туктасам – ул да туктый,
Мин йөгерсәм – йөгерә.
Кояш нигә минем арттан
Һаман ияреп килә?
Минем кунакка барганны
Әллә ул да беләме?
Әллә аның да кунакка
Барасы бик киләме?
Мин автобуска утыргач,
Ул туктап калыр микән?
Әллә автобус артыннан
Йөгереп барыр микән?
Автобустан төшү белән
Караган идем күккә,
Кояш миннән көлеп тора:
Ул алдан килеп җиткән!

## КИЛЕШМИ

Әни тотып карады да
башымны минем:
– Авырыйсың, улым, бераз
ятып тор, – диде.
Врач килде, дару бирде:
– Терелер, – диде. –
Ике-өч көннән дөп-дөп басып
йөгерер, – диде.
Әни минем янымда гел
саклап утырды.
Җылыткыч куйды муенга,
дару йоттырды.
Кура җиләк кагы белән
чәйләр эчерде.
Тәмле-тәмле пәрәмәчләр,
ашлар пешерде.
Мин терелдем. Бер җирем дә
авыртмый инде.
Әни генә элеккечә
көйләми мине...
Тукта әле, дим, чирлим, диеп
хәйләләп карыйм.
Тагын иркәләним әле,
тагын сыйланыйм...
Беркөнгечә кулын куйды
әни башыма.
Күзгә карап, озак кына
торды каршымда.
– Ай-һай, улым, йоккан сиңа
чирнең бик зуры...
Врач чакыртып тормабыз
инде бу юлы.
Урыныңны җый, юын, киен,
ашап ал элек.
Ялганлап тору килешми,
син бит зур егет!

## БУЛГАН ХӘЛ

Бүген мине бүре куды,
Мультфильмдагы кебек,
Әллә мине сынар өчен,
Әллә куян дип белеп.
Кигән идем ак бүрек,
Ак, йомшак куян бүрек.
Башта миңа карап торды,
Тешен ыржайтмый гына.
Бер адым атлаган идем,
Килим дип якынрак,
Миңа таба сикерде бу!
Җаным чыга дип торам.
Тешләрем тешкә бәрелә,
Дер-дер киләм куркудан.
Кычкырырга өнем юк,
Әйтерсең лә телем юк.
Бүре, өстемә сикереп,
Эләктерәм дигәндә,
Телем ачылып китте.
– Әни! – дип, бер дәшкән идем,
Әни килеп тә җитте.
– Нәрсә булды?
Ник чакырдың?
Саташасың бит, балам!..
– Бүре куа мине, әни,
Артымнан калмый һаман...
– И-и-и бәбкәем!
Мин үзем дә
Бик куркам бит бүредән.
«Әти!» дип дәшәләр аны,
Качар иде бүреләр...
Андый чакта кем уйлый соң
Кемгә дәшү турында?
Әни кирәк була бит ул
Иң куркыныч урында!

## СУКЫР КҮЗЛЕК

Беркөнне мин әбиемнең
Күзлеген алып кидем.
Менә гаҗәп!
Күзлек кигәч,
Күзем гел күрми минем!
Әби исә шыпырт кына
Күзәтеп торган мине.

Килде дә елмаеп кына:
«Сукыр күзлек ул!» – диде.
Сукыр булгач, әби аны
Нигә кия торгандыр?
Сукыр күзлек кигәч, үзе
Ничек күрә торгандыр?

## БИК МАТУР ИДЕ

Әнисәләргә
Кергәч уйнарга,
Өстәлләрендә
Күрдем бер йозак.
Бу бик кечкенә
Матур йозакка
Кызыгып карап
Тордым бик озак.
Кеше күрмәгән
Чагында гына,
Аны кесәмә
Саласым килде.
Курчак сандыгын
Бикләп куярга
Аны үземә
Аласым килде.
Кызыга торгач,
Алдым мин моны.
Күлмәк кесәмә
Салдым мин моны.

Өйгә кайткачтын,
Уйнадым озак.
Бигрәк тә матур
Иде шул йозак.
Сизде бит әни,
Барсын да сизде...
– Илтеп бир! – диде. –
Хәзер, тиз! – диде...
Мин елый-елый
Чыгып йөгердем,
Капка астыннан
Шуышып кердем.
Куйдым йозакны
Баскыч өстенә
Әкрен генә,
Үрелеп кенә.
Шуннан бирле мин
Кеше әйберенә
Рөхсәт сорамый
Тиим ник кенә!

## МЕНДӘРКӘЕМ

*(С.Михалковтан)*

Мендәркәем ак кына,
Ак кына, йомшак кына.
Куйдым исә йөземне,
Шундук йомам күземне.
Клубка бармыйча да,
Билетлар алмыйча да
Күреп була киносын –
Күзне генә йомасың.
Ә менә бүген миңа
Күрсәттеләр бер кино:
Космодромга бардым да,
Билет кына алдым да
Очтым киттем биеккә,
Очтым зәңгәр киңлеккә.
Әтиләр өйдә калды,
Җир миннән сәлам алды.
Миңа никтер кешеләр:
«Терешков!» – дип дәштеләр.
Очып йөрдем-йөрдем дә
Кайтып төштем мин җиргә,
Шар ачып күзләремне,
Кочаклап мендәремне...

## ЧАКЫРАЛАР

Су буена барам көн дә
Каз бәбкәсе сакларга.
Мин саклагач, тия алмый
Тилгәне дә, карга да.
Иң матурларын үземә
Сайлап алдым арадан.
«Сандугач» дип,
«Кояшкай» дип
Исем куштым аларга.
Бәбкәләр бик акыллылар,
Яратканны белделәр.
Мине күргәч, барысы бергә:
«Гөлназ апа, Гөлназ апа,
Гөлназ апа, кил!» – диләр.
Чакыралар,
Алар минем ата каздан
Курыкканны белмиләр.

## ҮПКӘЛӘДЕ

Беркөнне без әни белән
Киттек кибеткә.
Уенчык сайлый башладык
Килеп кердек тә.
Сатучы апа тезеп куйды
Алга барсын да.
Ни теләсәң, шул нәрсә бар
Безнең каршыда:
Буратино, Чипполино,
Наташасы да.
Аккош, тиен, аюлар да –
Барсы, барсы да.
Әни әйтә:
– Сайла, кызым,
Кайсын алыйк? – ди.
– Бар да матур, әни, болар,
Барсын алыйк! – дим.
– Син генә түгел бит, кызым,
Бар башкалар да.
Без барсын да алып китсәк,
Калмас аларга...

Әни әйткәч, мин дә аңа
Каршы килмәдем.
– Ярар инде, алай булгач,
Алыйк үрдәген...
Шул чагында үрдәк миңа:
– Бак, бак! – дип куйды.
Әллә белеп алды инде
Ул минем уйны?
Бакылдады, өйгә кайткач,
Көн буена ул.
Бик карыйсым килде эчен,
Ник кычкыра ул?
Эчендәге чын үрдәген
Чыгарыр өчен,
Бакылдык үрдәккәемнең
Тиштем мин эчен...
Әни почмакка бастырды,
Бер сүз әйтмәде.
Ә үрдәгем үпкәләде –
Бүтән дәшмәде.
Мин еладым...

## БӘХӘС

Бәхәсләшә Галия,
Бәхәсләшә Дания,
Берсеннән-берсе узып,
Берсеннән-берсе кызып.
– Ялкау сәгать була! – ди
Галия.
– Юк, юк, булмый, булмый! – ди
Дания.
– Ышанмасаң, кара безнең
Сәгатькә! –
Әни һаман кайта алмый
Әбәткә!
Көтәм, көтәм, һаман җитми
Унике.

Ялкау сәгать –
Безнең сәгать!
Безнеке!!!
– Ә безнеке ашыга да ашыга.
Шуңа мин иң алдан киләм бакчага.

Бертуктаусыз йөгерә дә йөгерә.
Андый сәгать
Бездә генә!
Бер генә!!!
Нәрсә сәбәп бу бәхәскә:
Сәгатьме?
Уйлыйк әле, табыйк әле сәбәпне!

*2005*

## Әнәс Хәсәнов



Әнәс Хәсән улы Хәсәнов 1935 елның
23 июнендә Спас (элеккеге Куйбышев) районы
Көек авылында туа.
1954 елда Куйбышев (хәзерге Болгар) шәһәрендә
педагогия училищесын, 1959 елда
Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый.
1959–1972 елларда Казан телестудиясендә
балалар өчен тапшырулар редакторы,
аннары иҗтимагый-сәяси тапшырулар
баш редакторы вазифаларын башкара.
Партия өлкә комитетында эшли.
1984–1988 елларда Татарстан китап нәшриятында –
баш мөхәррир урынбасары, 1988–1990 елларда
«Татарстан коммунисты» (хәзерге «Татарстан»)
журналында – җаваплы сәркатип,
1991 елдан Татарстан Югары Советы
секретариатында – өлкән консультант, берничә
айдан Татарстан Республикасы Президентының
Матбугат үзәге җитәкчесе вазифаларын башкара.
2000 елдан Президент Аппаратының
Матбугат архивы мөдире.
Әнәс Хәсәнов шигырьләр һәм проза әсәрләре яза,
балалар өчен хикәяләр иҗат итә.
Ул – Абдулла Алиш белән
бер авылда туып үскән, бер мәктәптә укыган кеше.
Шуңа күрәдер дә туган авылында Алиш исемен
мәңгеләштерү өчен күп хезмәтләр куя.
Алишның музеен булдыру,
аңа бюст куйдыру эшендә башлап йөри.
Шушы хезмәтләрен истә тотып, 2005 елда
Ә.Хәсәновка Татарстан Язучылар берлегенең
А.Алиш исемендәге премиясе тапшырыла.
Әнәс Хәсәнов – 1996 елдан
Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

## НӘНИ АУЧЫ

Базар шау-гөр килә. Кая карама, кеше, кеше. Әтиеңнең билбавына тотынып йөрмәсәң, монда адашып калуың да бар. Кем матур итеп, бизәкләп чиккән кәләпүшләр, кем күз явын алырлык күн читекләр, кем прәннек, конфет, клиндер сата. Ул да түгел, борынга балык, тозлы кәбестә, алма, буяу исе килеп керә.

Абдуллага бары да кызык, ул туктаусыз тирә-ягына каранып бара. Кем генә юк икән монда! Буҗак базары бер якта торсын!

Халык, халык. Озын-озын сакаллы картузлы урыслар, аларның кара юбка кигән, кара шәл ябынган хатыннары, кәләпүшле, фәсле татар бабайлары, тагын әллә кемнәр тыз-быз килә. Кем малын мактый, кем сатулаша, кем каядыр ашыга. Бер урыс бик зур, күкрәк хәтле ак сакалын тарак белән ике куллап тарап утыра. Абдулла аның урыс икәнен белә. Андый сакаллы урыслар, аларның өенә килеп, сабын, бал сатып алганнары бар.

Кинәт кемдер Абдулланың аягына китереп басты, Абдулла авыртудан кычкырып җибәрде. Каршында җирән сакаллы бер абзый басып тора иде.

– Күрми калдым, егет, ачуланма, рәнҗемә инде, – диде ул. – Минә бит, гөнаһ шомлыгы.

Ничек инде олы кешегә ачуланасың?

Габделбари абзый кулындагы таякларын бер бүкәнгә сөяп куйды да җирән сакалга:

– Карабрак йөрергә кирәк ләбаса, агайне, – диде. – Баланы аяксыз калдыруың бар. Үзем интеккән дә җитәр.

Шулай дип, әтисе Абдулланы бүкән өстенә утыртты да, сандалиен, оекбашын салдырып, аның аягын угалады. Ул арада теге җирән сакаллы абзый, кулына сапсары клиндер тотып, болар янына әйләнеп килде.

– Күгәреп чыкмаганмы? – диде ул. – Гаеп миндә. Минем аяк сизми шул. Агач аяк бит. Мә, энем, клиндер, бәхил бул, яме. Минем шикелле сыңар аяклы буласың килмәсә, солдатка барма.

Олы кешенең шулай сабый балага «бәхил бул» диюе Габделбари абзыйның күңеленә хуш килде.

– Ярар, кордаш, син артык борчылма инде. Була торган хәл. Үзем дә инде... Агач аяк дисең инде. Кайда өздерең соң ул аягыңны? – диде ул.

– Әй! – Җирән сакаллы абзый кулын гына селтәде. – Карап торам, үзең дә ике таякка таянып йөрисең икән... Солдат шулпасын әз татымагансың. Ярар, сәламәт булыгыз.

Белә Габделбари абзый аяк сызлавын, ничек кенә белә әле. Солдат хезмәтеннән ревматизм дигән рәхимсез авыру ияртеп кайтты бит ул. Шуңа күрә бик кызганып улының аягын кат-кат уды. Абдулла, авыртуы бетте бит инде, дип, әтисен тынычландырып маташты. Оекбашын җайлап кигәч, аягы чыннан да авыртмый башлады. Ул бүкән өстеннән сикереп төште дә янә әтисенең билбавына кулын куеп ияреп китте. Әтисе, йорт кирәк-яраклары саткан талчуклар янында туктап, керосинка филтәсе, без, ялт

итеп торган галошлар сатып алды. Бизәкле калай савытларны исни-исни, тәмле һинд чәе сайлады. Шактый сатулашып торгач, кулын селтәп, биштәренә төтәткеч тә салып куйды.

– Болай булгач, балны күп итеп ашыйбыз, улым... Син умарта кортларына гөмбә төтене өрдереп торырсың. Мин кәрәзләрне карармын, яме.

Аннары алар кием-салым кибетенә керделәр. Монда балалар киемнәре күп икән. Әтисе Абдуллага матур костюм, чалбар, башына фәс алды.

– Боларны кигәч, син, улым, чистый кияү егете буласың инде! – дип мактап та куйды.

Абдулла оялуыннан комачтай кызарды. Ул бит әле бик кечкенә, аңа алты гына тулып килә. Өйләнергә сайлаган кызы да юк. Олылардан ишеткәне бар ич аның, өйләнергә башта кыз сайларга кирәк. Кыз сайламыйча кияү булалармыни инде! Әтисе моны белергә тиеш ич инде. Ә киемнәре чыннан да матур шул... Шуларны киеп, Көек урамында йөрүен күз алдына китергәч, Абдулла килен сайлау эшен үзеннән-үзе онытты.

Ул арада әтисе, Абдулланың кулы ычкынуын тоеп, борылып карады. Ә улы кечкенә мылтыклар тезеп куелган кибет ишегенә карап телсез калган иде. Нинди матур, шома түтәле чын мылтыклар! Малай әтисенең:

– Әйдә, улым, кызыл билле прәннек алыйк та кайтыйк. Әниең дә чәй куеп көтә торгандыр. Әйдә, – дигәнен дә ишетми, шаккатып карап тора бирде. «Менә шундый мылтыгым булса, мин дә, аръяк Гарифулла абзый шикелле, Мүклесазга үрдәк атарга барыр идем», – дип уйлады ул. Гарифулла абзый, мылтыгын асып, аларның өйләре янынннан узганда, Абдулла да, авылның бүтән малайлары да кыркапка төбенә хәтле аңа ияреп баралар иде.

Анда җиткәч, Гарифулла абзый:

– Ярар, улларым, барыгыз, кайтыгыз инде. Йә мылтык ядрәсе тияр үзегезгә, – дигәч, нәниләр өйләренә йөгерәләр, ә олырак малайлар, келәтләр арасына посып, аучы артыннан карап калалар иде.

Абдулла, еш кына хыялга бирелеп, үзенең Гарифулла абзый шикелле урам буйлап мылтык асып узып киткәнен күз алдына китерә иде. Әнә ул, тирә-ягына карангалап, сызгыра-сызгыра яшел чирәмле урам буйлап атлый. Ә малайлар! Аның әле бер ягына, әле икенче ягына чыгып, кызыгып ияреп баралар...

– Абдулла... Абдулла, дим. Киттекме?

Ә малай, мылтыкка кызыгып карап торуыннан айнып:

– Це-це-це! – дип телен шартлатып куйды. – Әти, әти! Мылтык!

– Һе! Мылтык шул.

– Нәкъ Гарифулла абзыйныкы инде!

– Син аны каян беләсең?

– Ул Мүклесазга үрдәк атарга бара ич.

– Һм... Юк, болар аныкы шикелле түгел. Аныкы чын. Ә болар уенчык мылтык.

– Түтәсе шоп-шома ич!

– Һе-һе-һе! Анысы шома. Тик ядрә белән атмый ул. Бөке белән.

– Үрдәккә тисә, үрдәк егылып төшәме соң?

– Шап итеп. Тисә.

– Әти, әти, дим... Ал әле бер мылтык. Ә?

Абдулланың күзләрендә шулхәтле ялвару иде, әтисе бер аңа, бер тезеп куйган мылтыкларга карап торды-торды да озын мыеклы сатучыга:

– Знакум, давай покажь нам самый хороший ружье, – дип сүз катты.

Озын мыек чылгыйларын бөтереп күтәртеп куйган урыс белән алар бик озак сатулашып, ниһаять, кап-кара көпшәле, ялтырап торган түтәле, кәкре тәтеле кечкенә мылтык сатып алдылар. Абдулла, аның каеш

бавын җилкәсе аша киеп куйгач, нәкъ Гарифулла абзый булды. Ул инде кулын ычкындырып әтисе артыннан түгел, ә янәшәсеннән атлый иде. Алар әле тагын күпме кирәк-ярак сатып алдылар. Абдулла арып артта кала башлады. Моны күргәч, әтисе, көлемсерәп:

– Мылтыклы кеше арырга тиеш түгел, – дип куйды.

Абдулла, терек-терек йөгереп, аны куып җитә, әтисеннән калмаска тырыша иде...

Шулай итеп, Абдулла мылтыклы булды. Аңа мылтык алып биргәнне белгәч, малайлар аны кайткан көнне үк сарып алды:

– Күрсәт әле, малай, ә?

– Ядрәсе дә бармы?

– Атып карадыңмы?

– Бөке белән генә атамыни? Алайса, аның белән каз-үрдәк аулап булмый инде.

Абдулланың моңа кәефе китте.

– Нишләп булмасын, – диде ул. – Әйдәгез әле мәчет күленә. Казларга атып карыйк.

Малайлар мәчет күле янына йөгерделәр. Бер-ике генә атарга өлгерделәр, мәчеттән намаз картлары тарала башлады.

Аларның берсе:

– Кем авыл уртасында кеше казын атып йөри инде, ә? – диде. – Әнә Мүксазга барыгыз, кыр үрдәге атыгыз.

Абдулла бик оялды, ул бу хакта уйлап та карамаган иде шул. Беркөнне ул дуслары Салих, Газиз белән чыннан да Мүксазга барып, кыр үрдәге ауларга ниятләде. Кыяклы түмгәкләр арасында йөзеп йөргән үрдәкне күргәч, Абдулла мылтыгын төзәп маташкан арада, кыр үрдәге пылт итеп суга чумды. Ул арада чыр-чу килгән тәкәрлекләр, малайларның башларына тияр-тимәс очып, аларны өркетә башладылар. Үрдәк тә бүтән күренмәде. Ау уңышсыз чыкты. Аның каравы аучылар бер түмгәк өстендә үрдәк оясы таптылар.

Анда унлап үрдәк йомыркасы бар иде. Малайларның шатлыклары эчләренә сыймады, йомыркаларны, кәләпүшкә салып, өйләренә алып кайттылар.

Абдулла капкадан керүенә әнисенә:

– Әни, әни, менә шушылардан тәбия пешереп бир әле, – дип кычкырды.

Ул арада болдырда әтисе күренде.

Абдулла:

– Әти, менә үрдәк йомыркалары таптык. Өчесе Газиздә, өчесе Салихта да бар әле, – дип, әтисе янына йөгереп килде.

– Әй улым, улым, – диде Габделбари абзый. – Сез тимәсәгез, бу йомыркалардан шундый матур үрдәк бәбкәләре чыгар иде. Ул үрдәк хәзер нишли инде, ә? Булачак бәбкәләрен югалтканга кайгырып үлә бит инде ул. Син аның үлүен телисеңмени?

Абдулла аптырап калды. Чебиләрен саклап йөргән корт-корт тавыкны аның бик күп күргәне бар. Чебиен сыйпарга дип килгәч, ана тавык аның кулын да чукыган иде. Үрдәк тә бәбкәләрен шулай кайгыртадыр бит. Нишләргә соң?

– Әти, әти, мин ул үрдәкне бик җәллим. Әллә йомыркаларны үз урынына илтеп куйыйкмы?

– Менә дөрес итәрсез, улым. Илтегез шул, – диде әтисе.

Абдулла, кәләпүшендәге йомыркаларны саклык белән генә тотып, Салихларга йөгерде. Малайлар йомыркаларны үрдәк оясына илтеп салдылар да, шатланып, өйләренә кайтып киттеләр. Абдулланың әнисе аларны капка төбендә көтеп тора иде. Малайларга ул рәхмәт әйтте дә:

– Беләсезме, бер рәхмәт мең бәладән коткара, – диде. – Менә хәзер сезгә үрдәкләр дә рәхмәт укый инде. Шәфкатьле, миһербанлы егетләр булып үссеннәр дип тә телиләрдер әле.

Абдулла да, Газиз белән Салих та шатланып көлеп куйдылар.

## 2005

# Татарстан китап нәшрияты

Татарстан китап нәшрияты 1919 елның июль аенда оештырыла. Ул Октябрь инкыйлабына кадәр Россиянең төрле төбәкләрендә һәм Казанда эшләп килгән басмаханәләрне бер кул астына туплау, ягъни үзәкләштерү максаты белән төзелә. Төрле елларда төрле исемнәр (Татиздат, Татгосиздат һ.б.) белән атап йөртелгән Татарстан китап нәшрияты – бүгенге көндә дә республикада татар телендә китаплар бастырып чыгаручы төп нәшрият.

Татарстан китап нәшриятын оештыру эшенең башында татар әдәбияты классигы, күренекле җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов тора. Анда Г.Камал, Г.Нигъмәти, Г.Толымбай, Г.Гали, Ф.Сәйфи-Казанлы, Н.Баян, Ф.Кәрим, И.Гази, А.Шамов, Г.Бәширов, С.Хәким, М.Садри, Ә.Юныс кебек язучылар эшли.

Татарстан китап нәшрияты гомумән язучылар тормышы, әдәби хәрәкәт белән тыгыз бәйләнештә яши. Биредә татар әдипләренең китаплары дөнья күрә, татар әдәбияты мирасы ядкәрләре нәшер ителә, әдәбият теориясенә, тарихына кагылышлы басмалар чыга. Ел дәвамында 130–140 исемдә китап нәшер ителә.

Өченче меңьеллыкка аяк баскач кына да нәшриятта Ә.Еники, Г.Бәширов, Г.Ахунов, А.Гыйләҗев, Н.Фәттах, Ш.Галиев, И.Юзеев, М.Мәһдиев, Ә.Баян, Ф.Яруллин, Р.Фәйзуллин, Г.Афзал, Х.Камалов, Т.Миңнуллин, Р.Харис, Р.Миңнуллин, Р.Батулла кебек Татарстан халык язучыларының, халык шагыйрьләренең,




Мөхәммәдьяр, Акмулла, К.Насыйри,
Ш.Мәрҗани, Г.Кандалый, Г.Исхакый, Г.Тукай, М.Җәлил
һ.б. татар әдәбияты классикларының әсәрләре
һәм күптомлыклары дөнья күрә.
«Татар хикәяләре антологиясе», бүгенге татар прозаик-
лары һәм шагыйрьләренең рус теленә тәрҗемә ителгән
әсәрләре, сәнгать әһелләре һәм рәссамнарның альбомнары
басылып чыга.
Татарстан китап нәшрияты яшьләр иҗатына,
балалар һәм яшүсмерләр әдәбиятына аеруча зур игътибар
бирә. Ел саен балалар өчен төрле характердагы, төрле
жанрларны, төрле максатларны күз уңында тотып
әзерләнгән
һәм серияләргә берләштерелгән («Нәниләргә бүләк»,
«Исәнме, мәктәп!», «Табигатькә сәяхәт»,
«Алмаш», «Шәхесләр»,
«Татар тарихы» һ.б. серияләр) 25–30 китап дөнья күрә.
Татарстан китап нәшрияты
татар балалар әдәбиятын пропагандалау буенча
башкарган хезмәтләре өчен
2005 елда Татарстан Язучылар берлегенең
А.Алиш исемендәге премиясенә лаек була.

## *2005*

# «Салават күпере» журналы

«Салават күпере» журналының тәүге саны 1990 елның март аенда дөнья күрә. Затлы кәгазьдә, «җиде» төстә чыккан журналны сабыйлар гына түгел, өлкәннәр дә үз итә, ярата. Республикабызның абруйлы рәссамнары бизәгән, күренекле язучыларның (Ш.Галиев, И.Юзеев, М.Мәһдиев, Р.Мингалим, Р.Фәйзуллин, Р.Бәшәр, Р.Батулла, Р.Миңнуллин, Р.Корбан, Л.Лерон, Р.Зәйдулла, Г.Морат һ.б.) кызыклы, тәрбияви эчтәлекле әсәрләре басылган «Салават күпере»н яратмау мөмкин түгел!

Ул шушы кыска гына вакыт эчендә күпсанлы укучылар арасында киң танылу алды. «Салават күпере»нең «чишмә башында» З.Хөснияр, Л.Лерон, Р.Корбан, Ф.Бәдретдинова, А.Үтәгән кебек шәхесләрнең булуы да зур ихтирамга лаек. «Шүрәле биштәре», «Кыйбла», «Мин бит бу», «Былбыл», «Безнең гаилә» дигән күңелле-акыллы сәхифәләре, төрле кызыклы әдәби бәйгеләре белән укучыларны үзенә даими җәлеп итеп торган «Салават күпере»ндә хәзерге вакытта



З.Хөснияр, В.Нуриев,
Л.Лерон кебек язучылар, Ф.Муллахмәт,
Д.Нәүрүзова кебек рәссамнар эшли.
Журнал, халкыбызның күңел җәүһәрләрен,
классик әдипләребезнең бай иҗатыннан
иң яхшы үрнәкләрне генә алып,
шуларны укучылар игътибарына даими
ирештереп тора.
Тукай, Җәлил, Алиш, Такташ иҗатлары
һәрвакыт журналның игътибар үзәгендә.
Берничә еллар инде «Салават күпере»
журналы «Сыбызгы» дигән кушымта белән
бергә чыгып килә.
Һәр «Сыбызгы», «Салават күпере» кебек үк,
бер күркәм китапны хәтерләтә һәм өч телдә
(татар, рус һәм инглиз телләрендә) басыла.
Балаларны ике дистә елга якын куандырып-
сөендереп торучы «Салават күпере»нә
2005 елда Татарстан Язучылар берлегенең
А.Алиш исемендәге мәртәбәле бүләге бирелә.

## *2006*

# Равил Рахмани

Равил Фәйзрахман улы Рахмани (Кукушкин)
1949 елның 8 маенда Татарстанның
Буа районы Адав-Толымбай авылында
ишле гаиләдә җиденче бала булып туа.
Яшьли әтисез калып, кечкенәдән эшләп үсә.
Туган авылында
сигезьеллык мәктәпне тәмамлагач,
Буадагы А.Луначарский һәм М.Вахитов
исемендәге мәктәпләрдә урта белем ала.
1966–1971 елларда
Казан дәүләт университетында укый,
аспирантура тәмамлый.
Татарстан китап нәшриятында,
Буа районы үзәк китапханәсендә эшли.
Аннары, кабат Казанга кайтып,
Казан дәүләт педагогия институтында,
Казан дәүләт университетында һәм
Татар дәүләт гуманитар институтында
әдәбият укыта.
«Идел», «Татарстан» журналларында эшли.
Татарстан китап нәшриятында «Мирас»
редакциясе мөдире вазифасын башкара.
Нәшриятта эшләгән елларында
Р.Рахмани татар балалар әдәбияты белән
кызыксына башлый.
1985 елда татар балалар шигърияте буенча
кандидатлык диссертациясен яклый.
«Шигъри бишек» һәм «Канатлы дөнья»
дигән хезмәтләрен китап итеп бастыра.
2006 елда шушы хезмәтләре өчен
Р.Рахманига Татарстан Язучылар берлегенең
А.Алиш исемендәге премиясе бирелә.
Равил Рахмани – 1982 елдан
Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.



## ЯЗ КОЯШЫ

Яз кояшы, сөеп, бер елмайса,
Җаны барлар җирдә терелә;
Кышкы тунын иңнән салып атып,
Изүләрен ача бөреләр.

Чуар чыпчык, кабып кояш нурын,
Җылы ташый кышкы ояга...
Каз бәбкәсе чукый кабык өнен:
«Чыгар, – диеп, – якты дөньяга!»

Шук балыклар суз(ы)лып карый язны –
Җыелганнар тәрәз-бәкегә...
Телиләрдер бозны чәрдәкләгән
Ут-кояшка рәхмәт әйтергә.

Бөредәге дәртле аваз сыман,
Тәрәз чиртә җырлар күңелдә!
Хыял шаян... көтми, алга чаба –
Ләйсән яңгырларын күрергә!..

## БОЗ КИТКӘНДӘ

Һәркемнең купкан күңеле,
Эчтән яктырып елмая...
Җил йөгереп хәбәр йөртә:
«Боз кузгалган, боз... елгада!»

Яр буенча тезелешеп,
Шау-гөр килә бала-чага;
Берсен-берсе этә-төртә,
Ташкын суда бозлар ага.

Малайларга тынгы бирми
Ярга якын килгән бозлар:
«Эх, утырып йөзәргә бер кораб итеп,
Күреп калсын иде кызлар!..

Озатсын иде гармуннары,
Китсәң иде ерак йөзеп...
Кайтсаң иде диңгез гизеп
Беркөн – үзәкләрен өзеп!»

# ТАБИГАТЬНЕҢ ҮТӘ СИЗГЕР БЕР ИРКӘСЕ – КЫЗЫЛ КИТАПКА КЕРТЕЛГӘН КЫЛГАННАР ТУРЫНДА ҖЫР

«Таңда сәфәр чыгабыз!..» – дип,
Сөйләшепме куйганнар? –
Саба җиле исәр-исмәс...
Сәламләшә кылганнар!
Кая болай ашыгалар,
Хәтәр хәлме тойганнар? –
Бер-берсенең юлын бүлеп
Йөгерешә кылганнар...
Туган җирдән куганнармы,
Тамырданмы корганнар...
Ярдан чыккан дәрья булып
Дулкынлана кылганнар?!

Дөнья буйлап сибелгәннәр...
Иленнәнме туйганнар?
Гасыр арты гасыр кичеп,
Нәрсә эзли кылганнар?!
Җайдагаттай үргә чаба
Хуннар, кыпчак, болгарлар...
Кырыс тарих түрләрендә
Үлмәс яугир булганнар!
...Инде сүзсез, аксакалдай,
Уйларына чумганнар:
«Кемнәр идек?.. Кем булдык!..» – дип,
Башын чайкый кылганнар.

Эссе сугып, бозда туңып,
Инде мең сыналганнар...
Язмыш җиле җиргә еккан:
Сыгылган – сынмаганнар!
Бигрәк нечкә бәгырьлеләр,
Җаннары – чук кыллардан:
Җиһан сулап куйганга да
Дертләп китә торганнар.
Дәртле, тере дә җырлары...
Тора тоташ моңнардан;
Дала буйлап ятып үкси
Күңелләре тулганнар!..

Җилдә дөрләп янган утка
Әверелә курганнар...
Чыгып заман мәйданына,
Ирек даулый кылганнар!
Уйный, кача, елый, шаша,
Бәргәләнә – кол алар...
Көнгә чыкса, мең халәттә –
Хәтер җебен җуйганнар.
...Килер көнгә күчеп бара, –
Кулын болгый кылганнар...
Киң Рәсәйгә сыймаганнар,
Тәкъдиргә сыенганнар!

## КҮРШЕ ХАКЫ

Әни әйтә: «Күршеләр, – ди, –
Үзебездән яхшырак!»
Ә күрше апа безне мактый...
Белмим, кайсы хаклырак?..

Күрше бездән, без күршедән
Дөрестән дә әйбәтме?
Үз-үзеңнән шәбрәк булу –
Теләктерме, гадәтме?!

Җирдә шундый күршең булмау
Аянычтыр кешегә.
Күрше хакын хаклап яшәү
Һәркемне ул үстерә!

Нигә тарих китабында
Талау һәм үлем генә?..
Өйрәтсеннәр дәресләрдә
Күрше булу гыйльменә!

Бар милләтләр, бөтен илләр
Булсын әйбәт күршеләр...
Рәхәтләнеп, иркен сулап
Яшәр иде кешеләр!

## ӘБИ-БАБАЙ ХАКЫ

Әби-бабай – җанлы тарих,
Җиргә туганнар күптән;
Илдә иң-иң кызык хәлләр
Алар булганда үткән...

Ул заманны китаплардан
Өйрәтәләр дәрестә;
Әби-бабай өйдә сөйли
Киңәйтеп һәм дөресләп.

Әти белән әни туган
Чорга кереп китәләр;
Шул көннәрен саг(ы)нып, ахры,
«Балалар» дип йөртәләр.

Кайчак горур, кайчак сыкрап,
«Яшь буын» дип куялар;
Алар он(ы)тып җибәргәнне
Искә төшереп торалар.

«Туган телдән, туган җирдән
Нигә, – диләр, – бизәргә?..
Үзең теләп, шаулап үскән
Нәсел там(ы)рын өзәргә?!»

Әби-бабай бүгенгегә
Карый шулай тирәннән...
Эшне алар төптән уйлап
Хәл итәргә өйрәнгән!

Мине дә бит алар сөя
Биреп бөтен җаннарын;
Килми «буш чүлмәк» буласым,
Мин – аларның дәвамы!

Җыр өйрәнәм, әкият тыңлыйм,
Керешәбез догага...
«Кеше, – диләр, – чын кеше ул
Эчтә иман булганда!»

Алар һаман без дип яши,
Һаман изге теләктә;
Әби-бабай зур сөюне
Сала белә йөрәккә!
Әби-бабам килер көнне
Күрәләрдер еректан!

## 2006

# «Ялкын» журналы

«Ялкын» журналына 2009 елда 85 яшь тулды. Әмма ул – һаман да үз укучылары яшендә, алар белән сердәш, һәркемнең якын дусты, өйдә көтеп алынган кунак. Гомумән, шәп дус!

Аның юл башы – 1924 елның март аенда Мәскәү шәһәрендә чыга башлаган «Кечкенә иптәшләр» журналы. Оештыручысы һәм дөньяга чыгаручысы – каһарман шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе М.Җәлил, беренче редакторы – Х.Курмаев. 1928 елдан, гарәп графикасын латинга алмаштырып, журнал «Октябрь баласы» исеме белән Казанда басыла. 1933 елдан «Пионер каләме»нә үзгәртелә. Бу чорда яраткан язучыбыз А.Алиш журналда җаваплы сәркатип булып эшли. Бөек Ватан сугышы чорында журнал басылудан туктап тора һәм сугыштан соң бары тик 1952 елда гына «Пионер» исеме белән яңадан торгызыла.

1957 елдан «Ялкын» исеме белән чыга башлый. «Ялкын» озак еллар буе балаларның яраткан журналы, иҗатка тартылучылар өчен каләм чарлау урыны, пионер эшен җанландырып җибәрүче мәйдан булып хезмәт итә.

Аның битләрендә һәрдаим талантлы балалар, уку һәм хезмәт алдынгылары, яшь музыкантлар, яшь галимнәр турында материаллар урын алып торган, республикакүләм акцияләр, конкурс-бәйгеләр уздырылып килгән. Тимурчылар хәрәкәте, пионер оешмасы уздыра торган башка матур чаралар яктыртылган.












Хезмәтләре өчен аңа 1984 елда «Почет Билгесе» ордены бирелә.
«Ялкын» әдәби әсәрләрне дөньяга чыгару,
аларны пропагандалау буенча да зур эш башкара.
М.Җәлил, А.Алишлар оештырып җибәргән журналда башкача була да алмас иде. Бер үк вакытта балаларны әдәбиятка тарту буенча да эш алып бара.
«Ялкын» аша олы әдәбият мәйданына килгән язучылар бик күп.
30 нчы елларда мәктәп укучылары Җ.Тәрҗеманов, Ш.Мөдәррис «Пионер каләме»нә язышa, 60 нчы елларда – М.Әгъләм,
80 нче елларда – Р.Зәйдулла, Л.Лерон.
Ә 2000 елларда басылган С.Гаффарова, Л.Янсуар, Г.Гарипова, Л.Шәех, Г.Корбанова, Э.Җәлилова, Г.Җәлиловалар – хәзер үзләре китап авторлары.
Бүгенге хәбәрчеләребез Л.Фәтхетдинова, А.Габделхакова, С.Мөхәммәтҗанова, Г.Яппарова, Л.Исхакова, Р.Шәеховаларның да киләчәге өметле.
«Ялкын» үзендә эшләп киткән, иҗат белән шөгыльләнгән язучы-шагыйрьләр белән дә горурлана. Алар арасында Р.Хафизова, Г.Сабитов, И.Юзеев, Л.Ихсанова, Р.Вәлиев, Х.Гайнетдин, Ф.Сафин, Җ.Дәрзаманов, З.Хөснияр, Ф.Зөлкарнәй, Л.Зөлкарнәй һәм башка бик күпләр бар.
«Ялкын» журналы бер үк вакытта бер гасырга якын салынып килгән традицияләргә тугрылык та саклый, заман белән бергә дә атлый.
Бүген дә «Ялкын»да әдәби әсәрләр басыла, республикабыздагы балалар тормышы, сәнгать дөньясы, мәктәп темасы чагылыш таба.
Замана яшүсмерләрен борчыган проблемалар: дөньяда үз урыныңны табу, үз йөзеңне саклап калу, тискәре күренешләрдән саклану кебек мәсьәләләр күтәрелә. Шуларга һәм башка бик күп темаларга балалар, үсмерләр үзләре сөйләшәләр, үз фикерләре белән чыгыш ясыйлар.
«Абитур», «Борчылам, шуңа язам да», «Малайларга, кызларга...» сәхифәләре, «Тәнәфес», «Глобус» проектлары,
журналда даими оештырылып килгән бәхәс-дискуссияләр шуларның бер өлеше генә.
Балалар әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре һәм А.Алишның иҗат һәм тормыш юлын пропагандалау буенча зур эш башкарганы өчен 2006 елда «Ялкын» журналына Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясе бирелә.

*2007*

## Алмаз Гыймадиев



Алмаз Марс улы Гыймадиев
1972 елның 20 июлендә Татарстанның
Биектау районы Зур Битаман авылында туа.
1988 елда Зур Битаман урта мәктәбен
тәмамлаганнан соң,
Казан дәүләт университетының татар
теле, әдәбияты һәм көнчыгыш телләре
факультетында югары белем ала.
1991–1996 елларда «Сабантуй» балалар
газетасында,
1996–1997 елларда Әтнә районы
хакимиятенең мәдәният бүлегендә эшли.
1997 елдан ул – «Казан утлары»
журналында җаваплы сәркатип.
Үткән гасырның 90 нчы елларыннан башлап
А.Гыймадиевның кырыкка якын
шаян хикәяне туплаган
«Тә-нә-фес, яки Маҗаралы хәлләр»,
«Хуш, Тамчыгөл!», «Без андый малай
түгел!» һ.б. китаплары дөнья күрә.
2001 елда А.Гыймадиевка «Тә-нә-фес,
яки Маҗаралы хәлләр», «Хуш, Тамчыгөл!»
китаплары һәм «Сабантуй» газетасында
басылган язмалары өчен
Татарстан Язучылар берлегенең
Ш.Маннур исемендәге премиясе һәм
Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән
«Ниязның рекордлар китабы» өчен
2007 елда Татарстан Мәдәният министрлыгы
һәм Язучылар берлегенең
А.Алиш исемендәге премиясе бирелә.
Алмаз Гыймадиев – 1995 елдан
Татарстан Журналистлар берлеге
һәм 1998 елдан
Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

## НИЯЗНЫҢ РЕКОРДЛАР КИТАБЫ

Элеккеге командир Гамилә Төркиягә укырга китү сәбәпле, Ниязны класс старостасы итеп сайлап куйдылар. Иртәгесе көнне үк ул җыелыш җыйды.

– Әйдәгез, безнең алтынчы класс өчен «Гиннесснең рекордлар китабы»н ачып җибәрәбез, – дип башлады Нияз үзенең чыгышын. – Кызык бит, мәсәлән, Сәлим алты сәгать буе бертуктамый сөйләшә ала, тикмәгә генә укытучылар «ватык патефон» димиләр аңа. Әхәт исә любой ераклыктан, любой позада, любой язуны укытучыга сиздермичә күчерә ала. Мисалга Тәслимәне алыйк, ул – безнең сагыз чәйнәү остасы. Әнә, авызындагы кызыл төстәге сагызын декабрь башында чәйни башлаган ие... Йә, нинди фикерләр?

Класс Ниязның идеясен бердәм хуплады. «Писер» итеп сары чәчле Наиләне сайлап куйдылар. Алтынчының рекордлар китабына шулай итеп яшь рекордчылар теркәлә башлады:

1. Фәнис мәктәпкә кыш уртасында ай да унсигез көн яланбаш килде, колаклары өшемәгән булса, тагын да шулай йөрер иде әле.
2. Хәмит – класста иң озын малай. Аның буе – метр да алтмыш.
3. Тәслимә ярты ел буе гел «Му-му» конфетын суырып йөрде. (Дөрес, энекәше Мәрдәннең әйтүенә караганда, аның кәгазе генә «Му-му»ныкы булып, эчендә башка конфет яисә бөтенләй ипи катысы гына булган, чөнки әтиләре ярты гына кило «Му-му» алып кайткан булган. Ләкин тотылмаган карак карак түгел – Тәслимәне барыбер китапка керттеләр.)

«Рекордлар китабы» класс почмагындагы зур кадакта эленеп торды, Наилә бик тырышып аны тутырып барды. Китапка кемнәрне кертү мәсьәләсен Нияз класс җыелышында хәл итте. Тора-бара рекордчылар шулхәтле артты, кайберәүләр бу китапка көнгә өчәр тапкыр язылды. Мәсәлән, шул ук Сәлим бер сәгатьтә чәпләшке белән туксан биш чебен үтергән, шул ук Сәлим физика дәресендә алты тапкыр бәдрәфкә чыгып кергән... Соңга таба укытучыларны да китапка кертә башладылар: «Сабира апа бер дәрестә генә дә сиксән дүрт тапкыр «әгәр дә мәгәр» диде, Хәләф абыйның унбиш мәртәбә тәмәке тартканын күргәннәр, Гайния апаларның сыеры берьюлы өч бозау китерде...»

Ә беркөнне, рекордлар китабына эләгергә теләп, алтынчының малайлары тәнәфестә төкерү ярышы оештырганнар. Мәктәп почмагында үткәрелгән әлеге ярышта Фидаил җиңгән. Ул дүрт метр ераклыкка төкергән. Әмма төкерек һавада матур гына траектория белән очып барганда, почмактан директор килеп чыккан һәм... калганын сөйләү түгел, күз алдына китерүгә үк аркалар чымырдый башлый.

Озын сүзнең кыскасы – шушы хәлдән соң «Ниязның рекордлар китабы»н кабат ачылмаслык итеп ябып куйдылар.

## БҮЛӘК

Мине мәктәптә Дезодорант Рәсим дип йөртәләр. Бигрәк ямьсез кушамат инде, иеме? Гел уйламаганда ябыштырдылар миңа аны. Шул бәйрәмнәр аркасында килеп чыкты инде.

23 нче февраль көнне классташ кызларыбыз һәрберебезгә берәр одеколон бүләк итте. Без – егерме ике малай – кызларга чын күңелдән рәхмәт әйттек. Гомумән, ул көн күңелле узды. Алдан килешү буенча берберебезгә начар сүзләр әйтешмәдек, талашмадык. Хәтта мәктәптә явызлыгы белән даны чыккан Дию Фоаты да түзде: «Егерме өче генә үтсен, иртәгә барыбер берсен тотып тукмыйм!» – дип, йодрыгын кашып йөрде.

Бәйрәм ашы – кара-каршы, диләр. Без дә кызларыбызны 8 нче Мартта сөендерик, дидек. Өч кенә бөртек ич алар! Яхшы гына суммадан җыелыштык та бүләк алырга булдык. Авыл кибетендә юньле нәрсә юклыгын үзегез беләсез инде. «Рәсим, синең урысчаң да яхшы, шомалыгың да бар, давай, иптәшкә Бөтнек Әмирен ал да Казанга сыпырт! – диеште малайлар. – Бүләкнең шәбен ал!» – дип кычкырып калдылар арттан.

Шулай итеп, чыгып киттек без Әмир белән. Кесә тутырук акча. Әле әти белән әни дә өстәде! Шәһәргә барып ач йөрмәссең бит инде! Өч бөртек кызга ул акчага әллә ниләр алырга була. Беразын туздырсаң да сизелми әле. Шунлыктан автобус көтеп тормадык, бер «Жигули»ны туктаттык та – выжт!

Казанда булмаганга өч-дүрт ел бар иде. Бөтен нәрсә үзгәргән. Тимер юл вокзалының бер багана төбендә пычрак киемле, битен сакал-мыек баскан ике абыйны күреп дерт итеп киттек. Алларында буш шешәләр. Мөгаен, шешә тапшырырга барган җирләреннән егылып калганнардыр. Берсе, күзгә керердәй булып, инәлеп акча сорый. Бик кызгандык без боларны. Ун сум биреп калдырдык. Икесенә дә.

Ике адым гына атлаган идек, каршыда морожный киоскысы пәйда булды. Шәһәргә барып морожный ашамый кайталар димени! Мал-лай! Морожный да үзгәргән икән хәзер – шоколадка төреп тә, төрмичә дә саталар. Ниндиләре генә юк! Сатучыга акчаны сузган идем, әллә каян гына күз явын алырлык чибәр ике кызчык пәйда булды.

– Мальчики, безне дә угощайте, – диләр, үзләре чырык-чырык көләләр.

Әмирнең дә авыз ерылды. Шту син! Шәһәр кызлары белән танышу теләсә кемгә тәтеми ул! Бәлки, кино-фәләнгә алып керербез үзләрен, дип, и-и план корабыз эчтән генә.

Тагын кесәгә кереп киттек.

– Мальчики, без берьюлы икешәр мороженое ашыйбыз, – диләр болар.

Каршы килеп булмый бит инде! Гүләйт тек гүләйт! Кайткач, малайларга мактанып сөйләргә бер нәрсә булыр хет.

Ие, мактандык! Кулларына икешәр морожный тоттыргач, кызларыбыз «спасибочки» дип чыркылдаштылар да әллә каян гына килеп чыккан ике малай белән култыклашып китеп тә бардылар. Калдык авызны ачып.

Ярар, кепкаларны батырып кидек, кулларны кесәгә тыктык та, бераз бөкрәя төшеп

Казан малайлары кыяфәтенә кергәч, дәлше киттек.

Аннан соң грузиннар пешергән ике таяк шашлык, дүрт пирожки, ике стакан «Кокакола», бер стакан һава кукурузы, уен автоматы «йоткан» өч йөз сумны исәпләмәгәндә, бүтән акча туздырмадык.

Көн кичкә авышканда санап карасак... Акчабызның кайтырга автобус билетына да җитмәгәне ачыкланды. Бүләк тә алынмаган...

Бер кибеткә кердек. Балта, кадак, идән буявы белән беррәттән әллә ничаклы матур духи, дезодорантлар тезелеп киткән. Вәт, малай, бәхет басты! Иң арзаны – унбиш сум гына! Шунысын, «Карбофос» дигәнен өчне алдык та «куян»нар булып автобуска кереп чумдык. Ничек кысыла-кысыла кайтуыбызны, төшкәндә минем сыртка, Әмирнең артына тибүләрен сөйләп тормыйм.

Мәгәр малайларның без алып кайткан дезодорантка никтер исләре китмәде:

– Кызларга үзең тапшырырсың! – диешteләр төксе генә.

Тапшыруын тапшырдым... Әмма ахыры ни белән бетәсен белгән булсам! Кызларыбызның берсе, Гөлчәчәк исемлесе, дезодорантны шунда ук муенына сиптереп тә карады.

Мал-ла-ай! Класста берәү дә калмады! Ул «Карбофос» дигән нәмәрсә тараканнарга, коңгызларга каршы сиптерә торган сасы исле бер нәмәрсә икән.

Менә шуннан соң Дезодорант Рәсим дип йөртәләр мине. Бигрәк ямьсез кушамат инде, иеме?

*2008*

## Вакыйф Нуриев



Вакыйф Вәкил улы Нуриев 1958 елның 17 августында Татарстанның Арча районы Сеҗе авылында туа.

Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1975 елда Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керә.

Бишенче курста укыганда, «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасы редакциясендә эшли. Университетны тәмамлагач та шунда кала. Җаваплы сәркатип, баш редактор урынбасары була. 1987–1990 елларда Татарстан китап нәшриятының сәясәт редакциясе мөдире вазифасын башкара.

1990 елда ул яңа оешып килгән «Шәһри Казан» газетасы редакциясенә эшкә күчә. Башта – бүлек редакторы, 1995–2000 елларда баш редактор урынбасары булып эшли.

Бүгенге көндә Вакыйф Нуриев – Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, «Салават күпере» һәм «Сәхнә» журналларының баш мөхәррир урынбасары.

Вакыйф Нуриев – төрле газета-журналларда дөнья күргән җиде дистәгә якын хикәя авторы. 1991 елда аның Татарстан китап нәшриятында «Бүре кадәр бүрек» дигән хикәяләр җыентыгы дөнья күрә. Җыентыкка кергән әсәрләрнең геройлары дөньяны үзләренчә аңлаулары, яхшы күңелле булулары, ара-тирә бераз ялкаурак, малайларча бераз мактанчыграк булулары белән аерыла.

Соңгы елларда язучы күләмлерәк әсәрләргә («Җиденче палата», «Карга карагы», «Әбиемә – әфлисун») мөрәҗәгать итә башлый. 2007 елда алар барысы да Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган «Җиденче палата» дигән китапта урын ала.

1998 елда В.Нуриевка «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән исем һәм 2008 елда «Җиденче палата» дигән китабы өчен Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясе бирелә.

Вакыйф Нуриев – 2004 елдан Татарстан язучылар берлеге әгъзасы.

## КИТАП

Артур Казанның Имәнлек урамында яши. Бакчага Сукно бистәсенә йөри. Иртән аны бабасы илтә. Бистәгә автобуста барасы. Бүген дә «Газель»гә кереп утырулары булды – кондуктор билет алырга тыкырдата башлады.

– Сез кичә дә түләмичә төшеп киттегез, – диде ул, автобусны яңгыратып. – Акча өйдә онытылып калган, дигән булдыгыз. Карап карыйк, бүген дә шул тукталышта төшмәссеңме әле, бабай?!

Артурның да, бабасының да бу сүзләргә хәтере калды. Нишләп алдашсын инде аның бабасы! Акча чыннан да өйдә калган иде. Шуның аркасында беренче тукталышта ук төшеп калмыйча булмады.

Автобус кузгалып китеп күп тә үтмәде, Артурның тавышы яңгырады:

– Бабай, калган, өйдә калган! Китап калган!!!

Ул китапны бабасы кичә генә сатып алган иде. Әкият-поэманы малай тын да алмыйча тыңлады. Рәсемнәрен йомшак куллары белән сыпыра-сыпыра карады. Шул китапны кич буена күтәреп йөрде, шул китапны кочаклап йокыга китте. «Шул китапны бакчага алып барам, барысына да күрсәтәм», – дип хыялланды. Аңа карап бабасы уйланып утырды: «Аллаһы Тәгалә адәм баласын китап ярата торган итеп тудырган. Өстәлгә уенчыклар тезегез һәм китап куегыз. Сабый иң әүвәл китапка үреләчәк. Баланы китаптан без үзебез биздерәбез. Ул конфет сораганда да тозлы балык бирәбез».

– Ярый инде, улым, китапны иртәгә алып барырбыз.

– И бабай, минем бүген күрсәтәсем килә аны. Кире өйгә кайтып алыйк китапны! – Малай җиңелчә генә дымланып торган күзләренә мул итеп ялыну-ялвару билгеләре чыгарды.

«Әйе шул, нигә әле сабыйны шундый зур шатлыгыннан мәхрүм итәргә?! Юк-бар әйбер сорамый, китап сорый», – дип уйлап алды бабасы һәм Артурны җитәкләп ишеккә юнәлде.

Беренче тукталыш. Алар бүген дә төшеп калырга мәҗбүр булды.

Кондуктор артларыннан кычкырып калды: «Менә әйттем бит. Кичәге ялганың бүген тотылды. Бабай башың белән «куян» булып йөрмәсәң. Бик шәп үрнәк күрсәтәсең икән оныгыңа!»

Кондукторның нахак сүзләрен алар әллә ишетте, әллә юк, йөгерә-атлый өйләренә таба киттеләр.

Өйдә аларны Габдулла Тукайның ихлас елмаеп, шаян-шук күзләрен ялтыратып, онытып калдыруларына бераз гына нәүмизләнеп, сөйкемле «Шүрәле»се көтеп тора иде.

# ХУҖАЛАР ТАВЫНДА

Әнә ул куе, яшел бөдрәләр белән капланган шагыйранә мәһабәт тау. Бу – Хуҗалар тавы. Тау астында – калын су толымын кояш нурында чайкап, ургылып бәреп торган галиҗәнап чишмә. Бу – Изгеләр чишмәсе. Данлыклы Биләр җирендәге бу урын – үзе дә изге урын.

Идел-Чулман. Болгар дәүләте. Баш каласы – Биләр. Ата-бабаларыбыз Изге чишмә буенда корбан чалган, Хуҗалар тавына менеп, кыйблага карап, гыйбадәт кылган. Бүген дә изге урынга ераклардан киләләр. Ата-бабаларыбыз рухына, әрвахлар рухына багышлап корбан чалалар, табын җәеп, Коръән укыйлар, изге туфракка баш ияләр. Күңелләрен сафландырып, пакьләндереп китәләр. Изге чишмә суыннан сихәт алалар. Аны тәнеңә койсаң, чиреңне дә юып төшерә, диләр. «Их, коенырга иде шул су белән» дип уйлап куйды Рамил. Үзеннән бигрәк әбисенең коенуын тели ул. Коенсын иде, югыйсә соңгы вакытта сырхаулап тора.

Әбисе авырып түшәккә ятса, оныгының күгүен кара болыт каплый, һай, ул көннәр. Рамил нишләргә белми. Әбисенең өстенә ябып карый, чәй китереп карый. Ярты йөрәген бирерлек була малай. Авырмасын иде инде әбисе.

Башкалар аш хәстәрен күреп, табын әзерләп тыз-быз йөргәндә, Рамил әбисе белән чишмәгә китте.

Менә ул Изге чишмә. Көн эссе. Монда салкынча, җиләс һава, сафлык-пакьлек бөркелеп тора. Тирә-юньгә күңелне ымсындырып көмеш нурлар чәчри. Кәүсәр суны тизрәк учка аласы, татып карыйсы килә.

Рамил кизләүгә иң әүвәл әбисен уздырды.

– Бисмилләһир-рахмәәнир-рахим.

Галимә карчык ашыкмыйча, ипләп-җайлап кулларын юды. Көмеш су белән битен-маңгаен сыпырды. Йөзе яшәреп, тагын да балкып-яктырып китте.

Саф, тәмле, кояшлы-якты суны йотканда, әбинең күңеле дә шушы моңлы чишмә кебек җырлый иде.

Изге су Рамилнең дә йөрәгенә ятты.

Изге чишмә! Сусауны гына басып калмыйча, күңелне пакьләндереп, җанны сафландырып, яшәртеп, көч биреп, куәт өстәп җибәрә торган изге су!

Ни өчен изге соң ул?

Изге таудан бәреп чыккангамы? Кайчандыр шушы таудагы крепостьны дошманнардан саклап шәһит киткән кырык кызның каны тамган җирдә булгангамы?

Әбисе Рамилгә ошбу чишмә турында бер риваять сөйләде. 11–12 яшьлек өч кыз урманга баралар. Йөри торгач, адашалар. Үтереп эчәселәре килә. Шунда алар менә шушы аланга килеп чыгалар. Әлеге дә баягы биек тауга карап, Ходайдан ярдәм сорыйлар. Шул вакыт кызлардан бераз читтәрәк Мәрьям ана пәйда була һәм күз ачып йомган арада югала да. Ул басып торган урында чишмә тибеп чыга. Кызлар рәхәтләнеп су эчәләр, юыналар, коеналар, хәл алалар. Үзенең изге суы белән кешеләрне сөендерә, савыктыра торган чал чишмә әнә шул көннән бирле ага да ага.

Суга тилмергән кызлар... Ходайның рәхмәте белән ташып чыккан өр-яңа чишмә... Теләкнең кабул булуы...

Риваятьне гаҗәпкә калып тыңлаган Рамил башын чайкап куйды.

– Әби, бүген чишмә суы белән без дә коенабыз. Син дә коенырсың, яме! – диде ул.

Галимә карчык кеткелдәп көлде.

Аланда шарт-шорт учаклар яна. Учаклардан күтәрелгән сыек төтен зәңгәрсу рәшә булып тирбәлә. Казаннарда гөбер-гөбер ит кайный. Тирә-юньгә ит исе тарала. Кемдер сарыкны түшкәсе белән кыздыра.

Симез итнең эреп тамган кайнар маеннан учак чаж-чож итә. Урман аланында ашкынулы хәрәкәт, мәгънәле ыгы-зыгы, тантаналы күтәренкелек. Подносларда – әфлисун, өрек, хөрмә. Куна такталарында – төрледән-төрле пироглар, гөбәдия, өчпочмак, коймак, кыстыбый.

Аш пеште. Ит өлгерде. Рамилнең әбисе, әти-әнисе, туганнары өстәл янына түгәрәкләнделәр. Рамилне дә үзләре янына утырттылар.

Галимә карчык Коръән укыды. Карчык укый. Җаннарны айкый торган мәкам белән чыккан сабыр тавыш тауга сугылып-сугылып ала, тирән тынлыкта утырган урманга бәрелеп-бәрелеп куя. Ул укыганнарын вафат булган туганнарына, шушында утыручылардан дога өмет иткән барлык-барлык әрвахларга багышлады.

Табында өлкәннәр белән бер чуттан утырган, башына чигүле түбәтәй кигән Рамил әбисе укыганнарны йотылып тыңлады, мае елык-елык итеп торган сарык түшкәсе шулпасында пешкән токмачлы ашны, шакмаклап туралган хәләл итне тирләп-пешеп, мәмнүн булып ашады.

Коръән ашын ашагач, өстәлдәге сыйнигъмәтләрдән авыз иткәч, Хуҗалар тавына менделәр. 444 баскычны менү җиңел булмады. Җитмәсә, көне дә эссе, бөркү. Барысы да менделәр. Рамил дә менде. Ничек менмәсен?! 70 яшьлек әбисе менгәнне.

Баскычтан күтәрелгәндә, агач ботакларына бәйләнгән төрле чукларга, чүпрәк-чапракка игътибар итте малай. «Мәҗүсилектән калган ырым-гадәт бу», – дип аңлатты әбисе.

Тау башында өч кара таш. Бу мәҗүсиләргә, мөселманнарга һәм христиан динен тотучыларга багышлап салынган монумент икән. Икенче Иерусалим диләр моны. Кемнәр генә килми бирегә?! Мәҗүси дә, мөселман да, христиан динен тотучы да – барысы да килә.

Тау башында Рамил тагын бер риваять тыңлады. Монысын да әбисе сөйләде: «Яшәгән, ди, булган, ди, бер кыз. Бик матур булган ул: түгәрәк йөз, томрап торган зур күзләр, дугалы кашлар, озын керфекләр. Әллә инде күз тигән, кыз авырый башлаган. Көннән-көн сула-сызыла бара икән мескен. Нишләргә дә белмичә кайгыга баткан әтисе белән әнисе җәйнең бик эссе бер көнендә газиз балаларын шушы тауга алып менгәннәр. Ходайдан ярдәм сораганнар. Шул вакыт ни булган дисезме? Нәкъ менә кыз яткан урынга яңгыр коеп яуган. Шуннан бераз читкәрәк бер тамчы да төшмәгән. Яңгыр суы кызның битен, кашларын, керфекләрен юган, күлмәге манма су булган. Шуннан соң авыруның кипкән иреннәре дым тарткан, сулган йөзенә төс кергән, саргайган битенә кызыллык йөгергән. Кыз савыгып аякка баскан».

Әбисе сөйләгәннәрне гаҗәпләнеп тыңлап торган Рамил, сусаудан кипкән иреннәрен кысып, баш чайкап куйды.

Бу риваятьне тыңлагач, аның әбисен салкын чишмә суы белән коеныргa күндерү теләге тагын да көчәйде.

Тик ничек күндерергә соң аны? Коену өчен монда махсус урын да бар югыйсә. Суны чиләк белән алып киләсең дә кабинага керәсең... Аллаһе әкбәр!

– Әби, әйдә инде, коен инде!

– И улым... гомергә булмаганны.

– Бер авырлыгы да юк ич инде аның, әби. Чиләкне күтәрәсең дә... Шалт, Мөхәммәтҗан!

– Юк, улым, юк. Булмый. Кыстама.

Ах, бу әбисе! Бигрәк үзсүзле. Юк, аны коеныргa аркан белән тартып та китереп булмаячак.

Уйлый торгач, малайның башында бер план туды. Әбисен үзе коендырачак ул. Бер

чиләк суны шыпан-шыпан гына алып киләчәк тә сиздермичә генә... һоп-па!.. Рамил әбисенең чия төсендәге бәрхет калфагына, ак җирлеккә ак чәчәкләр төшерелгән читләре челтәрле чуклы яулыгына, нәфискурач гәүдәсенә бик килешле ятып торган йон кофтасына, милли бизәкләр белән бизәлгән күн читекләренә карап куйды. Киемнәре чыланыр инде. Чылансынсанә. Бу эсседә кибәр әле. Аның каравы изге судан тәненә шифа-сихәт алачак.

Әүвәл Рамил үзе коеначак. Менә алар әтисе белән бер кабинада. Алларында су белән мөлдерәмә тулы чиләкләр.

Әтисе, ике дә уйламыйча, бер чиләк суны башына уптымилаһи каплады. Рамил генә тәвәккәлли алмый азапланды. Чиләкне баш очына күтәреп тә карады. Су тимәс борын, тәне чымырдап куйды. Әтисе икенче чиләк суны алып килгәндә дә, малай коп-коры иде әле. Әтисе күп уйлап тормады, тотты да кулындагы суны улының өстенә орды. Рамил шундый каты кычкырып җибәрде ки, биш мәченең биш койрыгына берьюлы бастылармыни. Салкын су, малайның сулышын кысып, бөтен тәнен куырып алды.

Әбисен коендыру уеннан шул минутта ук ваз кичте ул.

Ул көнне Рамилләрнең табынындагы самавырны кат-кат яңарттылар. Эссе көндә авыз гел кибеп тора. Аннары, туганнар кайчан шулай барысы бергә җыелып тәмләп чәй эчәр иде әле. Күптән күрешмәгәнгәме, сөйләшер сүз дә күп иде. Ул сүзләр күңелдә җыр булып та туды:

Бакчаларда гөлләр түтәл-түтәл,
Арасыннан былбыл кош үтәр;
Гомерләр дә шулай үтәр-китәр,
Бергәлеккә, туганкай, ни җитәр!

Биргән садакаларга, сый-нигъмәтләргә дога кылып, кайтырга кузгалабыз дип торганда, Галимә карчык әйтеп куйды: «Аллага шөкер, барысын да күрдек, сыйландык. Рәхмәт барыгызга да! Догаларыбыз, укыганнарыбыз кабул булсын инде, Ярабби Ходаем!» Аннары уенын-чынын бергә кушып болай дип өстәде: «Тик менә Изге чишмә суы белән коенып кына булмады».

Тәңре кортканың сүзләрен дә ишетте, ахры. Күп тә үтмәде, күк йөзен кара болыт каплап алды. Тау-таш җимерердәй булып күк күкрәде. Орып-орып яңгыр яварга тотынды. Ул туры гына яумыйча, кыеклап бәреп, беседкада утырган Галимә карчыкны да керендереп коендырды. «Менә коенырга да насыйп булды, Ходайның рәхмәте, – диде Рамилнең әбисе, – изге җирнең яңгыры да изге».

Яңгыр туктагач, күңелләренә якты-матур тәэсирләр ияртеп, кайтырга кузгалдылар. Хуҗалар тавының күккә үрләгән яшел балкышы аларны назлап озатып калды.

Юлга чыккач, барысы да гаҗәпләнде: бәй, тирә-юнь коп-коры. Яңгырның эзе-әсәре юк. Алар, туган авылларына кайтып җиткәнче, берничә район аша үттеләр. Беркайда да явым-төшем булмаган.

Рамил тагын иреннәрен кысып, ияген шадраландырып баш чайкап куйды.

Яңгыр фәкать Хуҗалар тавына гына яуган иде...

# ИНША

Класс инша яза. Әкрәм генә язмый. Ручкасын чәйни. Чәйнәмәс иде – ни язарга белми. «Мин кибетче булам, – дип сырлый партадашы Ләлә. – Рәхәт эш ул». Арткы партадагы Кави сарык фермасында әтисе кебек мөдир булырга тели. «Иртән эшкә килгәндә, бөдрә йонлы бәрәннәр күзеңә карап көтеп торалар. Аларга көрпә сибеп чи бәрәңге бирсәң, бернәрсә кирәкми», – дип яза. Шул ук партадан Озын Сабир йә капитан, йә майор булам дип җенләнә. «Уйлап карагыз, каршыңда – бер көтү солдат. Погоннарыңдагы йолдызларыңны балкытып, яннарына килеп басасың. «Смирно!» – дип акырасың. Безнеңчә «Үрә кат!» инде. Тегеләр катып кала», – дип тезә.

Әкрәм авызыннан ручкасын ала. Алак-ялак карана. Ятып калганчы, атып кал дигәндәй, әле теге күршесеннән, әле монысыннан (кайсы күчертә бит!) күчерергә тотына. Тәнәфескә чыкканда, укытучыга менә мондый инша тапшыра: *«Мин кибетче булам. Рәхәт эш ул. Фрукты кибетенә эләксәң, кавын белән карбызны сыпыртасың гына. Кешеләргә дә сатасың. Иртән эшкә килгәндә, бөдрә йонлы бәрәннәр күзеңә карап көтеп торалар. Аларга көрпә сибеп чи бәрәңге бирсәң, бернәрсә кирәкми. Күп бирәсе түгел түлке. Хәзер азрак биреп, күбрәк алганны мактыйлар. Акча дигәнең янга да калсын. Азрак табыш та булмагач, ничу йөрергә ул бәрәннәр арасында. Сарык фермасында эшләве бик кызык. Погоннарыңдагы йолдызларыңны балкытып, яннарына килеп басасың. «Смирно!» – дип акырасың. Барысы да үрә ката. Катмый калганы йолдызыңа кызыгып карап торган була. «Отставить!» – дисең. Тагын үрә катарга кушасың. Барысы да катып бетә. Шуның белән минем инша да бетә».*

# ГӨМБӘ ОЯСЫНДА

Соңгы дәрес бетүен белдереп кыңгырау шалтырауга, балалар шау-гөр килеп ишектән чыга башладылар. Шулчак Зәки дусты Рәхимне җиңеннән тартып туктатты. Кеше ишетмәсен дигәндәй, пышылдап кына әйтте: «Хәзер үк китәбез, яме. Югыйсә Ильясның да иярүе бар. Урманга барганда, миңа да эндәшерсез, дип, бүген дә ике тапкыр әйтте инде. Ни пычагыма ул безгә. Кичә мәсьәләсен дә күчертмәде әле. Аннары тагын шул, урманга күп кеше барып юньләп гөмбә җыеп буламыни...»

Малайлар өйләренә кайтып тиз-тиз генә капкалап алдылар да чиләк эләктереп урманга юл тоттылар. Зәки җиңел сулап куйды. Болай булгач, Ильясны төп башына утырттык дип уйлады ул эчтән генә.

Баруы күңелсез булмасын өчен, малай былтыр гөмбә җыйган чагын сөйли башлады:

– Мин гөмбәнең оясын беләм. Былтыр шуннан берүзем ике чиләк җыеп алып төштем. Валлаһи менә!

– Кайда соң ул?

– Баргач күрерсең. Былтыр, әйтәм бит...

– Ак гөмбә бармы соң анда?..

– Әйтәм бит, дыңгычлап тутырылган ике чиләк ап-ак гөмбә алып кайттым...

Ул арада малайлар урман авызына якынлашып киләләр иде. Ләкин артларыннан кем-

неңдер кычкырган тавышы аларны борылып карарга мәҗбүр итте.

– Ильяс! Ильяс йөгерә. Кай арада күреп алган диген син аны! Кирәкле кишер яфрагы. – Зәки бу сүзләрне тешен кысып кына әйтте. – Тәк, болай итәбез. Урманга кергүгә сызабыз аның яныннан, йөрсен шунда берүзе аптырап.

Зәки тагын нидер әйтмәкче иде дә, яннарына мышный-мышный Ильяс килеп җитүгә туктап калды.

– Уф! Тәки куып җиттем бит. Урман тавыннан менеп баруыгызны күрдем дә йөгердем генә.

– Бәй, без сиңа әйтергә оныткканбыз, – диде Зәки, хәйләкәр елмаеп һәм Ильяска сиздермичә генә сул кулы белән Рәхимнең кабыргасына төртеп алды. Сөйләшкәнне онытма, янәсе.

Урманга кергәч тә Зәки кызып-кызып атлавын дәвам итте. Ул черек төпкә эләгеп чак кына абынмыйча калды. Аның шулай кабалануыннан, ашыгып атлавыннан гөмбәне беренче булып табасы һәм чиләкне беренче булып тутырасы килүе сизелеп тора иде.

Ильяс белән Рәхим, киресенчә, ашыкмадылар.

– Урман көз көне бигрәк тә матур була икән, ә, Рәхим, – диде Ильяс, соклануын яшерә алмыйча.

– Әйе шул!..

Атлаган саен аяк астында коры яфрак өеме кыштырдый. Чаганнарга ут капкан диярсең – алар кызгылт-сары ялкын эчендә балкып утыралар.

– Рәхим, кил әле монда, тизрәк кил.

– Нәрсә бар, Ильяс?

– Менә бу чыршы төбендәге гөмбәне күрәсеңме?

– Юк.

Ильяс кулындагы таягы белән төптән бер уч яфрак тартып чыгаруы булды – анда ак гөреҗдә елмаеп утыра иде.

– Карале син аны. Менә сиңа фокус!

– Гөмбәнең кайда үскәнен күңел белән тоярга кирәк, Рәхим.

Нәкъ шуны гына көтеп торган диярсең, малайлар янына Зәки килеп туктады. Ул бер гөреҗдәгә, бер үзенең буш чиләгенә карап торды да Ильяска арты белән борылып Рәхимгә эндәште:

– Ычкындык моннан, әйдә! Мөхетдин аланы өстенә менәбез, былтыр...

– Сабыр ит инде. Монда да очрый бит әле. Менә бит! – дип, Рәхим җиргә иелде.

Зәки, дустының тыңламавына ачуланып, сул кулын гына селекте. «Нәрсәгә ялынып торам соң. Мөхетдин аланы өстенә үзем генә менәм дә алып төшәм бер чиләк гөмбәне. Болар шаккатсын!»

Зәки юкка чыкты.

Тик былтыргы урында гөмбәдән җилләр искән. Алай итте, болай итте малай – хет күңел өчен генә булса да бер гөмбә дә тапмады. Ачуланып кепкасын тартып төшерде дә җиргә сузылып ятты. Кинәт шартлап сынган ботак тавышын ишетеп, сискәнеп китте. Алдына караса, ни күрсен – аланның уртасыннан башын аска игән хәлдә поши чаба. Туп-туры Зәкигә таба! Зәки куркуыннан ничек сикереп торганын да сизми калды һәм авылга таба элдерде. Кепкасы да, чиләге дә шунда торып калды. Поши аланның икенче ягына, чыршылар арасына кереп югалса да, малай өчен ул нәкъ үзе артыннан ук чабып килгәндәй тоелды, тоякларының җиргә бәрелгән тавышы Зәкинең колак төбендә генә ишетелгәндәй булды. Шулай йөгерә торгач, Зәки Ильяс белән Рәхимнең каршысына ук килеп чыкты.

– Ни булды, Зәки? Нигә шулай шабыр тиргә баттың? Чиләгең кайда?

– Уф, чиләк кайгысымы соң әле, кепкам да төшеп калды. Чүт поши сөзеп үтермәде. Мөгезенә эләктереп алды дигәндә, чак качып котылдым.

– Зур идеме соң?

– Ике сыер хәтле булгандыр.

– Ә чиләгең тулган идеме соң?

Зәки малайларның чиләкләренә күз төшереп алды да эндәшмәде.

– Әйдә, чиләгең белән кепкаңны барып алып киләбез, – диде Ильяс.

– Юк, юк. – Зәки тәмам кызарды. – Хәзер соң инде. Урманда караңгы тиз төшә бит. Башка вакытта... Этем дә тими аңа.

– Гөмбәсез ничек кайтасың инде?

– Без болай итәбез аны, – Ильяс тотты да чиләген җиргә бушатты, – гөмбәләрне бүләбез. Безгә җитә бит монда.

Рәхим дә үзенекен кушты. Шулай итеп, Зәки гөмбәле булды.

...Малайлар авылга кайтып җиткәндә, кояш офыкка кереп чумган иде инде.

– Иртәгә дә барабыз, яме, Ильяс, – диде Рәхим.

– Иртәгә ял көне дә әле. Иртүк китәбез, син дә барасыңмы, Зәки? Иртәгә Мөхетдин аланы өстенә менәрбез. Кепкаң белән чиләгеңне дә табарбыз. – Ильяс бу сүзләрне Зәкинең күзләренә туп-туры карап әйтте.

Зәки «ярар» димәкче иде – тавышы чыкмады. «Анда гөмбә ю-ук», – дип кенә пышылдады һәм тирән итеп бер сулады да сул кулының аркасы белән маңгаеннан агып төшкән тирен сөртте.

## 2008

# Татар дәүләт «Әкият» курчак театры



Татар дәүләт «Әкият» курчак театры 1934 елда ачыла.
Беренче спектакльләреннән үк театр үз алдына балаларга эстетик тәрбия бирү, аларда әдәбият-сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләү, өлкәннәр өчен театрларның булачак тамашачылары итеп үстерү бурычын куя һәм менә инде 75 ел буе шушы вазифасына тугры булып кала бирә.
Театр 1936 елда ук Габдулла Тукайның «Кәҗә белән Сарык» әкиятен сәхнәләштерә.
Ул шулай ук нәниләрне халык әкиятләре, милли фольклор үрнәгендә тәрбияләүгә дә зур игътибар бирә. Театр татар драматургларына балалар өчен әкиятләр иҗат итәргә киң юл ача һәм аларның нәниләргә атап махсус иҗат ителгән әкият пьесаларын һәрдаим сәхнәләштереп килә.
75 еллык тарихында «Әкият» курчак театры Н.Исәнбәт, А.Алиш, Х.Садри, Н.Дәүли, Р.Батулла, Н.Фәттах, К.Тинчурин, Т.Миңнуллин, Р.Харис, М.Гыйләҗев, Г.Рәхим, Р.Мингалим, Р.Корбан һәм башка татар язучыларының әкиятләренә мөрәҗәгать итте.
Театрда Ф.Таһиров, М.Хисамова, С.Вәлиуллина кебек сәхнә корифейлары эшләде.
Алар эстафетасын кабул иткән Р.Фәйзуллина, Р.Гыйззәтуллин, Ф.Сабирова, Г.Габдрахманова, Ю.Чуктиев, М.Сабирова, М.Гайфуллин кебек яшьрәк буын курчак уйнату осталарының тырышлыгы белән «Әкият» курчак театры 2008 елда Абдулла Алишның «Сертотмас үрдәк» әкияте буенча куелган спектакль һәм татар балалар китабы көннәрендәге актив эшчәнлеге өчен Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге премиясенә лаек була.

# ЭЧТӘЛЕК

**Татарстан Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге премиясе турында нигезләмә** . . . . . 2

**Шәүкәт Галиев** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Котбетдин мәргән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4

**Ләбибә Ихсанова** . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Очты, очты... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20

**Роберт Миңнуллин** . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Җиде абый тай җигә . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Өлкәннәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Торам менә елмаеп . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Олы булсам... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Пират . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Сүз тыңлый торган малай . . . . . . . . . . . . 27
Әни эштән кайтканчы . . . . . . . . . . . . . . . 27
Бутаган . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Югалган көн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Әтием палас кага . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Мактанырга яратмый... . . . . . . . . . . . . . . 29
Әйтмим . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Булатларга кунакка! . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Сабантуйда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Кызыл тавык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Кыр кәҗәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Мөгезсез бозау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Кем нәрсә тарта? . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Минем таныш автобусым . . . . . . . . . . . . 33
Энемне тирбәткәндә . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Качышлы уйнаганда . . . . . . . . . . . . . . . 34
Яздык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Бакча белән хушлашу . . . . . . . . . . . . . . . 35
Тылсымлы таяк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Авырткан кебек кенә . . . . . . . . . . . . . . . 36

**Рөстәм Мингалим** . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
Чәчең сыйпап, җил исә . . . . . . . . . . . . . 38
Дусларың гына булсын . . . . . . . . . . . . . 38
Мин җиләккә килдем . . . . . . . . . . . . . . . 39
Тамчы тотам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
Җирдә җайлы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
Ә сәгать келт-келт итә . . . . . . . . . . . . . . 40
Ачып куйдым капкасын . . . . . . . . . . . . . 40
Дусларым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
Җәйнең эссе чагында . . . . . . . . . . . . . . . 41
Яңгырлы кичтә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
Тук-тук! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
Узучылар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
Хәй күршесе Хөсәен . . . . . . . . . . . . . . . 43
Батыр Булат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Крокодил күрдек . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Барам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Юлга чыккан бер малай . . . . . . . . . . . . . 45
Бала балык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Алма төшкән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Торналар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Ак куян . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Кыюлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Гаҗәп кунак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48

**Хәкимҗан Халиков** . . . . . . . . . . . . . . . . 49
Тәти кыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Ялгышмаска өйрәнә . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Елак-мылак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Бәләкәй егет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Энем дә бии . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Алга бара . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Хәзер инде өчәү без . . . . . . . . . . . . . . . 52
Үзебезчә бүлдек . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Почмаксыз өй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Кайтасы гына килгән . . . . . . . . . . . . . . . 53
Котырган бозау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Бәләкәй машинист . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Охшаткан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Шайтан чакыра . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Үпкәли . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
Йоклаганда гына . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
Битен юдыртты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
Агачлар да белә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Ник сукты икән? . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Мин беренче! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Гөлдер бу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
Ял ит инде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57

Искәртте . . . 57
Маңгаена язылган . . . 58
Өйгә кергәч... . . . 58
Туктаттым . . . 58
Ятим пескәй . . . 58
Төшәрен уйламый . . . 59
Батыр кыз . . . 59
Кадыйр . . . 59
Чыелдык . . . 60
Ләм-мим . . . 60

**«Сабантуй» газетасы** . . . 61

**Ләбиб Лерон** . . . 63
Татар баласы . . . 64
Хәерле иртә! . . . 64
Сизми калганбыз... . . . 64
Көзге бакчада . . . 65
Татар теле дәресендә . . . 65
Җилдерәләр, әй, атта... . . . 65
Бакчабызда бер бала бар... . . . 66
Портрет . . . 66
Буталмыш илендә . . . 66
Кызык кыш . . . 67
Бу кай вакыт? Әйт, балам! . . . 67
Радиога салкын тигән . . . 68
Көяләй . . . 68
Йөри торган урындык . . . 68
Гөлләр рәхмәте . . . 68
Яз . . . 69
Сыерчыклар . . . 69
Апрель . . . 69
Кояшлы яңгыр . . . 70
Кем кайда яши? . . . 70
Казлар һәм бәбкәләр . . . 70
Нәкыя . . . 71
Нәни димәгез миңа . . . 71
Кояшны кочкан малай . . . 71
Җәй көтә безне... . . . 72
Акбай белән Кояш . . . 72
Соклангыч дөнья . . . 72
Миңлегата «борчак ата» . . . 73
Җил көймәсе . . . 73
Мәче балалары . . . 73
Сабан туе, сабан туе... . . . 74
Автобушлар . . . 74

**Рәшит Бәшәр** . . . 75
Бәбкәле болын . . . 76
Мыш-мыш . . . 77
Танышу . . . 77
Безнең кайсыбыз кунак? . . . 78
Яшен . . . 78
Ат . . . 79
Шәһәр төзим . . . 80
Бүрәнә һәм бүдәнә . . . 80
Бал суыртучы аю . . . 81
Әкият сөйлә . . . 81
Нишләп бетәрләр инде? . . . 82
Картайган ат . . . 82
Тегүче кырмыска . . . 83
Сандугач . . . 83
Шомырт тотты якадан . . . 84
Таган . . . 84

**Җәүдәт Дәрзаманов** . . . 85
Күлмәк юам . . . 86
Елак курчак . . . 86
Бүген генә үскән, ахры . . . 87
Такыя . . . 87
Күкеле сәгать . . . 87
Саный беләм . . . 88
Син усал түгел икән . . . 88
Камыраяк . . . 89
Көрәк . . . 89
Яңа чана яңа шул . . . 89
Җешшек көндә . . . 90
Куян бүрек . . . 90
Яз килә . . . 90
Ташкын . . . 91
Өч табышмак . . . 91
Әбием сүзләре . . . 91
Чирткәннәр . . . 92
Үземне тотты балык . . . 92
Җәйге яңгыр . . . 92
Алмаз . . . 93
Тылсымлы чүкеч . . . 93
Нур дәү булган . . . 93
Солдат булдым . . . 94
Наза йөри бакчада . . . 94

**Галимҗан Гыйльманов** . . . 95
Бүреләр һәм Иоһанн Себастьян Бах . . . 96

**Роза Хафизова** . . . 101
Күңел күзе . . . 102

**Рафис Корбан** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
Балалар бакчасында Көзге бал . . . . . . . . . 106
Бакчада мәктәпкә озату бәйрәме . . . . . . . 110
Чебен-Чебенчек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114

**Илсөяр Сөнкишева** . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116

**Йолдыз** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
Әни хәйләсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Җаен таптым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Юату . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
Гөлләр сагышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
Тәмле җиләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
Сатабыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
Нәрсә кемне үстергән? . . . . . . . . . . . . . . . 120
Эзләдек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
Билге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
Пычранмаган . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 121
Җырчы болын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Белмәмеш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Бүләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Өйрәтә торган ишек . . . . . . . . . . . . . . . . . 123
Колаклы коймаклар . . . . . . . . . . . . . . . . . 123
Көнләшү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
Авылны сагынганда . . . . . . . . . . . . . . . . . 124
Әни сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
Калган эшкә кар явар . . . . . . . . . . . . . . . 125
Кыярлар ник саргайган? . . . . . . . . . . . . . 126
Теш табибында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
Куркыныч уй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Чүп зары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Салават күпере . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Каникулда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128

**Мәрзия Фәйзуллина** . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
Гөлнар мәктәпкә бара . . . . . . . . . . . . . . . 130
Чебиләр зарядкасы . . . . . . . . . . . . . . . . . 130
Беренче май . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
Ялкау чебен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
Күләгә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
Урман докторы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
Чәчәкләр сәгате . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Күгәрчен бала чыгаргач . . . . . . . . . . . . . 132
Яшен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Гөлләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Казлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Чыршы күлмәкләре . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Гөмбәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133
Елак бәбкә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Җәнлекләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Теләсәң, эш табыла . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Ике көрәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Торналар нигә озын аяклы? . . . . . . . . . . 135
Күгәрчен һәм самолет . . . . . . . . . . . . . . . 135
Бал корты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Яңа һәм иске ай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Чебиләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Курчагым, йокла инде . . . . . . . . . . . . . . . 136
Пешкән, әллә пешмәгән . . . . . . . . . . . . . . 136
Тимераяк шуганда . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Чишмә кая чаба? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
Үрдәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
Керпе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
Сыер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Суган тураганда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Ислам дине . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Кыш бабай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
Чана шуганда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139

**Татарстан Республикасы «Мәгариф» милли нәшрияты** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140

**Энҗе Мөэминова** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141
Кем китерә бәйрәмне? . . . . . . . . . . . . . . . 142
Көн дә булышам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
Бәйрәм китердек әбигә . . . . . . . . . . . . . . 143
Моңсу бәйрәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
Сабантуй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
Эш табыла кемгә дә . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
«Сагыну чиraты» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Бүләк итсеннәр иде . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Яңа ел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
Әллә фокусчы микән? . . . . . . . . . . . . . . . 146
Үз телендә сөйләшә . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
Бер хикмәт бар... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Сыбызгы сызгырталар . . . . . . . . . . . . . . . 147
Балыкчы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Иң олысы кем бездә? . . . . . . . . . . . . . . . 148
Ничек тыңлатыйм? . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Ул алдан килеп җиткән . . . . . . . . . . . . . . 148
Килешми . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Булган хәл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Сукыр күзлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Бик матур иде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Мендәркәем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Чакыралар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Үпкәләде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152
Бәхәс . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152

**Әнәс Хәсәнов** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Нәни аучы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154

**Татарстан китап нәшрияты** . . . . . . . . . . . . . . . 157

**«Салават күпере» журналы** . . . . . . . . . . . . . . . 159

**Равил Рахмани** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Яз кояшы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Боз киткәндә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Табигатьнең үтә сизгер бер иркәсе – Кызыл китапка кертелгән кылганнар турында җыр . . . . . . . 163
Күрше хакы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Әби-бабай хакы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164

**«Ялкын» журналы** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165

**Алмаз Гыймадиев** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Ниязның рекордлар китабы . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
Бүләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169

**Вакыйф Нуриев** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171
Китап . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172
Хуҗалар тавында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173
Инша . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
Гөмбә оясында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176

**Татар дәүләт «Әкият» курчак театры** . . . . . . . 179

УДК 821.512.145-1:3-93
ББК 84(2Рос=Тат)-4:5
А51

**Төзүчесе РАФИС КОРБАН**

А51 Алиш варислары : Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Абдулла Алиш премиясе лауреатлары әсәрләре / Төз. Р.Корбан. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 183 б.
ISBN 978–5–298–01741–1

УДК 821.512.145-1:3-93
ББК 84(2Рос=Тат)-4:5

Литературно-художественное издание

## НАСЛЕДНИКИ АЛИША

**Произведения лауреатов премии имени Абдуллы Алиша, учрежденной министерством Культуры и Союзом писателей Республики Татарстан**

Составитель **Курбанов** Рафис Харисович

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

## АЛИШ ВАРИСЛАРЫ

**Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге премиясе лауреатлары әсәрләре**

Төзүчесе **Корбанов** Рафис Харис улы

Мөхәррире *Т.Р.Шакирова*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Компьютерда биткә салучысы һәм техник мөхәррире *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, Л.Р.Галимова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 2.07.2009. Форматы 84´108 1/16. Шартлы басма табагы 14,63.
Тиражы 2000 д. Заказ Т-1060.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

ISBN 978–5–298–01741–1

© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Корбанов Р.Х., төзү, 2010